
ИРЕК ГАБДРАХМАНОВ
ЯШИМ ӘЛЕ...



# АВТОБИОГРАФИЯ

Мин 1962 елның 8 сентябрендә (бәрәңге алган вакытта) Башкорт АССР ы Бүздәк районының Яңа Актау авылында Мәгсүм һәм Флүрә Габдрахмановларның гаиләсендә икенче бала булып дөньяга килгәнмен.Чирле булып тугангамы, ничектер мине 1963 елның 2

январенда туган дип яздырганнар. Балачактан ук авыр гәүдәле, сабыр холыклы булып үстем.Өч сыйныфны Яңа Актау башлангыч мәктәбендә тәмамлагач, 1974 елның сентябрендә 7км ераклыкта урнашкан Урзайбаш урта мәктәбендә укый башладым.Бу мәктәптә 5 ел белем алгач, безне Каран урта мәктәбенә күчерделәр.Соңгы классны-чыгарылыш елын шушы мәктәптә укыдым.

Миңа белем дөньясына ачкыч бүләк иткән беренче укытучыларым Заһира Габдрахимова һәм Рәхилә Зөбәерова, яраткан укытучыларым Рәүхәт һәм Әклимә Халиковлар,Гамил һәм Зөхрә Исмакаевлар,Хәниф һәм Роза Хасановлар,Ваһапова  Венера,Латыпова Зилә,Сабирова Әнисә апалар һәм безне кулларыбыздан алып,белем дөньясыннан алып барган класс җитәкчеләре Рәзилә Рәшитевна һәм Флүрә Әсгатовналарның тугры хезмәте,безгә салган ихтыяр көче нәтиҗәсендә 1980 елны урта мәктәпне яхшы билгеләр белән тәмамлап чыктым.Урта белем алгач та озак уйлап тормыйча документларны Башкорт ДПИ ның физика-математика бүлегенә илтеп тапшырдым.4 имтиханның 3 тик “4” һәм “5” билгеләренә тапшыргач, күңелем белән инде мин авыл малае үземне җиде кат күктә итеп тойдым.Соңгы имтихан-рус теленнән язма инша иде.Үземчә бик тырышып, эчтәлекле һәм хатасыз язарга тырыштым.Тик тормыш законнары без дигәнчә генә булмый икән шул.Ул вакытта мин аңлый алмаган сәбәпләр белән, соңгы имтиханны тапшыра алмадым-хәтта карап чыгарга да бирмәделәр язган иншаны.

Уку йортына керә алмагач, читтән торып укырмын дип уйлап район мәгариф бүлегенә бардым. Мине Өчтүбә сигезеллык мәктәбенә тарих һәм география укытучысы итеп билгеләделәр.”Рожденный ползать-летать не может!”-диләр бит,бераз эшләгәч мин үземне укытучы булып эшли алмавыма,өстемә бик зур йөкләмә алырга иртәрәк булуына төшендем.Төрле урыннарда-колхозда,кино хезмәтендә,урман хуҗалыгында,мәдәният учагында эшләп,читтән торып Кушнаренко авыл хуҗалыгы техникумын һәм Башкорт авыл хуҗалыгы институтын тәмамладым.Кайда гына барсам да,кайда гына укысам да явыз чир һәм физик мөмкинчелекләрем мине арттан эзәрлекләп йөрде.Тик мин һаман да алга барырга:үз тормышымны төзергә,ата-анага обуза булмаска,гаиләле булырга тырыштым.Бүгенге көндә мин 2 группа инвалиды,25 ел хезмәт стаҗым бар,2 дипломым бар!!!Инде 3 ел булды-Октябрьский картлар һәм инвалидлар йортында

яшим.Бернәрсәгә дә үкенмим,уфтанмыйм-акрын гына иҗат итеп, яшәп ятам.Дөньялыкта якты эзем калсын дип,шушы беренче китабымны чыгарырга булдым.”Одноклассники” сайтында ике группа ачтым:”Бүздәгем-моңнар төбәгем!” һәм “Татар бар җирдә иман бар!” группалары, анда 8000 якын кеше берләшә.Аллага шөкер, иртән йокыдан тору белән, эшкә чумам!Кемнедер туган көне белән котларга,кемнеңдер якын кешесенә котлау язырга яки кемнеңдер шатлыгын,кайгысын уртаклашырга-шулай итеп көннәр,айларның үткәне сизелми дә кала.

Үземнең мөмкинчелекләрем бик аз , китап чыгартырга ярдәм сорап дусларыма мөрәҗәгать иттем.Авылдашым –эшкуар Гыйлванов З.Н. яңа ноутбок бүләк итте.ООО НПФ «Пакер» директоры Нагуманов М.М. та озак уйлап тормыйча счетка акча күчерде.Ходай андый кешеләрне рәхмәтеннән ташламас иншалла!Классташларым Лүзә Андарьянова(Низамиева) һәм Т.Б.Тимашев иң беренчеләрдән булып үз өлешләрен кертте.”Күл тамчыдан җыела!”-ди халык әйтеме. Әйе, бәлки шундый изге күңелле кешеләр ярдәм итсә, бу китабым чыгар!Мин үземнең иҗат җимешләрендә туган ягыма, туган җиремә, яраткан халкыма, матур туган телемә һәм ЯЗга,НАЗга,ГҮЗӘЛЛЕКкә мәхәббәт тойгыларымны, күңелемдәге әрнү-сагышларымны күрсәтергә тырыштым.

Яраткан халкыма һәм шигърияткә гашыйк укучыларыма мин шушы сүзләрне әйтер идем:

“АЛЛАБЫЗ БЕЗГӘ ГОМЕР БИРГӘН,СӨЮ ҺӘМ НАЗ БҮЛӘК ИТКӘН!АЯК-КУЛЛАР, КУРКУСЫЗ ЙӨРӘКЛӘР,ТҮГӘРӘК БАШЛАР ЯСАП КУЙГАН!ТУГАННАРЫМ !ТОРМЫШ ТИК БЕР ГЕНӘ-КАДЕРЛӘРЕН АНЫҢ БЕЛ ГЕНӘ!АЯК-КУЛЛАРЫГЫЗ ИСӘН-САУ ЧАГЫНДА ЙӨГЕРЕГЕЗ,ЭШЛӘГЕЗ,ЯЛ ИТЕГЕЗ,УЙНАГЫЗ-КӨЛЕГЕЗ,СӨЕГЕЗ ҺӘМ СӨЕЛЕГЕЗ!СЕЗНЕҢ ЙӨРГӘН ЮЛЛАРЫГЫЗДА ГӨЛЛӘР ҮСЕП КАЛСЫН!”




**ТУГАН ЯГЫМ-ТУГАН БИШЕГЕМ!!!**

**СИН ВАТАНЫМ МИНЕМ БАШКОРТСТАН!!!**

**=======================================**




БӘХЕТ ИЛЕМ!

Туган җирем минем бәхет илем!

Чал тарихлы Туган илгенәм!

Башкортстан-син Ватаным минем!

Гөлбакчада үскән гөлгенәм!

Яши синдә уңган,эшчән халкым,

Бәхет табып туган җирендә.

Бер җан булып,туган булып яши,

Барча халкым бәхет илендә!

Ак каенлы урман акланнары!

Җиләккә бай җәйге тугайлар!

Кайсы илдә шулай моңлы итеп,

Сайрый икән җырчы тургайлар?

Иделләргә кадәр барып җитә,

Безнең татлы чишмә сулары!

Горур Агыйделем шаулап ага,

Бигрәк күркәм Танып буйлары!

Торган җирем минем бәхет илем!

Эшчән халкым яши сөенеп!

Тәгәрәшеп нарасыйлар туа,

Бәхеткә һәм назга төренеп!

Газиз туган җирем-бәхет илем,

Башкортстан-алтын бишегем!

Синдә тудым,синдә яшимен мин!

Сиңа баглыйм иҗат җимешен!

****************************************

МИН   ЯРАТАМ.......!

Мин яратам җаным-каным белән, туып-үскән газиз илемне!

Мин яратам кендек каным тамган, тәпи баскан туган җиремне.

Мин яратам Тукай илһам алган, “Әллүки”ле  туган телемне.

Мин яратам кошлар канат каккан, тулган айлы зәңгәр күгемне!

Пар аккошлар  йөзгән күл буенда мин яратам илһам алырга,

Җырчы тургай-сандугачлар сыман, сайрый-сайрый канат кагырга!

Мин яратам таңнар аткан чакта, чыклы үләннәргә басырга,

Чалгы тавышларын тыңлый-тыңлый, җырлый-җырлый печән чабырга!

Мин яратам авыл таңнарын!Яңгыраган гармун моңнарын!

Мин яратам эшчән авыл халкын!Улларын һәм чибәр кызларын!

Мин яратам күңел тулган чакта,шау чәчкәдә торган кырларын!

Мин яратам нарат урманнарын!Җырлый-җырлый атлар юлларын!

Шаулап узган туйлар-йолаларны, бәйрәмнәрне мин бик яратам!

Кичке уеннарны...Су буйларын...Оныталмыйм, һаман яратам!

Күңелләрдә җуелып калган инде,балачакның якты мизгелләрен

Ташлап булмый һич тә күңелдән!МИН ЯРАТАМ һаман ЯРАТАМ!

---------------------------------------------------------------------------------------

ИДӘШ    БУЙЛАРЫ.

Күз алдымда нарат урманнары,

Тузанланган арба юллары.

Кулын болгап, чакыралар сыман

Кузгалаклы Идәш буйлары.

Ак каеннар әйләндереп алган,

Хозурлык соң Кичу буйлары!

Шомырт чәчәк аткан тугайлары,

Ташкүперле Идәш сулары.

Колагымда чыңлый уеннарда

Яңгыраган гармун моңнары.

Учак ягып, ат көтүе көткән

Нагыштаулы Идәш буйлары.

Бар тормышым минем урман булды!

Чикләвекле болын-кырлары.

Җырларым да, моңнарым да сезгә-

Саф чишмәле  Идәш буйлары!

## ТУГАН АВЫЛЫМ.

Бик еш кайтып булмый авылларга,

Газиз әткәй-әнкәй янына.

Инде читтә яшәп өйрәнсәк тә,

Күңел һаман шунда ашкына.

Төшләремә керә туган авылым!

Туган йортым! Туган нигезем!

Бар күңелем белән сизәм сыман,

Туган якның йөрәк тибешен.

Авылымның салкын чишмәләрен,

Төштә күреп, сусап уянам.

Күз алдымда газиз балачагым!

Тиле яшьлегемне сагынам.

Авылдашлар! Бергә үскән дуслар!

Сагынамын хәзер барсын да!

Рәхмәтлемен биргән илһамыңа,

Туган авылым синең каршыңда!

****************************************

"МИН-БҮЗДӘКТӘН!"

Кояш сыман якты йөзле халкым!

Күзләреннән нурлар сибелә.

"Мин-Бүздәктән!"-диеп кул бирсәләр,

Күңелләрем моңга күмелә!

Сандугачлар булып сайрыйм әле,

Бәхет белән тулган илемдә.

Кайнар йөрәгемнән моңнар чәчәм,

Кендек каным тамган җиремдә!

Әгәр миннән туктап сорасалар-

"Син кайдан соң,кордаш?"-дисәләр.

"Мин-Бүздәктән!"-димен канатланып,

Күңел кылларымны чиртсәләр.


Туып үскән кырларыбыз иркен,

Горурланыйк-без бит Бүздәкләр!!!

Улларыбыз-кызларыбыз гүзәл,

Мәңге бергә типсен йөрәкләр!

**************************************




"БЕЗ - БҮЗДӘК ЕГЕТЛӘРЕ!!!"

Ирек Габдрахманов сүзләре

Ирек Зарипов музыкасы

Горурланам туган җирем белән,

Кендек каным шунда тамган бит.

Гүзәл яшьлек...Газиз балачагым...

Шул елларда качып калган бит.

Пешә Бүздәк чияләреееее...

Исә җәйнең  җылы җилләре.

Җырлыйбыз да,биибез дә кайчак,

Без- Бүздәәәәк егетләре!

Яши бездә уңган,эшчән халык,

Шаулап тора икмәк кырлары.

Көләч йөзле, алиһәләр сыман

Сөйкемлеләр Бүздәк кызлары!

Чәрмәсәне...Идәшләреее...

Шомырт чәчәгенең исләре.

Сынатмыйбыз-бил бирмибез,

Без-Бүздәәәк егетләре!

Чәчәк атсын туган җирләребез,

Гөлгә тулсын хозур мизгелләр!

Иң яхшысы-тик без булып калыйк-

Горурланыйк-без бит Бүздәкләр!

Пешсен Бүздәк чияләреее...

Шаулап торсын җәйге кичләре.

Яшик әле яшеннәрдәй яшьнәп,

Без -Бүздәәәк егетләре!

Без -Бүздәәәк Ирекләре!

---

КӨЯЗЕТАУ.

Без яшь чакта мәктәп ерак иде,

Җиде чакрым көн дә юл үттек.

Кире кайткан чакта, сиңа туктап

Салкын сулар эчтек! Ял иттек!

Кайда синең тезелешкән йортлар?

Бер казык та юк бит ичмасам.

Кайда булган гөрләп торган авыл?

Күңел тула сиңа тукталсам.

Кайда синең ачык апаларың?

Типсә тимер өзәр ирләрең?

Чия-алмагачлы бакчаларың-

Пар аккошлар йөзгән күлләрең.

Картада да юксың-кайда булдың?

Урының да хәтта сөрелгән.

Салкын сулы тирән кое да бит

Балчык белән тулып, күмелгән.

Шушы гөрләп торган күркәм авыл

Кайсыбызга каршы төшкәндер!

Бу адымга кайсы туң йөрәкнең,

Черек акылына килгәндер!

Чирәмнәрне сөрдек...Авылларны

Эреләттек инде янәсе.

Хәзер әнә ата-бабаларның

Сөякләрен җыеп күмәсе.

Юлым төшсә моннан узып китәм,

Кайтып-китеп йөргән чакларда.

Уйлап куям: ничә авыл шулай

Югалганын туган якларда.

Кулын болгап, арттан калыр төсле

Шәл бәйләгән эшчән апалар.

Тик тарихлар гына тере була-

Мәңгелеккә кереп калалар.

Яшел нарат, чыршы каплап киткән

Пеләш башлы Көяз  тауны да.

Төштә күрәм: кемдер кулын болгый

Тау башында – Көязтавымда!

---

СҮРЕЛМӘСЕН ӘНКӘЙ НУРЛАРЫҢ!!!

ТУГАН ЙОРТ ТА СҮРӘНЛӘНЕП КАЛГАН,

БАКЧАЛАР ДА ГӨЛСЕЗ-ЧӘЧКӘСЕЗ.

ӘЛЛӘ ШУЛАЙ КӨЗГЕ МОҢСУЛЫКТАН-
ШОМЛЫ УЙЛАР БАШКА КИЛӘСЕЗ.

ЯМАН ЧИРДӘН СУЫРЫЛГАН ЙӨЗЕҢ,

НӘЗЕКЛӘНГӘН АЯК-КУЛЛАРЫҢ.

ТИК КҮЗЛӘРЕҢ ҺАМАН ҖЫЛЫ СИБӘ,

СУРЕЛМӘСЕН ӘНКӘЙ НУРЛАРЫҢ!

АВЫР ТОРМЫШ-ЯЗМЫШ МАҢГАЙЛАРГА

ЯРЫП САЛГАН ТИРӘН ЭЗЛӘРЕН.

МИНЕМ ДӘ БИТ ЯЛГЫШЛАРЫМ БУЛДЫ-

КИЧЕР ЗИНҺАР ГӨНАҺ ЭШЛӘРЕН.

ЧЫГЫП ИНДЕ ЙӨРИ ДӘ АЛМЫЙСЫҢ,

ҮЛӘН БАСКАН ЙӨРГӘН ЮЛЛАРЫҢ.

ТИК СҮЗЛӘРЕҢ ҺАМАН ҖАНГА ДӘВА-

СҮРЕЛМӘСЕН ӘНКӘЙ НУРЛАРЫҢ!

СОҢГЫ ФАТИХАҢНЫ АЛЫРГА ДИП,
КАЙТТЫМ ӘНКӘЙ СИНЕҢ ЯНЫҢА.
НИ ЭШЛӘСӘМ ФАЙДА БУЛЫР ИКӘН,
ГАЗАПЛАРДАН СУЛГАН ҖАНЫҢА.

ӨЙ ТҮРЕНДӘ ЧӘЧӘК АТМЫЙ ГӨЛЛӘР,
ИШЕТЕЛМИ МОҢЛЫ ҖЫРЛАРЫҢ.
ГӨЛЛӘР СУЛСА СУЛСЫН!ТИК СИН ЯШӘ!
СҮРЕЛМӘСЕН ӘНКӘЙ НУРЛАРЫҢ!

А К Т А У

МИН ТУГАНМЫН АКТАУ АВЫЛЫНДА,
ИСКЕСЕНДӘ ТҮГЕЛ- ЯҢАСЫНДА!!!
ШУҢА КҮРӘ АЕРЫЛЫП ТОРАМ,
АВЫЛДАШЛАР,ДУСЛАР АРАСЫНДА!
ГОРУРЛЫГЫМ МИНЕМ,ҖАНЫМ-АКТАУ!
МИН БӘХЕТЛЕ!МИН БИТ-АКТАУДАН!
БАРЛЫК ҖИР ШАРЫНДА БЕЗНЕҢ АКТАУ-
БАР ШӘҺӘРЛӘР ШУЛАЙ АТАЛГАН.
КИБЕТЛӘР БАР-"АКТАУ" ДИП ЯЗЫЛГАН,
"АКТАУ" ДИГӘН ХӘТТА СЫРА БАР.
МӘҢГЕЛЕККӘ ҖУЕЛМАСЛЫК ИТЕП,
ЯЗЫП КУЙГАН АНЫ  ЯКТАШЛАР!
СИНЕҢ БЕЛӘН ГОРУРЛАНАМ АКТАУ!
СИН БИТ МИНЕМ ТУГАН БИШЕГЕМ!

МИНЕ ЯКТЫЛЫККА ЧЫГАРУЧЫ,

МАЯГЫМ СИН!!!БӘХЕТ ИШЕГЕМ!!!

--------------------------------

МОГҖИЗАЛАР ИЛЕ!

ӘКИЯТТӘ ТҮГЕЛ... ЧЫНБАРЛЫКТА...

БУЛА ИКӘН ШУНДЫЙ МОГҖИЗА!

КИЧӘ ГЕНӘ ЫЗГЫЛАШКАН ДУС ТА,

БҮГЕН КИЛЕП, СИҢА КУЛ СУЗА.

ҖИР ЧИТЕНДӘ ТОРГАН ТУГАН БЕЛӘН,

СӨЙЛӘШӘСЕҢ КИЛСӘ-БЕР МОМЕНТ!

КИРӘК ТҮГЕЛ КЫЙММӘТ БИЛЕТЛАР ДА,

КИРӘК ТҮГЕЛ ПАСПОРТ-ДОКУМЕНТ!

ЙӨРӘК БЕЛӘН ЙӨРӘК СЕРЛӘШКӘНДӘ,

МОНИТОРЛАР ТЫНЫП КАЛАЛАР,

ХУШТАН ЯЗАР ИДЕ-КОМПЬЮТЕРНЫ,

КҮРЕП КАЛСА АТА-БАБАЛАР.

КИРӘК ИКӘН ҖЫРЛАР ТЫҢЛАП АЛАМ,

УЕННАРГА КУЛ ДА ӨЛГӘШМИ.

БАР НӘРСӘНЕ БЕЛӘ-ШАККАТМАЛЫ!!!

ТЕЛЕ ГЕНӘ ТИК ЮК...СӨЙЛӘШМИ!

КӨТЕП АЛАМ ДУСЛАР ХӘБӘРЕН МИН,

ДУСЛАР БЕЛӘН БЕРГӘ СӨЕНӘМ.

КӨН ДӘ ИРТӘН ИЗГЕ ТЕЛӘК ТЕЛИМ,

КАЙГЫЛАРЫ БУЛСА- КӨЕНӘМ.

БЕЗ ЯШИБЕЗ ИСКИТМӘЛЕ ЧОРДА!

АДЫМ САЕН ХӘЗЕР- МОГҖИЗА!

ШУҢА КҮРӘ ИГЕЛЕГЕН КҮРЕП,

ЯШИ БЕЛИК, ДУСЛАР, ДӨНЬЯДА!

******************************

АЗАН МОҢЫ

--------------------------------------------------------------------

КҮПТӘН ИНДЕ КАЙТА АЛМАДЫМ ШУЛ,

ТУГАН ЯККА...ТУГАН АВЫЛГА...

ҮЗГӘРӘ ЧОР...ҮЗГӘРӘБЕЗ БЕЗ ДӘ-

БИРЕШӘБЕЗ ЯЗМЫШ-ДАВЫЛГА.

ТАҢ АТКАНДА ИСЕМ КИТТЕ ХӘТТА!

ЯҢГЫРАДЫ АЗАН МӘЧЕТТӘН.

БАР АВЫЛГА СЕРЛЕ НУРЫН ЧӘЧЕП,

КИЛЕП КЕРДЕ ҺӘРБЕР ИШЕКТӘН.

"...АЛЛАХҮ ӘКБӘР! ...АЛЛАХҮ ӘКБӘР!..."

ИМАН КАЙТТЫ ТУГАН ЯГЫМА.

ИМАН БЕЛӘН БЕРГӘ ӨМЕТ КАЙТТЫ,

ҖЫР-МОҢ СӨЙГӘН ЭШЧӘН ХАЛКЫМА.

МӘЧЕТЛӘРДӘ ИСЕМ КУШТЫРАБЫЗ,

КАВЫШАБЫЗ АЛЛА ЙОРТЫНДА.

ЫШАНЫЧЛЫ ПАРЛАР БУЛЫР ӨЧЕН,

ВӘГЬДӘЛӘШЕП ХОДАЙ КАРШЫНДА.

ИРТӘ-КИЧЕН-КӨН ДӘ ИКЕ ТАПКЫР,

ИШЕТЕЛӘ АЗАН МОҢНАРЫ.

ҖЫЕЛЫША КАРТЛАР ИЗГЕ ЙОРТКА,

ИЛҺАМЛАНА КҮҢЕЛ НУРЛАРЫ.

БАР ДӨНЬЯГА ИМАН НУРЫН ЧӘЧЕП,

ИШЕТЕЛСЕН АЗАН МОҢНАРЫ!

ТЫНЫЧЛЫКТА, ГАДЕЛ ИЗГЕЛЕКТӘ

АТЫП ТОРСЫН ТОРМЫШ ТАҢНАРЫ!

ИЗГЕ ҖОМГА.

АТА-БАБАМНАРДАН КАЛГАН ИМАН,

ҖАННАН-ҖАНГА, КАННАН-КАНГА СЕҢГӘН!

ӘЙТӘ ИДЕ КАРТӘТИЕМ:"БАЛАКАЕМ!

МӘРХҮМНӘРГӘ, ӘРВАХЛАРГА УКЫТ КОРЬӘН!"

БҮГЕН ҖОМГА...ӘНИЕМНЕҢ КЫРЫК КӨНЕ,

ИШЕГЕМНӘН НУРЛЫ ИМАН КЕРДЕ!

МӘДРӘСӘДӘН МУЛЛА КИЛЕП КОРЬӘН ӘЙТТЕ,

ҖИДЕ БУЫН ТУГАН ӨЧЕН ХӘЕР БИРДЕМ.

АТНАБЫЗНЫҢ ШУШЫ ИЗГЕ ҖОМГАСЫНДА,

УКЫТТЫМ МИН КОРЬӘН ӘНИ СИҢА!

ҖӘННӘТЛӘРДӘ БУЛСЫН УРЫННАРЫҢ,

КУЗГАЛЫП ЯТ!ЗИНҺАР АВЫРСЫНМА!

БҮГЕН ҖОМГА...ИМАНЛЫ ҺӘМ МОҢЛЫ ҖОМГА!

СӨЕНЕШСЕН БАРЧА ТУГАННАРЫМ!

ҮТӘҮ КИРӘК АТА-БАБА ВАСЫЯТЕН!

БӘЛКИ БЕТӘР КҮҢЕЛДӘГЕ ГАЗАПЛАРЫМ

*******************************************

ӘЙ ДУСЛАРЫМ ӘЙТИМ ӘЛЕ БЕР МӨНӘҖӘТ:

КҮҢЕЛЕГЕЗ ИЗГЕ БУЛСА ТОРМЫШ-ЛӘЗЗӘТ.

СИҢА НАЧАР ЭШЛӘСӘЛӘР - ИТ ИЗГЕЛЕК,

АЛЛАБЫЗДАН КҮРЕРСЕЗ СЕЗ-ТИК ИГЕЛЕК.

---------------------------------------------------------------------

ТУПАС ТЕЛЛЕ АХМАКЛАРНЫ ХАЛКЫМ СӨЙМӘС!

БИСМИЛЛАСЫЗ БӘНДӘЛӘРГӘ КУЛЫН БИРМӘС!

АЛЛАБЫЗДАН ЯРДӘМ СОРАП, БАШЛАР ЭШЕН,

ИМАНЫНА ТАП ТӨШЕРМӘС-УКЫР КОРЬӘН.

------------------------------------------------------------------------

ДӨНЬЯЛЫКТА ЯШИК ДУСЛАР ТЫЙНАК КЫНА,

БАРЫБЫЗ ДА БЕЗ БИТ МОНДА КУНАК КЫНА.

БАСКАН ҖИРДӘ ҮСЕП КАЛСЫН ЧӘЧКӘ-ГӨЛЛӘР!

БӘХЕТ БЕЛӘН, ШАТЛЫК БЕЛӘН ҮТСЕН КӨННӘР!

****************

АНА БӘХЕТЕ

НАРАСЫЕҢ КУЕНЫҢА АЛЫП,

ИМЕЗӘСЕҢ НАЗЛАП,ИРКӘЛӘП.

БИШЕК ҖЫРЫН ҖЫРЛАП,ТӨН БУЕНА

ҖӘЙГЕ ҖЫЛЫ ҖИЛДӘЙ ИСКӘЛӘП.

БӘХЕТКӘЕҢ КОЧАГЫҢДА ЧАКТА,

КҮКРӘГЕҢӘ КЫСЫП СӨЯСЕҢ!


АНА БӘХЕТЕ-ШУШЫ БУЛА МИКӘН?

ШУҢА ҖАВАП КИЛӘ БЕЛӘСЕМ.

ШОМА ТӘПИЛӘРЕН ҮБӘ-ҮБӘ,
СИН БИРӘСЕҢ ЙӨРӘК ХИСЛӘРЕН.
ШУШЫ ҮЗЕ БӘХЕТ ТҮГЕЛМЕНИ
БАЛАҢ КӨЛЕП ЯТСА КИЧЛӘРЕН!

“ӘННӘ!”-ДИЕП КАЙЧАН ДӘШЕР ИНДЕ,
СИҢА ТАБА СУЗЫП КУЛЛАРЫН.
КАЙЧАН ИНДЕ ТӘПИ БАСЫП ЙӨРЕР?
БАШЫҢДАГЫ БӨТЕН УЙЛАРЫҢ!

БАШЛАРЫННАН СЫЙПАП,ИРКӘЛИСЕҢ
ӨЧТЕКЛӘП ТӘ АНЫ АЛАСЫҢ.
ХОДАЙ БӘХЕТЕҢНӘН АЕРМАСЫН,
ФӘРЕШТӘЛӘР СИНЕ САКЛАСЫН!



ИСЕҢДӘМЕ.......

ИСЕҢДӘМЕ , ИРКӘМ , ЯЗГЫ КИЧТӘ-
АЛСУ ГӨЛЛӘР БҮЛӘК ИТТЕМ МИН.
ИСЕҢДӘМЕ ҖИЛӘК ТӘМЕ КИЛГӘН,
КАЙНАР ИРЕННӘРЕҢ ҮПТЕМ МИН.

ИСЕҢДӘМЕ ШОМЫРТ ЧӘЧӘК АТКАН,
ТУГАЙЛАРДАН ҖЫРЛАП УЗДЫК БЕЗ.
ИСЕҢДӘМЕ КҮЗГӘ-КҮЗ КАРАШЫП,
ХЫЯЛ ДИҢГЕЗЕНӘ ЧУМДЫК БЕЗ.

ИСЕҢДӘМЕ,ИРКӘМ,ИСЕҢДӘМЕ???
ЯШЬ ЧАКЛАРНЫҢ ГҮЗӘЛ МИЗГЕЛЕ.
КҮЗ АЛДЫМА ГЫНА КИЛӘ ХӘЗЕР-
ӘКИЯТТӘГЕ МИРАЖ ШИКЕЛЛЕ!

ИСЕҢДӘМЕ,ИРКӘМ,ИСЕҢДӘМЕ???
ХУШ ИС ЧӘЧКӘН КЫРЛАР-БОЛЫННАР.
КҮҢЕЛЛӘРДӘ  ТЕРЕ ИСТӘЛЕКЛӘР,
ЯКТЫ МАЯК БУЛЫП КАЛСЫННАР!



БИР АЛЛАМ!!!

БӘХЕТЛӘРНЕ,

СӨЮЛӘРНЕ,

ШАТЛЫКЛАРНЫ

БИР АЛЛАМ!!!

ЧӘЧӘКЛӘРГӘ,

ЙОЛДЫЗЛАРГА

ДӨНЬЯБЫЗНЫ

КҮМ АЛЛАМ!!!

ДИНДАРЛАРГА,

МӨСЛИМНӘРГӘ,

ТҮЗЕМЛЕКНЕ

БИР АЛЛАМ!!!

АНАЛАРГА,

САБЫЙЛАРГА,

БӘХЕТЕҢНЕ

БИР АЛЛАМ!!!!

ЯТИМНӘРГӘ,

ҮКСЕЗЛӘРГӘ,

ЯРДӘМЕҢ БИР

И-И АЛЛАМ!!!!

ГАРИПЛӘРГӘ,

СЫРХАУЛАРГА,

ИСӘН-САУЛЫК

БИР АЛЛАМ!!!

ТЕЛӘКЛӘРЕМ

КАБУЛ БУЛСЫН!

СӨБХАНАЛЛА-

БИР АЛЛАМ!

ҺӘР ЭШЕМНЕ

СИННӘН БАШЛЫЙМ-

ФАТЫЙХАҢНЫ

БИР АЛЛАМ!!!

====================

КИЛӘЧӘККӘ ЫШАНЫЧ.

КИЛЕР БЕР КӨН!!!БӘХЕТ ТАШЫП ЧЫГАР,

ОНЫТЫЛЫР САГЫШ-КАЙГЫЛАР.

САЛКЫН ЧИШМӘ БУЛЫП,ТАШЫП ЧЫГАР,

КАЙНАР ХИСЛӘР...КАЙНАР ТОЙГЫЛАР...

БЕЗНЕҢ ЯНГА АЛИҺӘЛӘР ТӨШӘР,

ХӨКЕМ ИТӘР ҖИРДӘ ТЫНЫЧЛЫК.

МӘЧЕ БЕЛӘН ЭТЛӘР ДУСЛАШЫРЛАР,

ЮККА ЧЫГАР ХУРЛЫК,КАНСЫЗЛЫК!

КИЛЕР БЕР КӨН!!!ЕРАК ЙОЛДЫЗЛАРДАН,

ҖИРЕБЕЗГӘ ЛӘЙСӘН СИБЕЛЕР!

БАР ДА БЕР ХОКУКЛЫ,ГҮЗӘЛ БУЛЫР,

ГӨЛЛӘР БЕЛӘН ТОРМЫШ КҮМЕЛЕР!

ЯЗМЫШЛАР

ПАР АККОШЛАР КҮРӘМ ТӨШЛӘРЕМДӘ,

ТӨНБОЕКЛАР БЕЛӘН СЕРЛӘШӘМ.

АЙЛЫ ТӨННЕҢ ТЫНЫЧЛЫГЫН ӨЗЕП,

ЙОЛДЫЗЛАРГА КАРАП ЭНДӘШӘМ!

АЧЫ САГЫШ  МИНЕ АЯМАДЫ-

ЯЗМЫШ МИНЕ САНГА СУКМАДЫ.

ЯҢА БӨРЕЛӘНГӘН ГОМЕРЕМНЕ,

ЯКАСЫННАН АЛЫП ТУКМАДЫ!

БИРЕШМӘДЕМ АЧЫ ЯЗМЫШЛАРГА,

ТЫРЫШТЫМ ТИК АЛГА БАРЫРГА!

ЮАНЫЧЫМ БУЛДЫ-САГЫШЫМНЫ

ЧИСТА БИТКӘ ЯЗЫП КАЛЫРГА!

ҮКЕНМӘДЕМ ЭШЛӘНМӘГӘН ЭШКӘ,
ЯЗМЫШЫМА КАРАП ЯНМАДЫМ!
ҮЗ ИҢЕМӘ ҮЗЕМ КАНАТ КУЕП,
ЕРАК ЙОЛДЫЗЛАРНЫ АЙКАДЫМ!

МИН БӘХЕТЛЕ!!!МИН БИТ МОҢЛЫ ДИМӘК,
МИН БИТ КИРӘК ТУГАН ХАЛКЫМА!
МОҢНАРЫМНЫ ЧӘЧӘМ БАР ҖИҺАНГА,
МӘХӘББӘТ ҺӘМ ТОРМЫШ ХАКЫНДА!

## ҖЫРЛАП ЯШИМ!

ТУГАН ЯКНЫҢ КАРА ТУФРАГЫНДА,
КҮКРӘП ҮСКӘН КӨЧЛЕ ИМӘНДӘЙ.
ТУЫП-ҮСТЕМ ҖЫРЛАП , ТАМЫР ҖӘЙДЕМ,
ЯШЕНЛӘДЕМ ЯКТЫ ЯШЕНДӘЙ.

АРТТА КАЛГАН ЯШЬЛЕК ЕЛЛАРЫМНЫ,
БАЛЫК БУАЛАРЫН САГЫНАМ.
ЯЛАН ТӘПИ ЙӨРГӘН СУКМАКЛАРЫМ
ЯШЕЛ ҮЛӘН БЕЛӘН САРЫЛГАН.

САЙРАР КОШЛАР МИҢА МОҢЫҢ БИРГӘН,
САЛКЫН ЧИШМӘ БИРГӘН КӨЙЛӘРЕН.

ҖЫРЛАП ЯШИМ ӘЛЕ ҺАМАН ДА МИН
ШИГЫРЬ  БУЛЫП АГА СҮЗЛӘРЕМ.

ЫҢГЫРАШЫП АУГАН КАЕН СЫМАН,
ӘГӘР СЫНСАМ КӨЧЛЕ ҖИЛЛӘРДӘ,
ҖЫРЫМ КАЛА, ШИГЫРЬЛӘРЕМ КАЛА
ЯЗМЫШЫМНЫ МИНЕМ СӨЙЛӘРГӘ.

## БАЛТЫРГАН АШЫ.

БАЛТЫРГАННЫҢ ЙОМШАК БӘБӘГЕННӘН
ӘНКӘМ ЯЗЫН ШУЛПА ПЕШЕРӘ.
ЙОМЫРКАЛАР СЫТЫП, УМАЧ УЫП,
АШКА КАЙМАК САЛЫП КИТЕРӘ

МАҢГАЙЛАРДАН ТИРЛӘР БӘРЕП ЧЫГА,
АШАГАНДА АНЫҢ ШУЛПАСЫН.
БЕЛЕП ТОРАМ, ТУГАН ҖИРДӘН БАШКА,
МОНДЫЙ АШНЫ АШАП БУЛМАСЫН.

ЯЗЛАР ҖИТСӘ, ТУГАН ЯККА КАЙТАМ
ОЧКАН ТОРНАЛАРГА ТАГЫЛЫП.
ТУГАН ЙОРТКА КЕРӘМ, ӘНИЕМНЕҢ
БАЛТЫРГАНЛЫ АШЫН САГЫНЫП.

БАР  ҖИРДӘ ДӘ АШ-СУ ТӘМЛЕ БУЛА,
АЧЫГУДАН ТӨШСӘҢ ӘЛСЕРӘП.
ТИК БАРЫБЕР, ТУГАН ҖИРДӘ ҮСКӘН
БАЛТЫРГАННЫҢ АШЫ ТӘМЛЕРӘК!

============

ПАР КҮГӘРЧЕННӘР.

САРАЙ КЫЕГЫНДА ГӨРГЕЛДӘШЕП,
ОЯ КОРДЫ ИКЕ КҮГӘРЧЕН.
ИКЕСЕ ДӘ БӘХЕТ КҮГӘРЧЕНЕ-
КАРДАЙ АП-АК!!!ЭНҖЕ ДИЯРСЕҢ!!!

ОЯ КОРЫП,БАЛА ЧЫГАРДЫЛАР,
ӨЙРӘТТЕЛӘР КҮКТӘ ОЧАРГА.
НИЧЕК КАРЧЫГАДАН КОТЫЛЫРГА,
БӨҖӘКЛӘРНЕ НИЧЕК ТОТАРГА.

БӘХЕТ БЕР ЯЛГЫЗЫ ЙӨРМИ ДИЛӘР!
ҺИЧ КӨТМӘСТӘН БӘЛА ТАРЫДЫ.
АТА КҮГӘРЧЕН ДӘ КИНӘТ КЕНӘ,
ЯВЫЗ КАРЧЫГАГА ОЧРАДЫ.

КАНАТЛАРЫ СЫНДЫ-БӘРГШЛӘНДЕ,
ЛЕП-ЛЕП КЕНӘ ТИПТЕ ЙӨРӘГЕ.
БЕР ЧОКЫРГА КИНӘТ БАРЫП ТӨШТЕ:

ҮЛЕ СЫМАН СҮНДЕ КҮЗЛӘРЕ.

АНА КҮГӘРЧЕН ДӘ ӨЗГӘЛӘНДЕ,
ӨЧ КӨН ЭЗЛИ-ҺАМАН ТАБАЛМЫЙ.
ҮЗЛӘРЕНЧӘ МОҢЛЫ АВАЗ БИРЕП,
ТИК ҖАВАБЫ ГЫНА ЯҢГЫРАМЫЙ.

СӨЮ КӨЧЛЕ!!!СӨЮ ҮЛЕМСЕЗ УЛ!!!
ТАПТЫ ПАРЫН-НАЗЛАП ТЕРЕЛТТЕ!
СЫНГАН КАНАТЛАР ДА ЯЛГАНДЫЛАР,
ТЕЛӘГЕНӘ СӨЮ ИРЕШТЕ!!!!

===

АНАЛАР КӨТӘ...

АВЫРУЛАР ТУЛГАН ПАЛАТАДА,
ЯЛГЫЗ КАРЧЫК ТӘРӘЗ ТӨБЕНДӘ.
ҺИЧ УРАМНАН КҮЗЕН АЛА АЛМЫЙ,
НЫК ТАУШАЛГАН ХАЛАТ ӨСТЕНДӘ.
КӨН ДӘ ТЫНЫЧ КЫНА ЕЛАП АЛА,
БЕРКЕМ БЕЛМИ АНЫҢ СӘБӘБЕН.
БЕРДӘНБЕРЕ-ГАЗИЗ УЛКАЕ ДА,
ТИК БЕР ГЕНӘ ТАПКЫР КИЛГӘНЕН.
ШУШЫ ХАЛАТНЫ ДА УЛ КИТЕРДЕ,
АСКА КАРАП КЫНА СӨЙЛӘШТЕ:
-ТАПОЧКАНЫ ОНЫТКАНМЫН,ӘНКӘЙ,

ИРТӘН КИТЕРЕРМЕН!”-ДИП КИТТЕ.

-ЯРАР,БАЛАМ,БИК ПОШЫНЫП БАРМА!

БЕР БАРАСЫ ҖИРЕМ ЮК МОНДА!

ҖӨН НОСКИЕМ,ЙОМШАК ЮРГАНЫМ БАР,

АШАУ,ЯТУ-БАРСЫ УРЫНДА!

БИК АРЫТКАН,БАЛАМ,БИК ЙОНЧЫТКАН,

ЯЛ ИТӘРМЕН ИНДЕ ИРКЕНЛӘП.

ЯВЫЗ ЧИР ДӘ БОГАЗЫМНАН АЛДЫ,

БЕР ХӘЛЕМЮК!БИГРӘК ЧИТЕН ЛӘ...”

ГАЗИЗ УЛЫ АВЫР СУЛЫШ АЛДЫ,

КАРАШЛАРЫН ЧИТКӘ БОРДЫ ДА:

-ҺИЧ БОЕКМА,ӘНКӘЙ,САЛӘМӘТ БУЛ!

ШУНДЫЙ КӨЧЛЕ УЛЫҢ БУЛГАНДА!

ТИК БИТ...КВАРТИРЫҢ...БУП-БУШ ТОРА,

ӘЛЛӘ...МӘЙТӘМ,ӘНКӘЙ,САТЫЙКМЫ?

СИНЕ ҮЗЕБЕЗДӘ ТӘРБИЯЛӘП,

ОНЫКЛАРЫҢ БЕЛӘН ТОТЫЙКМЫ?

СИНЕ КҮРЕП,АЛАР СӨЕНЕРЛӘР,

КИЛЕНЕҢ ДӘ УЙЛЫЙ ШУЛАЙРАК.

ЯРЫЙ,ӘНКӘЙ,ФАТИРЫҢНЫСАТАМ!

БЕЗДӘ ЯШӘВЕҢ ДӘ КУЛАЙРАК!”

ПАПКАСЫННАН КӘГАЗЛӘРЕН АЛЫП:

-МЕНӘ,ӘНКӘЙ,ЯЛЕ ИМЗА КУЙ!

ӘММА БЕРҮК АЧУЛАНА КҮРМӘ,

ДӨРЕС ЭШ БУ!ЯЛГАН НИКАКОЙ!”

НӘРСӘ ӘЙТСЕН ИНДЕ ГАЗИЗ АНА,
ТУГАН КАН БИТ,ХӘЛӘЛ ҖИМЕШЕ.
УКЫМЫЙЧА ГЫНА ИМЗА САЛДЫ,
БӘРЕП ЧЫКТЫ ШУЛЧАК КҮЗ ЯШЕ!
МЕНӘ ХӘЗЕР КӨН ДӘ УЛЫН КӨТӘ,
ДӨРЕС ХӘЛНЕ ГЕНӘ СИЗМИ ШУЛ.
КӨН ДӘ ТӘРӘЗӘДӘ АНЫҢ КҮЗЕ,
ТИК УЛКАЕ ГЫНА КИЛМИ ШУЛ.
КҮРШЕЛӘРЕ АНЫ ЮАТТЫЛАР,
КИЛЕР ӘЛЕ  УЛЫҢ ДИДЕЛӘР.
АНЫҢ ХӘЛЕН БАРСЫ АҢЛЫЙ ИНДЕ,
ҮЗЛӘРЕ ДӘ ШУНДЫЙ КӨНДӘЛӘР.
КАРЧЫК ИНДЕ ТӘМАМ ХӘЛСЕЗЛӘНДЕ,
СӘЕР ТӨШЛӘР КҮРӘ БАШЛАДЫ.
...УЛЫНА ДИП БОТКА ПЕШЕРӘ УЛ,
Ә УЛКАЕ КАШЫК ТАШЛАДЫ...
САБЫЕНЫҢ ТӘПИ БАСКАН ЧАГЫН,
ТӘҮГЕ ДӘРЕС,МӘКТӘП ЕЛЛАРЫН...
ҖИҢ ӨЗЕЛГӘН ЕРТЫК КҮЛМӘКЛӘРЕН,
ЧЕБЕШЛӘНГӘН АЯК-КУЛЛАРЫН...
ТАБИБЛАР ДА БАР КӨЧЛӘРЕН САЛА,
ТИК ӘЙТМИЛӘР АҢА ДӨРЕСЕН.
ЯМАН ЧИРДӘН АНЫҢ ЧИРЛӘГӘНЕН,
ЯНӘСЕ ДӘ БЕРКЕМ БЕЛМӘСЕН.
КАРЧЫК БЕЛМИ КАЙДА ЯТКАНЫН ДА,

ХАСТАХАНӘ ДИЕП УЙЛЫЙ УЛ.
ИШЕКТӘГЕ “ХОСПИС” ЯЗУЫНА,
БЕР ГЕНӘ ДӘ КАРАШ САЛМЫЙ ШУЛ.
УЛ БИТ БЕЛМИ ГАЗИЗ МАЛАЕНЫҢ,
КӨН ДӘ ШЫЛТЫРАТЫП ТОРГАНЫН.
ТАБИБЛАРНЫҢ ТЕҢКӘСЕНӘ ТИЕП,
ЯМАН СҮЗЛӘР АТЫП ОРГАНЫН.
-КИЧӘ ҮЛӘ ДИГӘН ИДЕГЕЗ БИТ,
НИШЛӘП ИСӘН,ҺАМАН ҮЛМӘДЕ.
МИНЕМ БИРГӘН АКЧАМ ҖИТМӘДЕМЕ?
ӘЛЛӘ ВАКЫТ СЕЗГӘ ҖИТМӘДЕ?”
КАРЧЫК ИСӘН!!!СОҢГЫ КӨЧЕН ҖЫЕП,
КӨТЕП ЯТАУЛЫН,САБЫЕН!
ИКЕ ЯШЬКӘ КАДӘР СӨТЕН ИМЕП,
КҮКРӘГЕНӘ КЫСКАН НАНЫЕН!
“КИЛЕР ӘЛЕ-Я ИРТӘГӘ КИЛЕР!”
ҮЗЕН-ҮЗЕ ШУЛАЙ ЮАТТЫ.
ИШЕК АЧЫЛЫР ДА,КИЛЕП КЕРЕР,
ИШЕКЛӘРНЕ КҮЗЛӘП ГЕЛ ЯТТЫ.
БЕРКӨН ИНДЕ БАР КҮӘТЕН ҖЫЕП,
КАРАВАТТАН ТОРЫП БАСТЫ ДА.
КӨЧ-ХӘЛ БЕЛӘН ГЕНӘ АТЛЫЙ-АТЛЫЙ
БАРЫП БАСТЫ ТӘРӘЗ КАРШЫНА.
“УЛЫМ КИЛЕП,МИНЕ КӨТЕП ТОРЫР,
МИН ТОРЫРГА ТИЕШ ШУШЫНДА!”

КҮККӘ КАРАП ЯЛВАРДЫ ДА АНА:

“КАЛДЫР ЗИНҺАР БАЛАМ ХАКЫНА!"

====================================

ТАЛЬЯН ГАРМУН

ТӨШЛӘРЕМДӘ БҮГЕН ӘТИЕМНЕҢ,

ГАРМУНЫНДА УЙНАП САТАШТЫМ.

ТӨЙМӘЛӘРДӘН ТӨЙМӘЛӘРГӘ БАСЫП,

КӨЙЛӘР ЧЫГАРЫРГА МАТАШТЫМ.

ИСКИТКЕЧ МОҢ !БАР АВЫЛГА ЧӘЧӘ,

ӘТИЕМНЕҢ ТАЛЬЯН ГАРМУНЫ.

ҖӘЙГЕ КИЧТӘ КАЕНЛЫККА ЧЫГЫП,

СИХРИ МОҢГА КҮМӘ АВЫЛНЫ.

КАЕННАР ДА ЕЛЫЙ-ЕЛЫЙ ТЫҢЛАЙ,

МОҢЛЫ КӨЙЛӘР ӘТИ ӨЗДЕРСӘ.

БАРЧА КӨЧЕН ЙӨРӘГЕНӘ ҖЫЕП,

"РАМАЙ"НЫ ҖЫРЛАП ҖИБӘРСӘ.

УЙНА ,ӘТИ, ТАЛЬЯН ГАРМУНЫҢНЫ

ЭРЕТ ӘЛЕ КҮҢЕЛ БОЗЛАРЫН!

БИЮ КӨЕН УЙНАП, БИЕТЕП АЛ-

АВЫЛЫМНЫҢ ШАЯН КЫЗЛАРЫН.

УЙНАП ҖИБӘР ӘТИ ГАРМУНЫҢНЫ,
БЕЗ ҖЫРЛАРБЫЗ СИҢА КУШЫЛЫП.
ЧАЛГЫ ТАВЫШЛАРЫН ТЫҢЛЫЙ-ТЫҢЛЫЙ,
ТАҢНАР АТКАН ЧАКТА СЫЗЫЛЫП.

ШИФАЛЫ ЧИШМӘ

-----------------------------------

ЯЗЛАР ҖИТКӘН САЕН СИҢА КАЙТАМ,
САБАНТУЙЛАР УЗГАН ВАКЫТТА.
КЫЯЛАРЫҢ ТАРИХ БЕЛӘН ТУЛЫ-
ҺИЧ ЮГАЛМАС КАЗЫП-ЧОКЫП ТА!
ЧИШМӘ СУЛАРЫННАН СИХӘТ АЛАМ,
ИСЕМЕ ДӘ АНЫҢ-ШИФАЛЫ!!!
КӨМЕШ АКЧА САЛЫП,СУЫН ЭЧӘМ
ҖАННАРЫМА БУЛА ФАЙДАЛЫ!!!
БИЕК ТАУ БАШЛАРЫН ЯРЫП ТӨШӘ,
ШОМЫРТ-ЧИКЛӘВЕКЛЕ КУРГЫДАН!
ГОРУР ИМӘННӘР ДӘ БАШЫН ЧАЙКЫЙ,
ИСЕРГӘННӘР СИХРИ ТОЙГЫДАН.

САГЫНАМ МИН ШУШЫ БОЛЫННАРДА,
ШАУЛАП УЗГАН САБАН ТУЙЛАРЫН.
ИЛҺАМЛАНЫП, ЯҢА КӨЧЛӘР АЛАМ
ЭЧСӘМ АНЫҢ САЛКЫН СУЛАРЫН.
ИСКӘ АЛАМ СИНДӘ УЧАК ЯГЫП,
ОЗАТТЫК БЕЗ МӘКТӘП ЕЛЛАРЫН.
УЙНАП-КӨЛЕП ТАҢНЫ КАРШЫЛАДЫК,
ҖЫРЛАП ХАЛКЫБЫЗНЫҢ ҖЫРЛАРЫН!!!

************

ДУСЛАРЫМ!

МОҢГА ТУЛДЫ ҖАНЫМ,КҮҢЕЛЛӘРЕМ,
МОҢГА ТУЛДЫ НАЗЛЫ ЯЗЛАРЫМ!
СЕЗ БУЛГАНГА ГЫНА МИН БӘХЕТЛЕ!
СЕЗНЕҢ БЕЛӘН ЯШИМ, ДУСЛАРЫМ!

КҮҢЕЛ ӨЧЕН БИК КҮП КИРӘКМИ БИТ!
ЧӘЧКӘ АТА КҮҢЕЛ КЫЛЛАРЫМ!
БАРЫ СЕЗНЕҢ ӨЧЕН БАГЫШЛАНА
ЙӨРӘГЕМДӘ ТУГАН ҖЫРЛАРЫМ!

БАРЫ СЕЗНЕҢ БЕЛӘН-МИН ҮЛЕМСЕЗ!
СЕЗГӘ БАГЛЫЙМ ЯЗГАН ҖЫРЛАРЫМ!
БӘХЕТ ДИҢГЕЗЕНДӘ КОЕНЫГЫЗ,
МЕҢ ЯШӘГЕЗ , ЯКЫН ДУСЛАРЫМ!

СЕЗ ДИП АТА МИНЕМ ТОРМЫШ ТАҢЫМ!
СЕЗ ДИП БАЛКЫЙ КҮҢЕЛ НУРЛАРЫМ!
ЙӨРӘГЕМДӘ БУЛГАН РӘХМӘТЕМНЕ,
ТАПШЫРСЫННАР ЯЗГАН ҖЫРЛАРЫМ!

СЕЗДӘН ТАБАМ ИЛҺАМ ЧИШМӘЛӘРЕН!
СЕЗДӘН АЛАМ ЯЗНЫҢ НАЗЛАРЫН!
РӘХМӘТ СЕЗГӘ ,ДУСЛАР,МЕҢ-МЕҢ РӘХМӘТ
БЕРГӘ БИЗИК ТОРМЫШ ЯЗЛАРЫН!

СЕЗДӘН БАШКА ТОРМЫШ КАРАҢГЫ ТӨН!
СЕЗДӘН БАШКА ЯЗЛАР КҮҢЕЛСЕЗ!
СЕЗНЕҢ БЕЛӘН ЙӨРӘК ЧӘЧКӘ АТА,
СЕЗНЕҢ БЕЛӘН МИН БИТ ҮЛЕМСЕЗ!!!

ИСКӘ ТӨШӘ....
ИСКӘ ТӨШӘ ГОРУР ЯЛАНГАЧНЫҢ***
КАРА УРМАННАРЫ...КЫРЛАРЫ...
ТАУЛАР АША САЛГАН АТ ЮЛЛАРЫ,
ГҮЗӘЛ ТАНЫП ҺӘМ ӘР БУЙЛАРЫ!
ИСКӘ ТӨШӘ АЛМА БАКЧАЛАРЫ!
ШАУ ЧӘЧӘКТӘ ТОРГАН ЧАКЛАРЫ!
НИК КҮҢЕЛДӘН КИТМИ ИКӘН ШУЛАЙ-
ГОМЕРЛӘРНЕҢ ЧӘЧКӘ ЧАКЛАРЫ!
ИСКӘ ТӨШӘ ГАРМУННАРЫ БЕЛӘН,

УРМАН АВЫЗЛАРЫ...УРАМНАР...

УСАЛ КИГӘВЕНЛЕ ПЕЧӘНЛЕКЛӘР,

ЫЖГЫРЫШЫП ТОРГАН БУРАННАР!

ИСКӘ ТӨШӘ ГҮЗӘЛ МИЗГЕЛЛӘРЕ!

ЯШЬЛЕГЕМНЕҢ-ТИЛЕ ЧАГЫМНЫҢ!

ҖЫРЛАРЫМ ДА МИНЕМ ШУЛ ХАКТА БИТ,

ЧАГЫЛЫШЫ МОҢЛЫ ҖАНЫМНЫҢ!

***ЯЛАНГАЧ АВЫЛЫ,БАЛТАЧ РАЙОНЫ,РБ

---

"МИН - ТАТАР!"

«Татар!» дигән данлы милләттән мин,

Туган илем, торган җирем бар.

Буыннарга җитәр моңнарым бар,

Горурланып әйтәм:»Мин-татар!»

Җир шарының барлык ноктасында,

Кайда барма-безнең татар бар!

Мәйдан гөрли татар булган җирдә,

Дулкынланып әйтәм: "Мин-татар!"

Тукай,Җәлил,Алиш илһам алган,

Туган телем – татар телем бар!

Гасырларга ишетерлек итеп,

Күкрәк сугып әйтәм: "Мин - татар!"

Казан ханлыгына һәм Болгарга,

Илтә торган нәсел җебем бар!

Хәнияләр,Салаватлар сыман,

Җырлый-җырлый әйтәм:”Мин - татар!”

Бабамнардан калган иманым бар,

Илһамланып атлар юлларым бар.

Ходаемнан ярдәм сорый-сорый,

Йолдызларга дәшәм: «Мин - татар!"

Илем өчен,газиз халкым өчен,

Ярсып тибәр кайнар йөрәк бар.

Мәңгелеккә җуелмаслык итеп,

Ак кәгазьгә язам: “Мин - татар!"

==================================

ТУГАН ТЕЛЕМ!!!

ТУГАН ТЕЛЕМ-МӘШХҮР ТУКАЙ ТЕЛЕ!

"ӘННӘМ!"-ДИЕП ТЕЛЕМ АЧЫЛГАН.

ИСЕМ КУШКАН ЧАКТА, КОРЫМ БЕЛӘН

МАҢГАЙЛАРГА ИСЕМ ЯЗЫЛГАН.

ТУГАН ТЕЛЕМ-ДАНЛЫ ТАТАР ТЕЛЕ!

БОЛГАР БАБАЛАРЫМ ИЛЕННӘН.

БОГАЗЫМА ПЫЧАК САЛСАЛАР ДА-

АЕРЫЛМАМ ТУГАН ТЕЛЕМНӘН.

ҖЫРЛАР ЯЗАМ ГҮЗӘЛЛЕКНЕ МАКТАП,

ҮЗ ТЕЛЕМДӘ-ТАТАР ТЕЛЕНДӘ!

ТАШЛЫЙ АЛМАМ ТЕЛНЕ, ТУГАН ҖИРНЕ
АЛТЫН КЫЙММӘТ ЧЫККАН ҖИРЕНДӘ!

ТУГАН ТЕЛЕМ МИНЕМ-ГАЗИЗ ТЕЛЕМ!
БӘХЕТЛЕ МИН ТАТАР БУЛГАНГА!
БӘХЕТЛЕМЕН ТУГАН ТЕЛЕМ БЕЛӘН!
"РӘХМӘТ!"-ДИМЕН БАРЛЫК ҖИҺАНГА!

============================================

" МИН БӘХЕТЛЕ!!!! "

МИН БӘХЕТЛЕ...ГАЗИЗ ТУГАН ИЛЕМ,
ИЗГЕ БИШЕК-ТУГАН ҖИРЕМ БАР!!!
МИН БӘХЕТЛЕ ШУҢА-КҮКРӘГЕМДӘ
ЯРСЫП ТИПКӘН КАЙНАР ЙӨРӘК БАР!

МИН БӘХЕТЛЕ...ГОМЕР БАСКЫЧЛАРЫМ
ТУЛЫ МИНЕМ ЯКЫН ДУСЛАРЫМ!!!
МИН БӘХЕТЛЕ...АЛАР БӘХЕТЕНӘ
БАГЫШЛАНА ЙӨРӘК ҖЫРЛАРЫМ!
МИН БӘХЕТЛЕ..ӘТИ-ӘНИ ИСӘН!!!
ГӨРЛӘП ЯШИ ДУСЛАР, ТУГАННАР!
БӘХЕТ ЭЗЛӘП БАРЫР ЮЛЛАРЫМ ЮК!
КАЙДА БӘХЕТ ӨЕП КУЙГАННАР?
МИН БӘХЕТЛЕ...КҮҢЕЛ ТУЛЫ МОҢНАР
ИЛҺАМ ЧИШМӘЛӘРЕМ УРГЫЛА!
МИН СӨЕНӘМ ДУСЛАР БӘХЕТЕНӘ-

ГОМЕРЕМ ДӘ МОҢЛЫ ҖЫР ГЫНА!!!

*****

КАРТАЙМЫЙК ӘЛЕ...

Бер яшьлектә,бер картлыкта диләр,
Яшәп калыйк дуслар,гөрләтеп!
Безнең арттан гөлләр үсеп калсын,
Йөрәкләрдә ялкын дөрләсен!

Яшь кызларны күрсәк,йөрәк әле
Чәчәк ата көзге кичләрдә!
Гомерләр бит шундый асыл мизгел,
Яратмыйча,безгә нишләргә?

Бер яшьлектә,бер картлыкта диләр!
Яшьнәп калыйк,дуслар,көзләрдә!
Гомерләрнең чәчкә мизгелләре,
Калсын әле,саг(ы)нып сөйләргә!

Олайсак та-без картаймыйк әле!
Җырланмаган әле безнең җыр!
Күңелләрдә кайнар утлар яна,
Сүнгән учакларны кабызыр!

==========================

МОҢСУЛАНМА!

-------------------------------------

Көзләр моңсу диеп моңсуланма,

Безнең күңелләрдә яз әле!

Көзләрнең дә була чуаклары-

Җырлыйсылар безнең бар әле!

Өзгәләнмә салкын җилләр булып,

Язгы,назлы җилдәй ис әле!

Йөрәгеңнән ташкан җылылыкны,

Миңа дустым бүләк ит әле!

Шаулап торган көзге гөлләр булып,

Йөрәгемдә чәчәк ат әле!

Моңсуланма-шаян көлә-көлә,

Сагыш капкаларын яп әле!

Төкер кайгыларга,моңсулыкка,

Бер караш сал назлы елмаеп!

Синең карашыңнан МОҢСУЛЫКның,

Томаннары китәр таралып!

Моңсуланма көзге иртәләрдә,

Моңсуланма көзге кичләрдә!

Таулар аша сизәм синең назны,

Ялкын өсти минем хисләргә!

============================

ӨЗГӘЛӘМӘ ЧӘЧКӘЛӘРНЕ....

(егет)

Кичтән генә чәчәк бүләк иттем,

Сөю хисләремне белдердем.

Карашыңнан синең исердем дә,

Сине куа-куа йөгердем!

(бергә)

Өзгәләмә чәчкәләрне...

Өзгәләмә үзәгемне...

Кирәк булса күкрәгемнән

Алып бирәм йөрәгемне!

(кыз)

Рәхмәт,җаным,йөрәк үземдә бар,

Бүләк ит син,миңа моңлы җыр!

Сөюләрдән шашкан йөрәгемнең,

Ялкыннары бәлки басылыр!

(бергә)

Өзгәләмә чәчкәләрне...

Өзгәләмә үзәгемне...

Өзеп әйтче күңелеңдә

Мин генә икәнемне!

====================

ЯКЫН ДУСКА.

Минем сагышларны таратырга,

Төрле-төрле юллар эзлисең.

Йөрәгемә сөю көчен өстәп,

Изгелекләр миңа телисең.

Рәхмәт дустым сиңа-

Мең-мең рәхмәт!!!

Сынган канатларны ялгыйсың!

Җылы,назлы карашлардан көчле,

Күңелләргә дәва бармы соң?

Якын дустым диеп хөрмәтлисең,

Серләреңне миңа сөйлисең.

Пыскып торган тормыш учагыма,

Кайнар ялкыннарың өстисең.

Рәхмәт дустым сиңа-

Мең-мең рәхмәт!!!

Син бит минем өмет йолдызым!

Уйларымда синең белән бергә,

Булырмын мин-калсам ялгызым!

Миңа салган назлы карашыңнан,

Чәчәк атты күңел хисләрем!

Мәңге яшә,дускай,минем хакка

Синнән башка мин бит нишләрмен?

Рәхмәт дустым сиңа-

Мең-мең рәхмәт!!!

Бәхет белән тулсын гомерең!

Ходай булсам- бүләк итәр идем,

Алтын мизгелләрен гомернең!

**************************************

КӨЗ  ҖЫРЫ.

Көзләр җитте инде...Алтын көзләр...

Тирә ягым сары алтын төсләр!

Күңелләрдә туа яңа җырлар,

Йөрәкләргә керә күркәм хисләр!

Көзләр җитте инде...Моңсу көзләр...

Моңсулыктан гына күңел нишләр?

Көз чәчәге сыман соңлап атты,

Тормыш бакчасында чәчәк-гөлләр!

Көзләр җитте инде...Сары көзләр...

Тәрәзәмә чиртә салкын җилләр!

"Соң түгелдер,әле соң түгелдер,

Илхамланып яшә,дускай!"-диләр!

Көзләр җитте инде...Гүзәл көзләр...

Гүзәллектән камашалар күзләр!

Җырлап яшим алтын көзләремдә,

Җырлый күңел...Туа яңа хисләр!

*************************************

*ЯНДЫРМА  ЙӨРӘГЕМНЕ!*

Җылап кына көзге яңгыр ява,

Салкын җилләр өзә үзәкне.

Язмышларга инде буйсынсак та,

Буйсындырып булмый йөрәкне!

Карама син, моңсуланып,

Өзмәче  үзәгемне!

Карашыңнан нур бөркелә,

Яндырма йөрәгемне!

Нигә генә сиңа гашыйк булдым?

Нигә күңел сиңа тартыла?

Мәхәббәттән качып,алга барам

Карамыйча алдым-артыма!

Бер карашың җитә кала,

Тыялмыйм хисләремне!

Үземне яндырсаң-яндыр,

Яндырма йөрәгемне!

Чәчәк ата күңел сине күрсәм,

Телгәләнә йөрәк,өзелә!

Инде ничә кабат гашыйк булып,

Кереп барам гомер көзенә!

Төшләремдә күрәм инде,

Ягымлы йөзләреңне!

Янсак,икәү бергә яныйк

Яндырма йөрәгемне!

## ИКӘҮ  ГЕНӘ

Ишетәсеңме,без җиһанда икәү!

Бары назлап җилләр исәләр.

Һәтта сандугачлар тынып калган,

Акмый тора салкын чишмәләр!

Әллә оҗмаһмы бу?Ышанмыйча

Шаркылдатып көлеп җибәрдең!

Кыңгыраудай чыңлап торган тавыш!

Бар Җиһанны гүя бизәдең!

Без Җиһанда бүген икәү генә!

Үпкәлибез һәм дә көләбез!

Бер-беребез өчен янып-көеп,

Гомер юлларыннан җиләбез!

Күктә тагын ике йолдыз янды!

Ике йолдыз-ике зөбәрҗәт!

Бер-беренә шаян күз кысышып,

Теләштеләр кайнар  мәхәббәт!

========================

ТАТЛЫ  ТӨШ.

Синең белән диңгезләрдә йөздек,

Ак болытлар белән ярышып.

Акчарлаклар җырын тыңлый-тыңлый,

Алтын комда яттык кызынып.

-----

Гөлчәчәкләр үскән яланнардан,

Көлә-көлә уздык чабышып.

Җиләс күләгәдә ял иткәндә

Сандугачлар торды сайрашып.

-----

Мине ирештереп,качып киттең,

Ә мин синең арттан йөгердем.

Тотып алып,назлы кочагыңда-

Ләззәт минутларын кичердем!

-----

Аклан тулы пешкән кура җиләк!

Бөрлегән һәм каен җиләге!

Җиләкләрен ашап туялмадык,

Исеп куйды яңгыр җилләре!

-----

...Күк күкри...Мин уяныП киттем...

Гөҗләп яҗгыр ява урамда.

Татлы төшем генә торып калды

Еракларда...Асыл чакларда!

=====================

ХАТЫН-КЫЗ

Хатын-кыз ул-БОЛЫНДАГЫ ЧӘЧКӘ!

Талгын гына искән ТАҢ ҖИЛЕ!

Зәңгәр күктә очкан ФӘРЕШТӘ ул!

Чык тамчысын эчкән ЯЗ ГӨЛЕ!

Хатын-кыз-ҖИЛ!БУРАН-ӨЕРМӘ ул!

Ялкын чәчеп яткан УТ-ВУЛКАН!

Кирәк чакта НАЗЛЫ ПЕСИ була,

Ачуланса инде-ул ЕЛАН!

Мәңге яшәгез сез-ФӘРЕШТӘЛӘР!

Назлап искән ак ТАҢ ҖИЛЛӘРЕ!

Һич сулмасын сезнең йөрәкләрдә,

МӘХӘББӘТ һәм СӨЮ гөлләре!!!

========================

КАЕННАР АРАСЫНДА!

-------------------------

ШАУЛАП ҮТТЕ БАЛАЧАГЫМ!

ЯШЬЛЕКТӘГЕ ТИЛЕ ЧАГЫМ!

КАЕННАР АРАСЫНДА!

ЧАКЫРСАҢ ДА КАЙТМАС ИНДЕ!

АТКАН ТАҢНАР АТМАС ИНДЕ!

С АГЫНЫП САРГАЙСАҢ ДА!

&&&&&&

ҖӘЙГЕ ГАРМУНЛЫ КИЧЛӘРЕМ!

БЕРЕНЧЕ СӨЮ ХИСЛӘРЕМ!

КАЕННАР АРАСЫНДА!

ТУЗГА КАЕП ЯЗГАН ИДЕК,

ВӘГЬДӘЛӘР БИРЕШКӘН ИДЕК

ҖӘЙНЕҢ  АЛСУ ТАҢЫНДА

&&&&&&

ОНЫТАЛМАМ ЯЗГЫ КИЧНЕ!

СӨЙГӘН ЯРЕМ КӨТӘ ТӨСЛЕ!

КАЕННАР АРАСЫНДА!

ЙӨРӘК НИЧЕК ТҮЗӘ ИКӘН?

ҮЗӘКЛӘР ӨЗЕЛӘ МИКӘН?

ЮКСЫНЫП САГЫНГАНДА!

&&&&&&

КАЙТАМ ИНДЕ ЯШЬЛЕГЕМӘ,

ТУЫП ҮСКӘН БИШЕГЕМӘ!

ТОРНАЛАРЫМ КАЙТСЫН ДА!

ХИСЛӘРЕБЕЗ ЧӘЧӘК АТЫР!

ЙӨРӘК ЙӨРӘКНЕ ЮАТЫР!

КАЕННАР АРАСЫНДА!

&&&&&&

====================

ЧӘЧӘК АТАМ.....

"...Атарга да өлгермәде,

Чәчәген койды гөлем!

"Ә син һаман чәчәк ат!"-ди

Ал таңда искән җилем..."

(җырдан)

Көн дә иртән торгач,Язмышыма

Үрсәләнә җаным,өзелә!

Тыңлашмаган аякларга карап,

Моңсу күзләр яшькә күмелә!

Юл чатында калган юлчы сыман,

Кайсы юлдан белмим барасын.

Нинди генә хисләр басар икән,

Йөрәгемнең тирән ярасын?

Янәшәдә генә Сагыш йөри!

Арттан калмый һич тә-күләгә!

Мине күрсә-Әҗәл читләп уза:

Бик иртә бит әле китәргә!

Әле минем яши башлаган чак!

Яңа "чәчәк аткан" чакларым!

Үкенергә һич тә вакыт калмый-

Илһам алып килде язларым!

"Бирешмә син язмыш җилләренә!

Чәчәк ат-дип,язгы таңнарда!".

Колагыма дәште назлыкай-Җил,

Яшәү көчен өстәп җаннарга!

Канат кагып,сайрый Сандугачым,

Аңа карап, Күңел моңлана!

Чәчәк ата Йөрәк дулкынланып,

Тормыш таңнарына соклана!

Кул селтәдем ачы Язмышка мин!

Сагышымны күккә болгадым!

Матур җәйге таңда чәчәк аттым,

Гүзәллеккә җырлар багладым!

Чәчәк атам...Күзләр берни күрми!

Ишетәм тик тургай моңнарын!

Күзне йомсам-гөлгә тула дөньям,

Канатланып туа җырларым!

===========================

САБЫЙЛАРГА БӘХЕТ ӨЛӘШИК!

Сөюнең бит татлы җимешләре,

Безнең газиз,сабый балалар!

Алар булса-тормыш бәрәкәтле,

Шат көлкегә тула урамнар!

Иртә таңнан кичке караңгыга,

Өлгәшмибез-тормыш куабыз!

Әле йокысы да ачылмаган,

Сабыйларны "садка куябыз"!

Акча җитми...Тормыш бик катлаулы!

Кичтән генә кайта сабыйлар.

Мониторга барып ябышалар,

Интернетка кереп уйныйлар.

Тормышның бар ачы-төчесен дә,

Татып үссен иде сабыйлар!

Булмас иде надан-куркаклар да,

"Текә" булмас иде малайлар!

Күреп үссен алар гөл үскәнен,

Тыңлап үссен тургай моңнарын!

Көлә-көлә йөгреп йөрсен алар,

Яшел чирәм баскан юлларын!

Бәхет белән тулган гаиләләргә,

Карап дуслар без дә тиңләшик!

Шау чәчәктә узсын балачагы-

Сабыйларга бәхет өләшик!

=============================

ГӨЛЛӘР БЕЛӘН СИНЕ КҮМӘР ИДЕМ!

Гөлләр белән сине күмәр идем,

Ал шәфакьле җәйге кичләрдә!

Синең белән булган асыл чаклар,

Керә хәзер бары төшләргә!

Күз алдымда-эссе челләләрдә,

Су коенып яткан күлләрем!

Зифа гәүдәң суда йөзгән чакта,

Алалмыйм да идем күзләрем!

Судан чыккач,кызу комга ятып,

Уйный идек анда шаярып.

Исеңдәме тәүге үпкән чагым-

Син чиядәй пештең кызарып!

Кереп кача идек урманнарга,

Чәчкә белән тулган тугайга!

Гөлләр белән күмә идем сине,

Шатлык чәчә идек тугайда!

Ай-һай эссе көннәр!!!Сулма иркәм!

Кайт яныма-сине көтәрмен!

Бар җиреңнән сине үбә-үбә

Гөлләр белән сине күмәрмен!

********************************

# АЛТЫН БАЛЫК

(хәзерге заман әкияте)

******************

## I

Салкын кышта күпләр балык тота,
Курыкмыйлар салкын-бураннан.
Таңнан торып,Корбан бабай әнә
Күлгә төшеп китте урамнан.
Бәке туңган...Бозын бәреп ватты,
Балыкларга тәмле җим салды.
Җайлап кына кармакларын сүтеп,
Утырырга урын сайлады.
Кайда булган бүген бу балыклар?
Ичмасам бер чиртеп карамый!
Суык һава өтә борыннарны,
Тик утыру болай ярамый!
Торып гимнастика ясап алды,
Арлы-бирле килде йөгереп.
Бәкегә соң килсә калкавычны,
Бер балык бит тора чирттереп!
Тартып алса-шундый матур балык!
Ялтырыйлар алтын тәңкәләр!
Канатлары алтын...Ә күзләре
Әйтерсең лә энҗе-мәрҗәннәр!
Телгә килде шулчак Алтын Балык,

Корбан бабай ушын югалтты!

"Ахырзаман җитте-балыклар да

Телгә килә!"-диеп баш ватты!

"Син изгелек эшлә бабай,миңа!

Җибәр мине зинһар күлемә!

Синең биш теләгең кабул булыр,

Сау-сәламәт кайтсам илемә!".

Озак уйламыча Корбан бабай,

Кире салды суга балыгын:

"Әйдә яшә,Алтынкаем минем!

Тик ашарга юк бит балыгым!".

Шулчак күлдә нидер улап алды,

Шартлый-шартлый бозлар сындылар!

Сикерешеп эре,зур балыклар,

Чиләгенә кереп тулдылар!

Шатлыгыннан ни эшләргә белми,

Чак-чак кайтып җитте өенә!

Олы чиләк тулган балык белән,

Карчыгы да нинди сөенә!

Кыздырылган балык ашап алгач,

Җайлап чыкты капка төбенә.

Күршесенә барын сөйләп бирде,

Энәсеннән алып җебенә!

"Юләрсең дә инде Корбан күрше,

Ышанасың икән балыкка!

Без бит хәзер-Галәм балалары,

Аптырыйм мин шушы халыкка!

Өең чүгеп бара-бер өй сора,

Бер "Җигули"кирәк йөрергә.

Трактор да булса-ишшу әйбәт,

Бакчаларны язын сөрергә!".

Көлеп кенә куйды Корбан бабай,

Күршесенең сизеп нәфесен.

"Ачуланма,күрше,тик мин үзем

Беләм миңа нәрсә кирәген!".

**************************

II

Язлар җитте...Кыр казлары кайтты...

Каңгылдашып туган күленә.

Алтын Балык көтте Корбан картны,

Бәхет теләп торган иленә!

Төште беркөн күлгә Корбан бабай,

Дәшеп алды Алтын Балыкны.

"Балыгым син безгә Тынычлык бир,

Кайгы урап узсын халыкны!

Мәхәббәт бир күркәм гаиләләргә,

Бәхет белән тулсын өйләре.

Барча халкым сау-сәламәт булсын,

Хезмәт булсын кылган эшләре!".

Алтын Балык картны тыңлап торган,

Ишетмичә кошлар сайравын.

Бераз уйга калып торганнан соң,

Әйтеп биргән аңа җавабын:

"Ярый,әйдә,гел синеңчә булсын!

Бүләк итәм сезгә Тынычлык!

Һәрчә йортка Бәхет өләшермен,

Барча җирдә булыр Татулык!

Янып сөйгәннәргә-саф Мәхәббәт,

Кайнар сөю бүләк итәрмен.

Хезмәт белән,эш-шөгыльләр белән,

Халыкларны сезнең күмәрмен!

Тагын бүләк итәр идем мин дә,

Әйтим әле үзең каршында.

Синең сыман изге җанлы картлар,

Бик күп булсын синең халкыңда!

Нәфесләрен тыя алган гына,

Алыр табып бушлай Бәхетне.

Яратсалар чын күңелдән әгәр,

Авыр эшне,изге Хезмәтне!".

******************************

Ашыгыгыз!

Ашыгыгыз Яшәп калырга!

Яшеннәрдәй Яшьнәп алырга!

Күккә ашып,йолдызлардай балкып,

Җырлый-җырлый алга барырга!

***

Ашыгыгыз Сөеп калырга!

Ләззәт минутларын татырга!

Сөю җимешләре-сабыйларның,

Игелеген күреп калырга!

***

Ашыгыгыз якты дөньяларда,

Изгелекләр эшләп калыгыз!

Якты Эзләр калсын бездән соңга,

Язмышларга каршы барыгыз!

***

Ашыгыгыз якын кешеләргә,

Изге сүзләр әйтеп калырга!

Балкып киткән нурлы Йөзләреннән,

Күзләреннән үбеп алырга!

***

Ашыгыгыз-Йөрәк Ялкын чакта!

Тормышларны Гөлгә күмегез!

Томырылып язын чәчәк атып,

Тирә якка Бәхет сибегез!

АШЫГЫГЫЫЫЗЗЗ!!!

======================

ҮБЕШЕГЕЗ!!!.....

Дус-туганнар белән очрашканда,

Күзләрегез яшкә чыланса!

Елый-елый дуслар үбешегез,

Сагынудан чара калмаса!

Җәйге болыннардан үткән чакта,

Мәхәббәттән күңел моңланса,

Җырлый-җырлый үбешегез,дуслар,

Таң кошлары сезгә сокланса!

Салкын суда сулар чәчрәтеп,

Уйнаганда йөрәк елмайса!

Көлә-көлә дуслар үбешегез,

Башка чара инде калмаса!

Без дөньяга яшәр өчен килгән,

Яшик әле сөеп-сөешеп!

Кайгы-шатлыкларны уртаклашып,

Яшик,дуслар,һәрчак үбешеп!

Ике минут гомер озынайта

Үбешсәгез бары бер тапкыр!

ШУҢА КҮРӘ ДУСЛАР СЕЗГӘ ӘЙТӘМ:

ҮБЕШЕГЕЗ КӨН ДӘ МЕҢ ТАПКЫР!

*************

=============================

ЯШЬ ЧАГЫМА КАЙТАМ!!!

Ярсу атка менеп,канатланып

Яшь чагыма кайтам ашкынып!

Яшьлегемдә-томан арасында

Калган мизгелләрне сагынып!

***

Сөйгән ярем көтә кебек һаман,

Яшьлегемдә-чишмә буенда!

Күз алдымда тора гүзәл сыны,

Болын чәчәкләре кулында!

***

Очып-очып яшь чагыма кайтам!

Ак болытлар белән ярышып!

Каенлыкка чыгам-каеннарым

Баш чайкыйлар хәлләр сорашып!

***

Ат атланып яшь чагыма кайтам,

Каршылагыз туган кырларым!

Яшьлегемдә сөйгән ярем белән,

Җырлый-җырлый узган юлларым!

***

Каршылагыз- тәүге мәхәббәтем!

Яшел шәлле каен кызлары!

Һичкенә дә хәтеремнән чыкмый

Яшь чагымның алтын еллары!

***

ирек

ТУЙ

Шатлык бөркеп назлы күңелләргә,

Туйлар уза ямьле җәйләрдә!

Йөрәк белән йөрәк кавышканы-

Бик күңелле җәйге кичләрдә!

Пар балдаклар киеп,вәгьдә биреп,

Кавышалар парлар мәңгегә!

Сөю учаклары суынмасын,

Саф мәхәббәт җитсен гомергә!

Җиз кыңгырау чыңлый!!!Атлар килә!!!

Туй килә-Туй!!!Каршы алыгыз!!!

Курчаклардай ике бәхетленең,

Сөенгәнен күреп калыгыз!

Йөрәкләрне җилдәй җилкендереп,

Туйлар уза туган якларда.

Тик ялгызлар гына сыкранышып,

Моңсулана шундый чакларда!

=======================

## ГҮЗӘЛ ЯШЬЛЕК.

Күзләремә кайнар яшьләр килә,

Искә алсам гүзәл яшьлекне.

Шәраб кайнагандай хисләр кайный,

Татлы төшләр өзә үзәкне.

Канатларым булса,кайтыр идем
Очып сиңа,гүзәл яшьлегем!
Сагындым бит тәүге мәхәббәтнең,
Иң татлы һәм назлы мизгелен!

Язгы ташкын булып кайтыр идем-
Юллар булса кире кайтырга.
Мин әзермен моңсу күзләрдә дә,
Томырылып чәчкә атырга!

Гүзәл яшьлек!!!Назлы үбешкәннәр!!!
Керә хәзер бары төшләргә!
Истән чыкмый икән тәүге сөю,
Сеңеп калган йөргән эзләргә!

Кәккүк тавышларын саный-саный,
Йөргән таңнар кире кайтырмы?
Гүзәл яшьлегемдә аткан сыман,
Алмагачлар чәчәк атырмы?

Бер кайтмасам-бер кайтырмын әле!
Көтеп тор син,гүзәл яшьлегем!
Көтеп тор син мине,мәхәббәтем,
Туган җирем-газиз бишегем!

======

ирек

==================================

РӘХМӘТ СИҢА....

Рәхмәт сиңа,миңа җырлар бүләк иттең!
Җырың белән күңелемне алып киттең.
Бар халыкның күзләренә яшьләр сиптең,
Уйларымда килеп битләремнән үптең!

*****

Моң агыла...Канатлана саф күңелләр!
Җыр-моң сөеп үтә шулай бу гомерләр!
Кайда калды синең җырлап биргән гөлләр?
Урладылар узып киткән шук мизгелләр.

******

Рәхмәт сиңа,миңа җырлар бүләк иттең!
Рәхмәт сиңа-бар дөньяга йолдыз сиптең!
Рәхмәт сиңа-күңелемә өмет керттең,
Моңың белән йөрәгемне әсир иттең!

*****

Җыр яңгырый...Тасмалардан көй агыла...
Көн дә торгач,сине тыңлыйм талгын гына!
Күз алдымда синең сының янәшәмдә-
Әйтерсең лә син җырлыйсың акрын гына!

====================

ирек

========================================

ТӘРӘЗӘДӘН КҮЗЛӘРЕҢНЕ АЛМА!

Тәрәзәдән күзләреңне алма,

Таң атканда кайтып җитермен.

Җәйге җилләр сыман назлап кына,

Талгын гына тәрәз чиртермен.

===

Син кичләрен тәрәзәгә карап,

Көтәсеңдер мине...Мин сизәм!

Менә кайтам...Инде кайтам диеп,

Ничә еллар хәзер ил гизәм!

===

Тәрәзәдән төшкән ай нурында,

Укыйсыңдыр язган хатларны.

Мендәреңне кочып елыйсыңдыр,

Искә алып бергә чакларны!

===

Тәрәзәдән күзләреңне алма!

Бер кайтырмын җырлап җәйләрдә.

Тәрәзәңә килеп сызгырырмын,

Чәчәк исе килгән кичләрдә!

===

Бер кайтмасам,җаным,бер кайтырмын!

Таң алдыннан сайрар кош булып!

Зинһар тәрәзәңнән күзең алма,

Мин балкырмын тынмас моң булып!

===

ирек

---------------------------------------------------

ЮГАЛТТЫМ!

Мин бит сине әкияттән таптым!!!

Ерак йолдызлардан менеп алдым.

Чәчәк арасыннан куып җитеп,

Үземнеке итеп-үбеп алдым!

***

Күктән очып төште фәрештәләр,

Саф сөюгә шаһит булдылар.

Йөрәкләргә сөю угын атып,

Канатларын җилпеп тордылар!

***

Без-Мәңгелек!Без-бер Җиһан!

Без-бер Дөнья!

Кайнар хисләребез ярсыды!

Зәңгәр күктә бер ялгызы калган-

Урак Ай да үксеп елады!

***

Сине бит мин чәчәкләрдән таптым!

Томаннарга төреп юаттым!

Шул томаннар урладылар әллә-

Мәңгелеккә сине югалттым!

***

ирек

==================================

СЕРЛЕ ТӨН.

Төне буе кошлар сайраштылар,

Ай нурында канат кагынып.

Сине көтеп алдым шушы төндә,

Көтеп алдым сине сагынып.

Хисләребез кайнар вулкан иде...

Бер-беребез өчен үлдек без!

Без бит Икәү-Син дә һәм Мин,

Ләззәт диңгезләрен кичәбез!

Гашыйк аккошлардай каңгылдашып,

Үткәрдек бит җәйге төннәрне!

Чәчәкләрдән чык тамчысы тамды-

Чиркандырып назлы тәннәрне!

Күбәләкләр ирешенеп уйный,

Йолдызлар да серле елмая!

Шушы төн бит-безнең бәхет төне,

Иң серле төн булды дөньяда!

==========================================================

## ҖАНЫМ СИН!

Син җаныма сүнмәс учак яктың...
Йөрәгемдә кайнар ут-ялкын!
Күңелемә кунып,канат кактың-
Өмет утларымны кабыздың.
Күзләремдә якты нурлар уйный,
Күрсәм синең алсу йөзеңне.
Нишләр идем икән-бер ишетсәм:
"Җаным!Бу мин!"-дигән сүзеңне!
Йөрәкләрне буйсындырып булмый,
Күңелләрне булмый йөгәнләп!
Ерак җирләр аша мин Наз тоям,
Кайнар хисләр тоям иртәләп.
Кайчагында миңа якынсың син,
Тоям төсле кайнар сулышың.
Тик аралар ерак-хисләр якын,
Язмышлардан юктыр узмышым!
Синең белән генә мин бәхетле!
Синең белән генә мин солтан!
Йөрәгемә үтеп тамыр җәйдең-
Чәчәк аттың...Шуңа син соклан!
Синең белән генә мин үлемсез!
Синең белән генә мин яшим!
Ничек заманага яраклашыйм,
Максатыма ничек ирешим?

Бары синнән алам илһам нурын,

Күзләреңнән бәхет бөркелә!

Аңла шуны-исмең йөрәгемдә

Рәшә яңгыр булып сибелә!

====================

ҖИЛӘК ЧАКЛАР!

Җиләк пешкән яланнардан сине,

Төшләремдә эзләп йөредем.

Шул таңнарда югалтырмын диеп,

Томаннарга карап йөгердем!

Алсуланып пешкән җир җиләге!

Моңсуланып җырлый куралар.

Җиләк чаклар гына узып бара,

Усал җилләр арттан куалар!

Язмышларга каршы чыгыйк әйдә,

Кук томанлы ялган таңнарда.

Җырлыйк әйдә елар чакларда да,

Калыйк мәңге җиләк чакларда!

Бер-беребез өчен өзелешеп,

Алсуланып пешик сөюдән!

Мәхәббәттән дөнья корылган бит,

Гузәллектән...Наздан...Сөюдән...

======================

ДУСЛАРЫМ МИНЕМ!

Сөйләшергә сүзләр бетмәс сыман,

Сагындырган узган мизгелләр!

Заманалар үзгәрә бит диеп,

Үзгәрмәек әле ,егетләр!

Чикәләргә карлар сарылса да,

Без калабыз һаман яшьлектә!

Шундый дуслар була торып инде-

Сайрар микән тургай читлектә!

Сайрыйм,сайрыйм!Талпыныплар сайрыйм!

Гүзәллеккә һәрчак омтылам.

Дуслар тормышына сөенәм мин,

Дуслар уңышына таң калам!

Урап чыктым барча дөньяны мин,

Һич булмаган җирем калмады.

Су коендык барып, Ак күлдә дә

Тормыш күген илһам каплады.

Рәхмәт сезгә,минем якын дуслар!

Тормыш гөлләрегез сулмасын!

Сезнең салган гомер юлларына,

Беркайчан да кырау кунмасын!

Рәхмәт сезгә,минем якын дуслар!

Урап үтсен ачы язмышлар.

Җәйге томан сыман таралышсын,

Юкка чыксын кайгы-сагышлар!

=========================

КИЧҮ БУЙЛАРЫ!

Мин сагынам гүзәл балачакны!

Җанга дәва-чишмә суларын!

Учак ягып,балык тотып яткан,

Шундый хозур Кичү буйларын!

Тирә-ягы аның яшел урман,

Нинди генә кошлар сайрамый!

Әкияттән килгән мираҗ сыман,

Күз алдымнан һич тә киталмый!

Ак каеннар...Гүзәл төз чыршылар...

Кичүемне горур саклыйлар!

Яңгырыйлар кәккүк тавышлары,

Алар безгә гомер саныйлар!

Бер,ике,өч...алты,җиде,сигез...

Егерме биш...Утыз...Утызбиш!

Җитәр инде...Бу кадәрле гомер,

Гасырларга барып җитәр бит!

Балачакта йөргән сукмакларны,

Җуеп куйган тормыш җилләре.

Каеннарга салган билгеләрне-

Урлаганнар моңсу көзләрем!

Шундый гүзәллекне күңелләрдән,

Ничек итеп алып ташлыйсың?

Күз алдына басса томаннары-

Моңлы җырлар яза башлыйсың.

======================

## КӨЗЛӘР ҖИТӘ....

Тагын җитә инде моңсу көзләр!

Тагын үтте гүзәл җәйләрем.

Калалмадым назлы язларымда,

Моңсуланып узар кичләрем!

Таң атканда исә салкын җилләр,

Кырау төшә чәчәк-гөлләргә.

Җәйләремнән китмәм дигән идем,

Кереп барам инде көзләргә.

Кайда булган җырчы сандугачлар?

Ишетелми кәккүк моңнары.

Күңелләргә пыскып-пыскып керә,

Салкын көзнең моңсу таңнары!

Кырау төшсә төшсен,бәсләр кунсын,

Тик күңелләр генә сулмасын!

Көзләрнең дә гүзәллеге була,

Хыял канатларым сынмасын!

===========================

## СИНЕҢ КАРАШЫҢ.

Ничә еллар күз алдымнан китми,

Синең назлы,җылы карашың.

Төшләремдә күрәм,өннәремдә

Тоям назын синең карашның.

Таң атканда,шәфакь нурларында

Күрәм синең алсу йөзеңне!

Ай нурында Чулпан булып калкып,

Кул болгаган ул син түгелме?

Синең карашыңны тоям көн дә,

Төшсәм салкын чишмә буена.

Син яраткан җырларыңны кушам,

Нәзек билле таллар җырына!

Кайчагында,кинәт уянам да

Эзлим синең назлы карашың!

Тик мәңгегә һичкем алыштырмас,

Җылылыгын синең карашның!

============================

СИНЕҢ КҮЗЛӘР....

Синең күзләр...Зәңгәр миләүшәләр!

Җемелдиләр кояш нурында.

Наз бөркелә-сөю ташып тора,

Керфегеңнән җәйнең таңында!

*****

Синең күзләр-моңлы кара урман!

Карашларың җанны эретә!

Бер мизгелдә һуштан яздыра да,

Бер мизгелдә инде...терелтә!

*****

Синең күзләр-алар зәңгәр күкләр!

"Башлар китә!" син бер карасаң!

Назлы карашыңны сирпеп-сирпеп,

Чәчләреңне сыйпап тарасаң!

*****

Синең күзләр төнге йолдызлар бит!

Яктырталар барлык Галәмне!

Бар җаннары белән данлый алар,

Сиңа гашыйк булган Адәмне!

*****

====================================

ҖАВАПСЫЗ МӘХӘББӘТ.

Инде йөз кат гашыйк булганмындыр,

Инде йөз кат тәүбә ителде.

Мәхәббәттән җавап алалмагач,

Хыял канатларым өзелде.

***

Чын йөрәгем белән сөяр булдым,

Сөйгәнемә җырлар багладым.

Төшләремдә аны гына күрдем,

Йөрәгемдә мәңге саkладым!

***

Еллар узган инде...Тузан тузган,

Без атлаган чирәм юллардан.

Тик сагынып,һаман көтеп алам

Чәчкәләрне көләч язлардан.

***

Сөйдем сине...Гомер буе сөям!

Алышмадым сине ятларга.

Бер җавапсыз калган мәхәббәтем,

Гел чакыра гүзәл чакларга!

****************************************

КАЙДА СИН???

Кайда соң син,пар канатым минем?

Гомер буе сине көтәм мин!

Җәйге таңда,чыклы үләннәрдән

Синең килгәнеңне көтәрмен!

----------

Йолдызлардан әллә төшалмыйча,

Мәңгелеккә күктә калдыңмы?

Сине эзлим һаман-кайда соң син?

Карашларым сине табырмы?

-------------

Көн дә төшеп чишмә суын эчәм,

Таба алмыйм әмма дәвасын.

Каеннарны кочып,уйга чумам,

Пар канатым минем-кайда син?

--------------

Айга менәм,әгәр анда булсаң,

Күктә булсаң-күккә ашармын!

Әгәр тапсам,йөрәгемдә генә

Гомер буе сине саклармын!

============================

ТӨШЕМӘ КЕР.

БҮГЕН ТАГЫН ТӨШЛӘРЕМӘ КЕРДЕҢ,

БҮЛӘК ИТТЕҢ МИҢА ЧӘЧКӘЛӘР.

ЧӘЧЛӘРЕҢНӘН ҖИЛЛӘР ҮТЕП КИТТЕ

СИНЕ НАЗЛАП...СИНЕ ИРКӘЛӘП....

ЗӘҢГӘР КҮЗЛӘРЕҢНЕ СИРПЕП КЕНӘ,

ЙӨРӘК СЕРЛӘРЕҢНЕ СӨЙЛӘДЕҢ.

Ә МИН ЮЛӘР ЙОЛДЫЗ АРАСЫННАН,

КҮЗЛӘРЕҢНЕ СИНЕҢ ЭЗЛӘДЕМ..

ТАБАЛМАДЫМ ГОМЕР БУЕ ЭЗЛӘП,

СИНЕҢ КҮЗДӘЙ ЗӘҢГӘР КҮЗЛӘРНЕ.

АЛЫП ТАШЛАП БУЛМЫЙ ҺИЧ ЙӨРӘКТӘН

СИНЕҢ ӘЙТКӘН СОҢГЫ СҮЗЛӘРНЕ.

САГЫНДЫРЫП КЫНА ,СИРӘК КЕНӘ
ТӨШЕМӘ ДӘ ХӘЗЕР КЕРӘСЕҢ.
МИНЕМ ДӘ БИТ СИНЕ НАЗЛАП,СӨЕП
ИРЕНЕҢНӘН КИЛӘ ҮБӘСЕМ!

КАЙТМАСАҢ ДА КИРЕ ЯННАРЫМА,
НАЗЛЫ КАРАШЫҢНЫ САЛСАҢЧЫ!
САГЫНДЫРЫП,НАЗЛАП КӨЛӘ-КӨЛӘ
ТӨШЛӘРЕМДӘ ИРКӘМ, КАЙТСАҢЧЫ!

## ГӨЛНАЗЫМ!!!

Язын аткан чәчәк-гөлләрдәй,
Йөгерешкән шаян җилләрдәй.
Серле карап күзләремә,
Утлар салдың йөрәгемә.
Гөлназым, әй-й Гөлназым!
Язгы таңда искән җилем!
Йөрәгемдә чәчәк аткан
Мәхәббәтем...Назлы гөлем!

Чишмәләргә суга төшәсең...
Үзәгемне өзеп үтәсең...
Көнләштереп бакча гөлләрен,
Яулап алдың кемнәр йөрәген.

Гөлназым, әй-й  Гөлназым!

Кара  кашым...Карлугачым!

Күңелемдә  канат   каккан,

Сайрар кошым...Сандугачым!

Йолдызлардан төшеп калдыңмы?

Чишмәләрнең моңын алдыңмы?

Син бит- ХЫЯЛЫМ!!!ЙОЛДЫЗЫМ!!!

Сүнәм бит инде ЯЛГЫЗЫМ!!!

Гөлназым, әй-й Гөлназым!

Син чәчәкле, җылы язым!

Җырларымда чәчәк аткан

ГҮЗӘЛЛЕК һәм СӨЮ-НАЗЫМ!

==================================

СИРЕНЬ ТӘЛГӘШЛӘРЕ.

======================

КАРТОЧКАҢНЫ КӨН ДӘ АЛЫП КАРЫЙМ,

ӘЛЛӘ ШУНЫҢ БЕЛӘН ЮАНАМ.

БЕРЧӘ ЯНАМ...БЕРЧӘ ГАЗАПЛАНАМ...

КҮЗЛӘРЕҢНЕ КҮРГӘЧ-КУАНАМ!

ЯЗМЫШЛАРНЫ БЕРГӘ КУШАЛМАДЫК,

ӘЛЛӘ КАЙДА КАЛДЫҢ АДАШЫП.

ӘЛЛӘ МОГҖИЗАЛЫ ӘКИЯТКӘ-

СИН ЮГАЛДЫҢ КЕРЕП-ЯЛГЫШЫП.

ЯЗЛАР ҖИТКӘЧ,СИРЕНЬ ЧӘЧӘК АТКАЧ,
ЕЛ ДА КИЛӘМ ШУШЫ УРЫНГА.
ЮМАРТ ЯЗНЫҢ НАЗЛЫ ХУШБУЙЛАРЫ,
ИСЕРТТЕРЕП КЕРӘ БОРЫНГА!

ШУШЫ ТӘЛГӘШЛӘРДӘЙ КҮРКӘМ ИДЕҢ!
ЯШЬЛЕГЕМНЕҢ СИН БИТ ЙОЛДЫЗЫ!
ТӘЛГӘШЛӘР ДӘ СИНЕ ЮКСЫНГАННАР-
СИРЕНЬ ДА БИТ ХӘЗЕР ЯЛГЫЗЫ!

ТАҢНАР АТЫП,КӘККҮК КЫЧКЫРГАНДА
САНАДЫМ МИН ГОМЕР СӘГАТЕН.
КҮЗ АЛДЫМА КИЛДЕ СИНЕҢ КАРАШ,
КУЛГА АЛДЫМ СИРЕНЬ ТӘЛГӘШЕН.

СИНЕҢ ИРЕННӘРДӘЙ НАЗЛЫ ИСЛЕ!
БИГРӘК КҮРКӘМ СИРЕНЬ ТӘЛГӘШЕ!
ТАҢ ҖИЛЕДӘЙ КАЙТЫП КИЛЧӘЛЕ БЕР,
ТӘЛГӘШЛӘРНЕ КЫРАУ ӨЗГӘНЧЕ!
*********************************

СЫЛУКАЙ!

КӨТМӘГӘНДӘ ГАШЫЙК БУЛДЫМ!

ИНДЕ ХӘЗЕР НИШЛӘРГӘ?!
КОШЛАР БУЛЫП ОЧАР ИДЕМ-
КАНАТ ҮСМИ ИҢНӘРГӘ!
ӘЙ СЫЛУ КЫЗ! СЫЛУКАЙ!
ӨЗДЕРМӘ ҮЗӘГЕМНЕ!
ЯЗЛАРДАЙ САФ ЕЛМАЯСЫҢ,
ЯНДЫРМА ЙӨРӘГЕМНЕ!

СЫЕРЧЫКЛАР КАЙТТЫ ИНДЕ,
КАЙТ ТИЗЕРӘК, ЯНЫМА!
НАЗЫҢ БӘЛКИ ДӘВА БУЛЫР,
ЯРАЛАНГАН ҖАНЫМА!
ӘЙ СЫЛУ КЫЗ! СЫЛУКАЙ!
ҺИЧ ЧЫКМЫЙСЫҢ УЕМНАН!
ЙОЛДЫЗ БҮЛӘК ИТӘР ИДЕМ,
АНСЫ КИЛМИ КУЛЫМНАН!

БАШ ОЧЫҢДА САЙРАР ИДЕМ,
ҖЫРЧЫ САНДУГАЧ БУЛЫП.
КЕРФЕГЕҢӘ КУНАР ИДЕМ,
ЧЫК ТАМЧЫЛАРЫ БУЛЫП.
ӘЙ СЫЛУ КЫЗ! СЫЛУКАЙ!
СИХЕРЛӘДЕҢ ҖАНЫМНЫ!

ТӨШЛӘРЕМДӘ КҮРӘМ СИНЕҢ,

УЙНАП КӨЛГӘН ЧАГЫҢНЫ!

=================================

СИН - МӘҢГЕЛЕК!

Син-ҖИЛ,БУРАН,ДАВЫЛ-ӨЕРМӘ!

Син бит назлы,язгы ГӨРЛӘВЕК!

Син бит алсу КАЕН ҖИЛӘГЕ!

Син теш үтмәс каты ЧИКЛӘВЕК!

Болыннарда үскән ЧӘЧКӘ син!

Җырлап аккан салкын ЧИШМӘ син!

Йөрәгемдә янган ЯЛКЫН син!

Күңелемнән мәңге китмә син!

Син-ҖӘЙ,син-КЫШ,син-ЯЗ мәңгелек!

Син- моңсу КӨЗ!Тере гүзәллек!

Син-ОКЕАН!ДИҢГЕЗ!Син-ЙОЛДЫЗ!

Бар җиһанны сиңа тиңләрлек!

Керфегемә ТАМЧЫ булып там!

ТУРГАЙ булып сайра иң элек!

Син-бит ул МИН!Мин тик бары СИН!

Син-ТАБЫШМАК!Син бит-МӘҢГЕЛЕК!

## МИН МӘҢГЕГӘ СЕЗНЕҢ БЕЛӘН ДУСЛАРЫМ!

***********************************

Аерылса да тормыш юлларыбыз,

Аерым атсалар да таңнарым!

Җырларымда,кайнар моңнарымда,

Сезнең белән калам,дусларым!

Елгаларны кире боралмадык,

Яшьлектә дә калып булмады!

Дөньялыкта якты эзләр калды,

Безнең гомер зая узмады!

Тау белән тау очраша алмый!

Очраша безнең язмышлар!

Бер-беребез өчен җан бирәбез,

Юкка чыга кайгы-сагышлар!

Мин һәрвакыт сезнең белән яшим!

Сезнең белән йоклыйм-уянам!

Төшләремдә дуслар сезне күреп:

"Мин бәхетле!"-диеп юанам!

Сезнең белән хыялларда йөзәм,

Сезнең белән ташый моңнарым!

Үзем читкә китсәм-моңлы җаным,

Сезнең белән кала дусларым!

=======================

БЕЗ БИТ СӨЯР ӨЧЕН ЯРАЛГАН!

Әйдә әле,җаным,бергәләшеп,
Көлә-көлә ашыйк күкләргә!
Болытларны түшәк итеп ятыйк,
Өстән карап торган җирләргә!

Әйдә  әле,җаным,күккә ашыйк!
Йолдызларга сәлам җиткерик!
Фәрештәләр безне саклап йөртер,
Сөю ләззәтләрен  кичерик!

Күрәсеңме,җаным,җиребездә
Гөлләр чәчәк ата башлаган.
Чәчәк атсын сөю хисләребез,
Без бит сөяр өчен яралган!

Йолдызлардан йолдызларга очыйк,
Җир әйләнсен!Гөлләр шиңмәсен!

Без бит кайнар сөю җимешләре,

Сөю ялкыннары сүнмәсен!!!

УРМАН КЫЗЫ.

ТАҢ АТКАНДА-КОШЛАР САЙРАГАНДА

ЧИШМӘЛӘРГӘ СУГА ТӨШӘСЕҢ.

ҖЫРЛЫЙ-ҖЫРЛЫЙ НӘФИС ЧӘЧӘКЛӘРДӘН,

ТАКЫЯЛАР ҮРЕП КИЯСЕҢ.

АК КАЕННАР СИНЕҢ ӘХИРӘТЛӘР,

САЛКЫН ЧИШМӘ-ЯКЫН СЕРДӘШЕҢ.

КӨН ДӘ ТӨШЕП ЧИШМӘ БУЙЛАРЫНДА

БУШАТАСЫҢ ЙӨРӘК ХИСЛӘРЕН.

КОШЛАР САЙРАВЫННАН ТУКТАП ТОРА,

СИН ҖЫРЛАГАН ЧАКТА ӨЗДЕРЕП.

ТУРГАЙ-САНДУГАЧЛАР СУ ЭЧӘЛӘР,

ЧИШМӘ БУЙЛАРЫНА ТЕЗЕЛЕП.

МИН ДӘ ТӨШӘМ КӨН ДӘ ЧИШМӘЛӘРГӘ,

СИНЕҢ ҖЫРЛАГАННЫ ТЫҢЛАРГА.

БИК САГЫНСАМ СИНЕ, УРМАН КЫЗЫ,

ЧЫГАРМЫН МИН СИНЕҢ КАРШЫГА.

КАЙНАР КОЧАГЫМА АЛЫП СИНЕ,
АЛСУ ИРЕННӘРЕҢ ҮБӘРМЕН.
КАЕН ҖИЛӘК ТӘМЕН ТАТЫЙ-ТАТЫЙ,
МӘҢГЕ ҮЗЕМНЕКЕ ИТӘРМЕН.

--------------------------------------------------------------

КҮҢЕЛЕМӘ КИЛЕП КЕРДЕҢ.....

КӨТМӘГӘНДӘ КАРЛЫ БУРАН БУЛЫП,
КҮҢЕЛЕМӘ КИЛЕП КЕРДЕҢ СИН!
КӨЛӘ-КӨЛӘ ЧӘЧЛӘРЕҢНЕ ТАРАП,
ОЗЫН ТОЛЫМНАРЫҢ ҮРДЕҢ СИН.

***

ТАҢ АЛДЫННАН ИСКӘН ҖИЛЛӘР БУЛЫП,
ҮТЕП КЕРДЕҢ МИНЕМ КҮҢЕЛГӘ.
СИНЕҢ НАЗЛЫ,ҖЫЛЫ КАРАШЫҢНЫ,
МИН ОНЫТМАМ ИНДЕ МӘҢГЕГӘ!

***

ЯРСУ АРГАМАКТАЙ ЧАБЫП-ЧАБЫП,
КҮҢЕЛЕМӘ КИЛЕП КЕРДЕҢ ДӘ!
КЫҢГЫРАУДАЙ ЧЫҢЛАП КӨЛҮЛӘРЕҢ,
КӨН ДӘ КҮРӘМ ИНДЕ ТӨШЕМДӘ!

***

САНДУГАЧЛЫ,ГҮЗӘЛ ЯЗЛАР БУЛЫП,
КҮҢЕЛЕМДӘ МӘҢГЕ КАЛСАҢЧЫ!
АЛСУ ЧӘЧӘК АТКАН ГӨЛЛӘР БУЛЫП,

ЙӨРӘГЕМДӘ ЧӘЧӘК АТСАҢЧЫ!

***

ҮЗӘКЛӘРНЕ ӨЗГӘН МОҢЛЫ ҖЫРДАЙ,

КҮҢЕЛЕМӘ КИЛЕП КЕРДЕҢ СИН!

КИРЕ ЧЫГАР ЮЛЛАР ЯБЫК ИНДЕ-

ЙӨРӘГЕМДӘ ТАМЫР ҖӘЙДЕҢ СИН!!!

================================

ИСЕҢӘ ТӨШЕР!

КАЙГЫЛАРДАН ЙӨРӘК ТЫПЫРЧЫНСА, ТОРМЫШ КҮГЕН БОЛЫТ КАПЛАСА.

СИН ИСЕҢӘ ТӨШЕР-СӨЮ ТАҢЫН,

БЕР ЭШКӘ ДӘ КУЛЫҢ ТАРТМАСА.

ИСКӘ ТӨШЕР ШОМЫРТ ЧӘЧӘК АТКАН,

САНДУГАЧЛЫ ЧИШМӘ БУЙЛАРЫН.

ГАРМУН БЕЛӘН УЗГАН ЯШЬЛЕГЕҢНЕ,

ШАУЛАП УЗГАН САБАН ТУЙЛАРЫН!

ИСКӘ ТӨШЕР МИНЕМ БЕЛӘН БЕРГӘ,

КАРШЫЛАГАН АЛСУ ТАҢНАРНЫ.

ҮЛӘН КЫРЫП,ПОШКЫРЫШЫП ЙӨРГӘН,

КЫҢГЫРАУЛЫ ЧАПТАР АТЛАРНЫ!

ИСКӘ ТӨШЕР ҖӘЙГЕ УЧАКЛАРНЫ,

ТӘҮГЕ СӨЮ ТАШКАН ЧАКЛАРНЫ!

ТӘҮГЕ ТАПКЫР КАЙНАР ИРЕННӘРНЕҢ,

ОЧЫРАШКАН АЛСУ ТАҢНАРНЫ!

==========================================

ФӘРЕШТӘГӘ ТИҢ....

ТИҢЛӘМИМ МИН СИНЕ ЧӘЧКӘЛӘРГӘ ,
ТИҢДӘШ ТҮГЕЛ СИҢА ГӨЛЛӘРЕМ!
МИН БИТ СИНЕ ФӘРЕШТӘГӘ ТИҢЛИМ-
ИЗГЕ БУЛСЫН КЫЛГАН ЭШЛӘРЕҢ!

******

СИН ФӘРЕШТӘ БУЛСАҢ,КҮКТӘ ОЧЫП
ЙӨРЕР ИДЕҢ БӘХЕТ ӨЛӘШЕП!
ТАҢ АТКАНДА ГӨЛДӘН-ГӨЛГӘ КУНЫП,
КҮБӘЛӘКЛӘР БЕЛӘН СЕРЛӘШЕП.

*****

ҖАНЫМ ӘРНЕГӘНДӘ-ӘЛ ДӘ СИН БАР!
ЯРСУ ЙӨРӘГЕМНЕ БАСАРГА!
КҮҢЕЛЕМӘ МИНЕМ,ИЛХАМ БИРЕП,
КОШЛАР СЫМАН КАНАТ КАГАРГА!

******

ЧӘЧӘКЛӘРДӘЙ ГҮЗӘЛ БУЛСАҢ ДА СИН,
ЧИШМӘЛӘРДӘЙ МОҢЛЫ БУЛСАҢ ДА СИН!
МИН БИТ СИНЕ ФӘРЕШТӘГӘ ТИҢЛИМ,
ЙӨРӘГЕМНЕ ЯУЛАП АЛСАҢ ДА СИН!!!

=======================================

## БӘХЕТ КОШЫ.

БАРЧА ДУСЛАРЫМА БӘХЕТ ТЕЛӘП,
БӘХЕТ КОШЫН КҮККӘ ОЧЫРДЫМ!
"ДУСЛАРЫМА КҮКТӘН БӘХЕТ ЯУСЫН!
СӨЮ ТАШСЫН!"-ДИЕП КЫЧКЫРДЫМ!

*****

БӘХЕТЛӘРЕ ТУЛЫП,ТАШЫП ТОРСЫН!
КАЙГЫ ҖИЛЕ ИШЕК КАКМАСЫН!
ЯВЫЗ ЧИРДӘН,ЯМАН АФӘТЛӘРДӘН,
СЕЗНЕ,ДУСЛАР,АЛЛАМ САКЛАСЫН!

*****

ГАИЛӘЛӘР ТУЛСЫН СӨЮ БЕЛӘН,
ТУЫП ТОРСЫН ГАЗИЗ САБЫЙЛАР!
БАКЧАГЫЗДА ҺӘРЧАК КАНАТ КАГЫП,
МОҢНАР ЧӘЧСЕН ҖЫРЧЫ ТУРГАЙЛАР!

*****

МИН ОЧЫРДЫМ КҮККӘ БӘХЕТ КОШЫН!
БАР ДУСЛАРГА БӘХЕТ ТЕЛӘДЕМ!
ХОДАЕМА КӨН ДӘ ЯЛВАРАМ МИН,
КАБУЛ БУЛСА ИДЕ ТЕЛӘГЕМ!

*****

МӘХӘББӘТ КЫЙССАСЫ.

ЯШЬ ХАТЫНКАЙ

ИРГӘ СОРАУ БИРӘ:

-МИН МАТУРМЫ,ҖАНЫМ,ӘЙТ ӘЛЕ?

СӨЯСЕҢМЕ МИНЕ...СӨЙМИСЕҢМЕ?

ЗИННҺАР ӨЧЕН ҖАВАП БИР ӘЛЕ...

МИН ТАРТАММЫ СИНЕ...МИНЕМ БЕЛӘН,

КИЛӘМЕ СОҢ,ҖАНЫМ,БУЛАСЫҢ?

СИНЕ ТАШЛАП КИТСӘМ-ЕЛАРСЫҢМЫ?

НИНДИ УЙЛАР УЙЛАП ТОРАСЫҢ?”

ИРКӘЙ ҖИҢЕЛ ГЕНӘ ҖАВАП БИРДЕ:

-ЮК,СИН ҖАНЫМ,МАТУР ТҮГЕЛСЕҢ!

СӨЯРЛЕК ТӘ ТҮГЕЛ СИНЕ ХӘТТА,

СИН БИТ ГАДИ  КУРЧАК КЕБЕКСЕҢ!

МИН ТЕЛӘМИМ СИНЕ...СИНЕҢ БЕЛӘН,

КИЛМИ ӘЛЕ ЯКЫН БУЛАСЫМ.

ТАШЛАП КИТСӘҢ ИНДЕ ЕЛАМАМ ДА,

ЯЗМЫШЫМНАН КИЛМИ УЗАСЫМ!”

КҮЗЛӘРЕНӘ ЯШЬЛӘР БӘРЕП ЧЫКТЫ,

КАЯ БАРЫРГА ДА БЕЛМӘДЕ.

НИНДИДЕР КӨЧ АЧЫК ТӘРӘЗӘГӘ-
ХАТЫНКАЙНЫ АЛГА ЭТӘРДЕ.

ТӘРӘЗ ТУПСАСЫНА БАСКАН КИЛЕШ,
БИЕКЛЕККӘ...АСКА КАРАДЫ.
БАР ГОМЕРЕ АНЫҢ КҮЗ АЛДЫНДА,
ЗИҺЕННӘРЕ ШУЛЧАК ЧУАЛДЫ.

СИЗЕП КАЛДЫ ИР ДӘ,ХАТЫНЫНА
КУЛЫН СУЗЫП,АЛГА СИКЕРДЕ:
-ТУКТА,ҖАНЫМ!”-ДИЕП ӨЗГӘЛӘНДЕ,
ТАВЫШКАЕ ГЫНА ИШЕЛДЕ.

АКРЫН ГЫНА БАШЫН АРТКА БОРЫП,
ИРНЕҢ КҮЗЛӘРЕНӘ КАРАДЫ.
ҺӘМ БЕР КУЛЫН СУЗДЫ ИРГӘ ТАБАН,
ЕШ-ЕШ ҺАМАН ҮЗЕ ТЫН АЛДЫ!

-ӘЙЕ,ҖАНЫМ,МАТУР ТҮГЕЛСЕҢ СИН,
ТИК СИН МИНЕМ НАЗЛЫ ГҮЗӘЛЕМ!
СИНЕ ЯРАТМЫЙМ МИН,СИНЕҢ ӨЧЕН
ГОМЕРЕМНЕ БИРӘМ,ЧИБӘРЕМ!

СИНЕ ТЕЛӘМИМ МИН...СИННӘН БАШКА
БЕР МИНУТ ТА ҖАНЫМ,ТОРАЛМЫЙМ!

МИНЕ ТАШЛАП КИТСӘҢ-МИН ДӘ ҮЛӘМ!
ЯКТЫ ДӨНЬЯЛАРДА КАЛАЛМЫЙМ!”.

СИНЕҢ БҮЛӘК ИТКӘН БИЮ.

*********************

МИН ҺӘРВАКЫТ СИНЕ КӨТЕП АЛДЫМ!
СИНЕҢ НАЗЛЫ КАРАШЫҢНАН ЯНДЫМ!
СИН БИТ МИНЕМ КАЙНАР ЙӨРӘГЕМӘ,
ҖӘЙГЕ ЧЫК ТАМЧЫСЫ БУЛЫП ТАМДЫҢ!

===

БЕРВАКЫТ СИН БИЮ БҮЛӘК ИТТЕҢ!
НАЗЛАП КЫНА ИРЕНЕМНӘН ҮПТЕҢ!
ӘЙЛӘНДЕРЕП АЛДЫҢ МОҢЛЫ КӨЙГӘ,
МИНЕ ӘКИЯТКӘ АЛЫП КИТТЕҢ!

===

КӨЙ АГЫЛА..БИИ ГАШЫЙК ПАРЛАР!
КҮҢЕЛЕМДӘ ТУДЫ ҖЫЛЫ НАЗЛАР!
СИН ШУЛВАКЫТ БИЮ БҮЛӘК ИТЕП,
БҮЛӘК ИТТЕҢ МӘХӘББӘТЛЕ ЯЗЛАР!

===

КУЛЛАРЫМНЫ ИҢНӘРЕҢӘ КУЙДЫМ!
ҮЗЕМ ХЫЯЛ ДИҢГЕЗЕНӘ ЧУМДЫМ!
СИНЕҢ НАЗЛЫ,ҖЫЛЫ КАРАШЫҢНАН,
БЕР МИЗГЕЛГӘ УШЛАРЫМНЫ ҖУЙДЫМ!

===

НИК ШУЛЧАКТА МИҢА БИЮ БҮЛӘК ИТТЕҢ?
ЙӨРӘГЕМӘ НАЗЛАРЫҢНЫ СИПТЕҢ.
ГОМЕРЛЕККӘ ТИРӘН ЯРА САЛЫП,
БИЕГӘНДӘ ИРЕНЕМНӘН ҮПТЕҢ!

********************************

ҖӘЙ.

КҮРЕГЕЗЧЕ-ҖӘЙ БИТ! ҖӘЙ  МӘЛЕ!
ҖЫРЛАНМАГАН ҖЫРЛАР БАР ӘЛЕ!
АЛДА КӨТӘ ГҮЗӘЛ МОГҖИЗАЛАР,
ҖӘЙЛӘРЕҢДӘ ШАУЛАП КАЛ ӘЛЕ!

***

КАРАГЫЗЧЫ-ТЫШТА  ҖӘЙ ӘЛЕ!
ГОМЕР ҮТӘ-ЯШЬНӘП КАЛ ӘЛЕ!
ГӨЛБАКЧАГА КЕРЕП,КҮҢЕЛЕҢӘ
ЛӘЗЗӘТ МИНУТЛАРЫН АЛ ӘЛЕ!

***

БЕЛЕП ТОРАМ-ТЫШТА ҖӘЙ ӘЛЕ!
АХ!ЧАК КЫНА САБЫР ИТ ӘЛЕ!
АШЫКМАЧЫ КӨЗДӘ КАЛДЫРЫРГА,
ХОЗУРЛЫКНЫ ДӘВАМ ИТ ӘЛЕ!

***

САНДУГАЧЛАР КАНАТ КАКСЫННАР!
АЛСУ ГӨЛЛӘР ЧӘЧӘК АТСЫННАР!

ГАШЫЙКЛАР ДА БӘХЕТ ТӨННӘРЕННӘН,

ТАҢ АТКАНДА ГЫНА КАЙТСЫННАР!

***

БЕРАЗ ГЫНА САБЫР ИТ ӘЛЕ!

ҮТМӘ ҖӘЕМ!!!ЗИНҺАР КИТМӘЛЕ!

САНДУГАЧЛАР КЕРДЕ КҮҢЕЛЕМӘ,

БЕРАЗ ГЫНА ЗИНҺАР КӨТ ӘЛЕ!

=================================

ҖӘЙГЕ ИРТӘ.

ИРТӘН ТОРСАМ-БАЛАН ЧӘЧӘК АТКАН!

ТУЗГАНАКЛАР АК ШӘЛ ЯБЫНГАН!

ҖӘЙНЕҢ ГҮЗӘЛ ТАҢЫН МАКТЫЙ-МАКТЫЙ,

САНДУГАЧЛАР КАНАТ КАГЫНГАН.

===

ӘЙТЕРСЕҢ ЛӘ КЕМДЕР ХУШБУЙ СИПКӘН,

БАР ДӨНЬЯГА ХУШ ИС ТАРАЛА!

БАШЫН ЧАЙКАП,АК КАЕННАР ШАУЛЫЙ,

ЧУКЛАРЫННАН ЯКТЫ МОҢ ТАМА!

===

ТЕЛГӘ КИЛДЕ УРМАН ӘҮЛИЯСЕ-

"КҮПМЕ КАЛДЫ?"-ДИЕП СОРАДЫМ.

ЯШИСЕЛӘР БИК КҮП ИКӘН ӘЛЕ-

ЧИРЕК ГАСЫР МИҢА ЮРАДЫ!

===

ЧЫК ТАМЧЫСЫН ЭЧӘ САНДУГАЧЛАР,

БАЛ КОРТЛАРЫ ЭШКӘ ЯБЫШКАН!

ГАШЫЙК ПАРЛАР ӨЙЛӘРЕНӘ КАЙТА-

КАЙ АРАДА АЛАР КАВЫШКАН?

===

ТУРГАЙ МОҢЫ...КӘККҮК ТАВЫШЛАРЫ...

БЕЗНЕҢ ЯКТА ШУЛАЙ ТАҢ АТА!

ТУГАН ҖИРНЕҢ ҖӘЙГЕ ИРТӘЛӘРЕ,

ТӨШЛӘРЕМӘ КЕРЕП ЮАТА!

===

САНА КӘККҮК!САНА БЕЗГӘ ГОМЕР!

БЕЗ ЯШӘРГӘ КИЛДЕК БУ ҖИРГӘ!

БЕЗ МЕҢ БАЛКЫП,БЕР СҮНӘРГӘ ТИЕШ,

СӨЕЛЕРГӘ ҺӘМ ДӘ СӨЕРГӘ!!!

******************************

................

Мин сезгә ҖИЛ бүләк итәр идем,

Алып китсен сагыш утларын.

Барлык сорауларга җавап табып,

Балкытсын ул күңел нурларын!

Мин сезгә СУ бүләк итәр идем,

Аткан таңнар чыкка күмелсен!

Тынычлык һәм бәхет алып килсен,

Күгегезгә йолдыз сибелсен!

Мәңгелек УТ бүләк итәр идем,

Эретергә күңел бозларын.

Йөрәгегез ялкынланып янып,

Бүләк итсен сөю назларын!

Туган ҖИРнең туфрагын бирәм!

Иренмәгез-төреп салыгыз!

Туган якка тартып торыр сезне,

Һәрвакытта туган йортыгыз!

Сезгә ДУСЛЫК бүләк итәр идем,

Мин бит сезнең беләң!Белегез!

Чын күңелдән биргән бүләгемне,

Барчасын да ала күрегез!

==============================================

БЕРЕНЧЕ МӘХӘББӘТ.

САГЫШЛАРДАН ГАЗАПЛАНА ЙӨРӘК,

ХӘТЕРЛӘСӘМ ГҮЗӘЛ ЧАКЛАРНЫ.

КҮЗЛӘРЕМӘ КАЙНАР ЯШЬЛӘР КИЛӘ,

ИСКӘ АЛСАМ УЗГАН ЕЛЛАРНЫ.

ТИК КҮҢЕЛДӘ МӘҢГЕЛЕККӘ КАЛГАН

БЕРЕНЧЕ ҺӘМ ИҢ САФ МӘХӘББӘТ.

ҖИР АСТЫНДА ЯТКАН АЛТЫННАРДАН,

ЭНҖЕ-МӘРҖӘННӘРДӘН УЛ КЫЙММӘТ!

БЕРЕНЧЕ МӘХӘББӘТ ҮЛЕМСЕЗ УЛ!

БЕРЕНЧЕ МӘХӘББӘТ МӘҢГЕЛЕК!

ҖАНЫМ КӨЙГӘН,КАНАТЛАРЫМ ТАЛГАН,

ТИК СӨЮ БАР ҖАНГА ҖИТӘРЛЕК.

БЕРЕНЧЕСЕ,АЗАКЫСЫ БУЛДЫҢ,

СИНЕҢ БЕЛӘН ЯШИМ МӘХӘББӘТ!

СИНЕҢ БЕЛӘН ЙОЛДЫЗЛАРГА АШАМ!

СИНЕҢ БЕЛӘН КЫЛАМ ГЫЙБАДӘТ!

ТАГЫН СИҢА ГАШЫЙК БУЛДЫМ ИНДЕ...

ТАГЫН СИҢА ГАШЫЙК БУЛДЫМ ИНДЕ...

ТАГЫН СИН ДИП ТИБӘ ЙӨРӘГЕМ.

АЛ ЧӘЧӘКЛӘР ӨЗЕП БОЛЫННАРДАН,

КУЛЛАРЫҢА КИЛӘ БИРӘСЕМ.

ТАГЫН СИҢА ГАШЫЙК  БУЛДЫМ ИНДЕ-

КҮЗЛӘРЕҢНӘН КИЛӘ ҮБӘСЕМ.

БЕР ЕЛМАЮ ҖИТӘ  КҮҢЕЛЕМӘ,

ЙОЛДЫЗЛАРГА КИЛӘ МЕНӘСЕМ!

ТАГЫН СИҢА ГАШЫЙК БУЛДЫМ ИНДЕ-

МИНЕ СӨЙМИ-КИРЕ КАКСАҢ ДА.

РОЗАЛАР АЛЫП КУЛЛАРЫМА,

КИЛЕР ИШЕКЛӘРНЕ ЯПСАҢ ДА!

ТАГЫН СИҢА ГАШЫЙК БУЛДЫМ ИНДЕ-
АЧУЛАНСАҢ МИНЕ-АЧУЛАН!
СӨЮ ГӨЛЕМ ИНДЕ ҮСЕП ЧЫККАН,
КҮРКӘМЛӘНЕП ТАҢДА АЧЫЛГАН!

ТАГЫН СИҢА ГАШЫЙК БУЛДЫМ ИНДЕ-
ТАГЫН ТӨШЛӘРЕМДӘ КҮРӘМЕН.
КОЛАК ОЧЛАРЫННАН ҮБӘ-ҮБӘ,
СИНЕҢ ТОЛЫМНАРЫҢ ҮРӘМЕН.

СӨЮЕМӘ ҖАВАП БУЛМАСА ДА,
ТАГЫН СИҢА ГАШЫЙК БУЛДЫМ МИН.
КҮҢЕЛЛӘРЕҢ БЕЛӘН МӘҢГЕЛЕККӘ,
МИНЕМ ЙӨРӘГЕМДӘ КАЛДЫҢ СИН!!!
=======================================

ГӨЛЧӘЧӘГЕМ!

ЙӨРӘГЕМДӘ ШАУЛАП ЧӘЧӘК АТТЫ ,
КҮҢЕЛ ГӨЛЕМ,ТОРМЫШ БИЗӘГЕМ!
КАРАШЛАРЫҢ НАЗЛЫ КОЯШ СИНЕҢ,
БАЛКЫП ЯШӘ,ГӨЛЕМ-ЧӘЧӘГЕМ!

НАЗЛЫ ҖИЛЛӘР БУЛЫП ТАҢ АТКАНДА,
БАШ ОЧЫМА КИЛЕП ИС ӘЛЕ!

ГӨЛЧӘЧӘГЕМ,МИНЕМ ГӨЛЧӘЧӘГЕМ!
КҮҢЕЛЕМӘ КИЛЕП КЕР ӘЛЕ!

КАЕНЛЫКТА ҖИЛӘК ПЕШКӘН  ИНДЕ!
МӨЛДЕРӘМӘ ТУЛДЫ ЧИЛӘГЕМ.
ИРЕННӘРДӘ КАЕН ҖИЛӘК ТӘМЕН,
КАЛДЫРСАНА ГӨЛЕМ-ЧӘЧӘГЕМ!

БЕЗ СӨЕШКӘН ЧАКТА КАЕННАР ДА,
ОЯЛЫШЫП КАРАП ТОРСЫННАР!
ГӨЛЧӘЧӘГЕМ,МИНЕМ ГӨЛЧӘЧӘГЕМ!
АЛАР БЕЗГӘ ШАХИТ БУЛСЫННАР!

"ЯРАТАМ!"-ДИП ӘЙТЕР ИДЕҢ ИНДЕ,
СИН БИТ ӨМЕТЕМ-КИЛӘЧӘГЕМ!
ЙӨРӘГЕМДӘ ГӨРЛӘП ЧӘЧӘК АТКАН,
МӘХӘББӘТЕМ,ГӨЛЕМ-ЧӘЧӘГЕМ!

ЧЫК ТАМЧЫСЫ БУЛЫП,АЛЛАРЫМА,
КОЕЛСАЧЫ ҖӨЙГЕ ТАҢНАРДА!
ГӨЛЧӘЧӘГЕМ,МИНЕМ ГӨЛЧӘЧӘГЕМ!
МИНЕМ БӘХЕТ СИНЕҢ КУЛЛАРДА!
МИН СИНЕ ЯРАТАААММ!!!!

========================================

ЯШЬЛЕК ХАТАСЫ.

===============

ҺӘР ТАҢ САЕН АКРЫН ГЫНА АТЛАП,
БЕР ЯШЬ ХАТЫН КИЛӘ ЗИРАТКА.
БЕР КАБЕРГӘ ТУКТАП,ЧӘЧКӘ САЛА,
СУЛАР СИБӘ ЯЛГЫЗ НАРАТКА.

ИНДЕ ӨЧ ЕЛ ГАЗИЗ НАРАСЫЕ,
ЯТА ХӘЗЕР КАРА ГҮРЛӘРДӘ.
"ӘННӘ!","ӘННӘ!"-ДИЕП,ИМИ СОРАП,
ЕЛЫЙ-ЕЛЫЙ КЕРӘ ТӨШЛӘРГӘ.

СТУДЕНТКА ИДЕ...ТУГАН КӨННӘР,
ЮБИЛЕЙЛАР,ТУЙЛАР ГӨРЛӘДЕ.
ШУЛАЙ КИЛЕП,БӘБИ КҮТӘРГӘНЕН
УЛ ҮЗЕ ДӘ ШУЛЧАК СИЗМӘДЕ.

ИНДЕ СИГЕЗ АЙЛЫК АВЫР БУЛДЫ,
ВРАЧЛАРГА БАРЫП,АЛДЫРДЫ.
БАЛАСЫНА ГОМЕР БИРГӘН АНА-
ЯЗМЫШЫНА ГӨНАҺ САЛДЫРДЫ.

ЯКТЫ ДӨНЬЯНЫ ДА КҮРАЛМАДЫ,
ЯТА ХӘЗЕР КАРА ГҮРЛӘРДӘ.
"ӘННӘ!","ӘННӘ!"-ДИЕП,КУЛЫН СУЗЫП,
КӨЛӘ-КӨЛӘ КЕРӘ ТӨШЛӘРГӘ!

ИНДЕ КҮЗ ЯШЬЛӘРЕ КИБЕП БЕТТЕ,
КӨН ДӘ КИЛЕП ШУНДА  ЕЛАДЫ.
ТИК ЯШЬЛЕКТӘ БУЛГАН ХАТА ГЫНА,
КҮҢЕЛЕНӘ ТЫНГЫ КУЙМАДЫ!

СИНЕ ЭЗЛӘДЕМ!

САБЫЙ ЧАКТАН,ЯШЬЛЕК ЕЛЛАРЫМНАН,
СИНЕҢ ЭЗЛӘРЕҢНЕ ЭЗЛӘДЕМ.
ТАБАЛМАДЫМ,ЛӘКИН ҺАМАН ӘЛЕ,
КАЙНАР ӨМЕТЕМНЕ ӨЗМӘДЕМ!

***

КҮК КҮКРӘП,ЯҢГЫР ЯУГАН ЧАКТА,
ҖӘЙЛӘҮЛӘРДӘН СИНЕ ЭЗЛӘДЕМ.
СИН ЙӨГЕРЕП ЙӨРГӘН БОЛЫННАРДА,
ЧӘЧӘКЛӘРНЕҢ ИСЕН ИСНӘДЕМ!

***

КОЯШ БАТЫП,КҮКТӘ АЙ КАЛЫККАЧ,
ЙОЛДЫЗЛАРДАН СИНЕ ЭЗЛӘДЕМ.
СИНЕ УЙЛАП,СИНЕ ЭЗЛӘП ЙӨРЕП,
ГОМЕР ҮТКӘНЕН ДӘ СИЗМӘДЕМ!

***

ТӨШЛӘРЕМДӘ ТОМАН АРАСЫННАН,
ҖЫРЛЫЙ-ҖЫРЛЫЙ СИНЕ ЭЗЛӘДЕМ.

ГОМЕР БУЕ СИНЕ ЭЗЛӘРМЕН МИН,

ЙОМЫЛСА ДА МӘҢГЕ КҮЗЛӘРЕМ!

***

ХЫЯЛЫМДА,ТУГАН УЙЛАРЫМДА,

ҖЫРЛАРЫМДА СИНЕ ЭЗЛӘДЕМ!

УЙЛЫЙ КҮРМӘ-МИНЕ ЮГАЛТТЫМ ДИП,

МИН БАРЫБЕР СИНЕ ЭЗЛӘРМЕН!!!

========================================

СОҢГЫ КИЧ...

ТЕЛГӘЛИСЕҢ ЙӨРӘГЕМНЕ...КИТӘМ ДИСЕҢ....

ЧӘЧӘК АТКАН ГӨЛЛӘРЕМНЕ ӨЗӘМ ДИСЕҢ.

ЯЛГЫЗЫМНЫ КУЕ ТОМАН АРАСЫНДА,

КАЛДЫРАМ ДИП ҺАМАН ҮРТӘЛИСЕҢ!

............................

ГАЕБЕМ ЮК ҺИЧ КЕНӘ ДӘ СИНЕҢ АЛДА!

БЕР КАРАУДАН СИНЕ ЯРАТТЫМ!

"МИН-СИНЕКЕ!"-ДИГӘН СҮЗЛӘРЕҢӘ

ЧЫН КҮҢЕЛЕМ БЕЛӘН ЫШАНДЫМ.

...........................

БҮГЕН КИЛЕП СИҢА АКЧА ҖИТМИ!

ҖИТМИ САЛГАН КАЙНАР ХИСЛӘРЕМ.

КАЙДА ЮГАЛДЫ СОҢ ӨЧ ЕЛ БУЕ-

ЛӘЗЗӘТ АЛЫП ЯТКАН КИЧЛӘРЕҢ?

................................

ҮТЕНМИМ ДӘ СИҢА,ЯЛВАРМЫЙМ ДА!

КИТСӘҢ ИНДЕ ҖАНЫМ,КИТӘРСЕҢ!
ТИК КИРЕГӘ КАЙТЫР ЮЛЛАР БУЛМАС,
САГЫШЛАРДАН СУЛЫП КИБӘРСЕҢ.

.........................

БҮГЕН БЕЗНЕҢ САУБУЛЛАШУ ТӨНЕ!
БҮГЕН БЕЗНЕҢ  СОҢГЫ ТАТЛЫ КИЧ!
ТЫН ГЫНА КӨЙ ИШЕТЕЛЕП ТОРСЫН,
ШУНДЫЙ ГАҖӘЕП ТӨН!ИСКИТКЕЧ!

..............................

ШӘРАБ  ШАУКЫМЫНА ИСЕРЕШЕП,
ЙОЛДЫЗЛАРГА КАДӘР АШЫЙКЧЫ!
БЕР-БЕРЕБЕЗ ӨЧЕН ҮЛӘ-ҮЛӘ,
САФ ЧИШМӘЛӘР БУЛЫП ТАШЫЙКЧЫ!

=====

*******************************************

МИН КӨТӘМ!

*************

МИН ҺАМАН ДА СИНЕ КӨТӘМ ӘЛЕ,
УФТАНМЫЙЧА ГОМЕР ҮТКӘНГӘ.
ҮЛГӘНДӘ ДӘ СИНЕ КӨТӘРМЕН МИН,
АЧУЛАНМА МИНЕМ КӨТКӘНГӘ!

===

МИН КӨТӘМ-ТИК  ТҮЗСЕН ИДЕ ЙӨРӘК!
МИН КӨТӘМ-ТИК ҖАНЫМ СУЛМАСЫН!

МИН КӨТӘМ-ТИК ШУНДЫЙ ГҮЗӘЛ ЧАКЛАР,
СӨЙЛӘРЛӘРГӘ ГЕНӘ КАЛМАСЫН!

===

ГОМЕР БУЕ БАРЫ СИНЕ КӨТТЕМ,
ӘЛЕ ҺАМАН СИНЕ КӨТӘМ МИН!
СИНЕҢ САЛКЫНАЙГАН КҮҢЕЛЕҢӘ,
ӨМЕТ УТЛАРЫМНЫ СИБӘМ МИН

===

ТАҢ АТКАНДА,КОЯШ БАТКАН ЧАКТА,
АЙ НУРЫНДА СИНЕ КӨТӘРМЕН!
ЙӨРӘГЕМДӘ ТИК СИН!КИТКӘНДӘ ДӘ
ҮЗЕМ  БЕЛӘН АЛЫП КИТӘРМЕН!

=================

СИННӘН КАЛМАМ!!!

МИН ТӨШЕМДӘ ТАГЫН СИНЕ КҮРДЕМ!
БӘХЕТЕМӘ ДИЕП ЮРАДЫМ.
СИҢА БӘХЕТ, САФ МӘХӘББӘТ ТЕЛӘП,
ХОДАЕМНАН ЯРДӘМ СОРАДЫМ!

********

ГҮЗӘЛ ЧАКЛАР КАЛДЫ БИК ЕРАКТА,
КИЧЕЛӘСЕ СУЛАР КИЧЕЛГӘН!
СӨЮ ГӨЛЛӘРЕМ ДӘ СУЛЫП БАРА,
СӨЕЛӘСЕ ЯРЛӘР СӨЕЛГӘН!

********

ТИК КҮҢЕЛДӘН КИТМИ СИНЕҢ КАРАШ!

СИНЕҢ УЙЧАН ЗӘҢГӘР КҮЗЛӘРЕҢ!

ЕЛМАЙГАНДА,КАЕН ҖИЛӘГЕДӘЙ

КЫЗАРЫШКАН АЛСУ ЙӨЗЛӘРЕҢ!

**************

СИН ЕРАКТА ИНДЕ,ТОРМЫШЫҢДА

ТАМЫР ҖӘЙГӘН БАШКА  ГӨЛЛӘР БАР!

ОҖМАХЛАРДА КЕБЕК ЯШӘСӘҢ ДӘ,

САФ ТОЙГЫЛАР МОНДА ТАРТАЛАР!

********

ТОРГАН ҖИРЕҢ-АЛИҺӘЛӘР ИЛЕ!

АЛТЫН КОШЛАР ОЧА БАКЧАҢДА!

ТИК ҖАНЫҢДА ӘЛЕ ҺАМАН ЯШИМ,

КАЛМАСМЫН МИН-КАЙДА БУЛСАҢ ДА!

************

СОҢ ТҮГЕЛДЕР...

===

ИКЕБЕЗДӘ ТИБӘ ИКЕ ЙӨРӘК,

БЕРГӘ КУШСАК,БУЛЫР НИЧЕГРӘК?

СИКӘЛТӘЛЕ ТОРМЫШ ЮЛЛАРЫННАН,

ҮТӘРБЕЗМЕ ӘЛЛӘ ҖИҢЕЛРӘК?

----

ИКЕБЕЗДӘ ЯНА ИКЕ УЧАК,

ЯЛКЫННАРЫ ҖАННЫ КӨЙДЕРӘ!

ЯЗМЫШЫМНЫҢ САЛКЫН БУРАННАРЫ,

АРАЛАРГА КӨРТЛӘР ӨЙДЕРӘ!

----

ИКЕБЕЗДӘ КАЙНЫЙ ИКЕ ТОРМЫШ!

ТИК АТМЫЙЛАР  СӨЮ ГӨЛЛӘРЕ!

ПАРЫН ТАБАЛМАГАН АККОШЛАРНЫҢ,

КИБЕП БЕТМӘС МИКӘН КҮЛЛӘРЕ?

-----

СОҢ ТҮГЕЛДЕР...ЯРСУ ЙӨРӘКЛӘРНЕ

БЕРГӘ КУШЫП-БӨТЕН ИТӘРГӘ!

БЕЗ БИТ ИКӘҮ ТИК БЕР ЙӨРӘК БУЛЫП,

ЯШӘРГӘ ДӘ БЕЗГӘ ЯШӘРГӘ!!!

------

СОҢ ТҮГЕЛДЕР...СӨЮ ТАШКАН ЧАКТА!

СОҢ ТҮГЕЛДЕР ЯЛКЫН БАРЫНДА!

СОҢ ТҮГЕЛДЕР ӘЛЕ ОЧРАШЫП,

КАВЫШЫРГА ҖӘЙНЕҢ ТАҢЫНДА!!!

==================================

СИНЕҢ     БЕЛӘН!

Синең белән уянасым килә,

Назларыңны килә тоясым.

Сөю тулы,назлы карашыңда

Мәңгелеккә килә каласым!

Таң атканчы бер серләшер идек,

Бер уфтанып,берчә көлешеп.

Искә алып бәхет мизгелләрен,

Үпкәләшеп,аннан килешеп.

Синең назлы,җылы куенында

Көтеп җәйге таңнар атканын.

Бар йөрәгем белән сөяр идем,

Тыңлап кошлар канат какканын.

Ике йөрәк кайчан бергә тибәр?

Сине югалтудан куркам мин!

Ак төс кайчак кара булып куя,

Шул чакларың аңлый алмам мин!

Кайнар мәхәббәтне сакларга дип,

Көн дә ярдәм сорыйм Ходайдан.

Безнең тормыш-озын бер юл бит ул!

Без бит сөяр өчен яралган!

..................................................................

ОЧЫП КАЙТАМ!!!!

САГЫНДЫРГАН САБАНТУЙЛАР,

ЧИШМӘДӘГЕ САЛКЫН СУЛАР.

КАЙТАМ ӘЛЕ ТУГАН ЯГЫМА!

АЛСУ ҖИЛӘКЛЕ ҖӘЙЛӘРЕ,

МӘТРҮШКӘЛЕ БАЛЧӘЙЛӘРЕ.

СЕҢЕП КАЛГАН МИНЕМ ҖАНЫМА!

ОЧЫП КАЙТАМ БАЛАЧАККА,

ОЧЫП КАЙТАМ ТИЛЕ ЧАККА.

ТЫҢЛАРГА  ДИП ЧИШМӘ АГЫШЫН.

НИНДИ ГЕНӘ ХАТИРӘЛӘР,

НИНДИ ГЕНӘ ИСТӘЛЕКЛӘР,

БАСАР МИКӘН ЙӨРӘК САГЫШЫН?

ҖИЛӘКЛЕ ҖӘЙЛӘРНЕҢ ЯМЕН,

ИРЕННӘРДӘ ҖИЛӘК ТӘМЕН.

ОНЫТАЛМАМ ИНДЕ ГОМЕРГӘ!

ОЧЫП КАЙТАМ ҖӘЙЛӘРЕМӘ,

КАЙНАП ТОРГАН ЧӘЙЛӘРЕМӘ.

ОЧЫП КАЙТАМ УЗГАН ДӘВЕРГӘ!

===================================

УЙЛАНУ.

ЧӘЧКӘ БАЗАРЫННАН САБЫЙ МАЛАЙ,

ҖАЙЛАП КЫНА ЧӘЧКӘ САЙЛАДЫ.

САТУЧЫ КЫЗ КАРАШЛАРЫ БЕЛӘН:

"ТҮЛӘР  МИКӘН?"-ДИЕП УЙЛАДЫ.

ПЫЧРАК КИЕМ...КОРЫМЛАНГАН БИТЛӘР...

Ә КУЛЛАРЫ КАТЫП,СЫРЛАНГАН.

ЯНӘШӘДӘ ТОРГАН ХАТЫННАР ДА,

ЧИРКАНЫШЫП, БИТЕН КАПЛАГАН.

КЕСӘСЕННӘН БЕР УЧ ТИЕН АКЧА,

АЛЫП БИРДЕ ӨНСЕЗ КАССИРГА.

ЧӘЧКӘЛӘРЕН НАЗЛАП,ҮБӘ-ҮБӘ,

СОРАДЫ УЛ ПАКЕТ САЛЫРГА.

-КЕМГӘ АЛАСЫҢ БУ ЧӘЧКӘЛӘРНЕ,

СИНЕҢ МОНДА АКЧАҢ ҖИТМИ БИТ?

МАЛАЙ ТАЛГЫН ГЫНА ҖАВАП БИРДЕ:

-ӘНКӘЕМНЕҢ ТУГАН КӨНЕ БИТ!

РОДДОМДА САБЫЙ КӨТЕП ЯТА,

ТИЗДӘН ТАБЫР ИНДЕ,БИК ТИЗДӘН.

ӘНКӘЕМ БИТ МИНЕМ ТИК БЕРГЕНӘМ!

ЯТА ИНДЕ АНДА ХӘТСЕЗДӘН."

ЯНӘШӘДӘ ТОРГАН ИКЕ ХАТЫН,

ТЫҢЛАП ҺУШТАН ЯЗА ЯЗДЫЛАР:

"МЕНӘ ШУНДЫЙ ИЗГЕ САБЫЙЛАРНЫ,

ТАБАР ӨЧЕНБЕЗ БИТ-ХАТЫННАР!"

====================================

МИЛӘҮШӘЛӘР.

АЙ НУРЫНДА ҖЕМЕЛДӘШЕП,

СЕРЛӘШӘ  МИЛӘҮШӘЛӘР!

ГАШЫЙКЛАРДАН ОЯЛЫШЫП,

ТЫН ГЫНА СӨЙЛӘШӘЛӘР!

ТИЗДӘН ТАҢНАР АТАР ИНДЕ,

ЙОКЛАМЫЙ МИЛӘҮШӘЛӘР!

ИРЕННӘРНЕҢ БЕРСЕН-БЕРСЕ,

ТАПКАНЫН КҮЗӘТӘЛӘР!

ҖИЛ ИСТЕМЕ-КОШ БУЛДЫМЫ?

ТЫН КАЛДЫ МИЛӘҮШӘЛӘР!

Ә ГАШЫЙКЛАР ОНЫТЫЛЫП,

БЕР-БЕРСЕН СӨЕШӘЛӘР!

ТАҢ КОШЛАРЫ САЙРАГАНДА,

ЧАЙКАЛА МИЛӘҮШӘЛӘР!

БЕР-БЕРЕНӘ СӨЮ ХИСЕ,

ҖЫЛЫ НАЗ СИБЕШӘЛӘР!

ТАҢНАР АТЫП,КОЯШ ЧЫКТЫ,

СӨЕНӘ  МИЛӘҮШӘЛӘР!

ГАШЫЙКЛАРГА БӘХЕТ ТЕЛӘП,

МӘХӘББӘТ ӨЛӘШӘЛӘР!

========================================

ТУГАН ЯК МОҢНАРЫ.

ТУГАН ЯК МОҢНАРЫ,

ТУРГАЙЛЫ КЫРЛАРЫ,

УЙНАШАЛАР КОЯШ НУРЛАРЫ.

ЙӨРӘКЛӘРГӘ ҮТСЕН,

ҮЗӘКЛӘРНЕ ӨЗСЕН,

ХАЛКЫБЫЗНЫҢ МОҢЛЫ ҖЫРЛАРЫ!

"ТУГАН ЯК МОҢНАРЫ",

УЛЛАРЫ,КЫЗЛАРЫ.

БЕЗ ҖЫРЛАРБЫЗ МОҢЛЫ ҖЫРЛАРНЫ!

ҖӘЙГЕ ҖИЛДӘЙ ИССЕН,

САХРАЛАРНЫ КИЧСЕН.

ТУГАН ЯКНЫҢ СИХРИ МОҢНАРЫ!

КАРШЫЛЫЙСЫЗ БЕЗНЕ,

АЛКЫШЛЫЙСЫЗ БЕЗНЕ,

СЕЗ КУШЫЛЫП БЕЗГӘ ҖЫРЛАРСЫЗ!

КАЙДА ЯШӘСӘК ТӘ,

КАЙДА ҖЫРЛАСАК ТА,

ЯШӘП БУЛМЫЙ ЯКЫН МОҢНАРСЫЗ!

*****************************

Хатыннар нигә елый???

Сабый малай әнисеннән сорый:

-И,әнкәем,нигә елыйсың?

-Балакаем!Мин бит хатын-кыз ла!

Син аны һич аңлый алмассың!”

Газизкәен күкрәгенә кысып,

Тупылдатып Ана сөйде дә:

-Бу сорауга,балам,җавап юк ул!

Син тапмассың аны мәңгегә!”

Бераз үскәч,тынгы белмәс малай,

Әтисенә бирә соравын:

-И,әткәем,әйтче бер сәбәпсез,

Хатын-кызның нигә елавын!”

Ата кеше тирән сулыш алды,

Озак кына уйлап алды ул.

“Әйе,улым,хатын-кызлар кайчак

Бер сәбәпсез генә елый шул!”.
Еллар узды...Сабый ир-ат булды...
Нинди генә илләр гизмәде.
Тик хәтердә калган сорау гына,
Күңеленә тынгы бирмәде.
Йөрәгендә булган көчен туплап,
Ул сорарга булды Ходайдан:
-Әйтче,Аллам,нигә хатын-кызлар
Бер сәбәпсез генә елайлар?”
Аны тыңлап,Ходай уйга калды,
Һәм ул аңа бирде җавабын:
“Әйе,балам,хатын-кызны бит мин
Елый алсын өчен ясадым!
Көчле канат тактым иңнәренә,
Тормыш күген айкап очарга.
Эшчән куллар,ихтыярлы иттем
Заман җилен тыеп тотарга.
Нәфис түшләр куйдым,нарасыен
Күкрәгенә кысып,назларга.
Көчле рухлы һәм чыдамлы иттем-
Бәби тудырганда чыдарга!
Алдан барсын өчен күәт бирдем,
Кеше җанлы итеп ясадым.
Көчсезләргә һәм дә үксезләргә,
Ярдәм кылсын диеп багладым.

Изге күңел,саф мәхәббәт бирдем,

Бала багып,кеше итәргә.

Пар аккоштай тугры ярлар булып,

Тормыш диңгезләрен кичәргә.

Сезнең кабыргадан ясап куйдым,

Саклар өчен ирләр йөрәген.

Яман сүзләр атып,сүксәләр дә

Тешен кысып,түзү кирәген.

Заман җилләренә бирешмичә,

Бары алга-алга барырга!

Юл чатында ташлап калдырса да,

Ихтыярлы иттем барына!

Һәм ниһаять күз яшьләре бирдем,

Үксеп-үксеп елап алырга.

Авырлыкка түзеп,тешне кысып,

Елый-елый алга барырга!

Менә,улым,аңла инде хәзер,

Гүзәллекнең кайда икәнен.

Сылу гәүдә түгел,кием түгел-

Ә чыланган күзләр икәнен.

Хатын-кызның назлы йөрәгенә,

Яшьле күзләр-ишек ачкычы!

Мәхәббәтнең,янып сөюләрнең

Кайнар тойгыларын саклаучы!”.

******************************

ҮКСЕЗ ЯЗМЫШЛАР.

ЯЗ ЯЗЛЫГЫН ИТӘ АКРЫНЛАП,
БАР ТИРӘ-ЯК КАРДАН АЧЫЛА.
ТЫШТА УЙНЫЙ ДЕТДОМ БАЛАЛАРЫ,
УЕН БЕЛӘН САГЫШ ОНТЫЛА.

САФ КАРАШЛЫ,МОҢСУ КҮЗЛӘРЕНДӘ
АЧЫ ЯЗМЫШЛАРЫ ЧАГЫЛА.
ӘТИ-ӘНИЛӘРЕН КӨТӘ АЛАР...
КАРАШЛАРЫ ЮЛЛАР ЧАТЫНДА!

КӨТӘ АЛАР ГАЗИЗ ӘНКӘЙЛӘРЕН!
ЯЗ КИЛМӘСӘ-БӘЛКИ ҖӘЙ КИЛЕР!
КОЧЫП АЛЫП,КАЙНАР КОЧАГЫНДА
НАЗЛЫЙ-НАЗЛЫЙ СӨЯР ҺӘМ ҮБЕР!

БЕР КИЛМӘСӘ-БЕР КИЛЕРЛӘР ӘЛЕ,
ГОМЕРЛӘРЕ КӨТЕП УЗА ШУЛ!
ТИК ЙӨРӘКТӘ ТИРӘН ЭЗЛӘР КАЛА,
ЯЗМЫШЛАРДАН УЗМЫШ ЮКТЫР УЛ!

=====================================

ГӨРЛӘВЕКЛӘР АГА ҖЫРЛЫЙ-ҖЫРЛЫЙ!
СЫЕРЧЫКЛАР САЙРЫЙ ОЧЫНЫП.
ГОМЕР БУЕ ШУЛАЙ ҮТӘР МИКӘН,
ӘТИ-ӘНИЛӘРЕН САГЫНЫП!

ТАМАК ТА ТУК!!!ӨСТӘ ЯХШЫ КИЕМ!
БЕРГӘ УЙНАП,БЕРГӘ ҮСӘЛӘР.
ӘТКӘЙ-ӘНКӘЙ НАЗЫ ГЫНА ҖИТМИ,
ҮЗӘКЛӘРЕН ШУЛАЙ ӨЗӘЛӘР.

ЮЛ ЧАТЫННАН БЕРӘҮ КИЛЕП ЧЫКСА,
БАР ДА ЙӨГЕРЕШЕП ЧЫГАЛАР.
МОҢСУ КАРАШЛАРЫН СИРПЕП АЛЫП,
БАР ДА СИНЕ СЫРЫП АЛАЛАР.

"СИН БИТ МИНЕМ ӘНИ,ӘЙМЕ АПА?"
"СИН БИТ МИНЕМ ГАЗИЗ ӘНИЕМ!"
"ӘТИЕМӘ БИГРӘК ОХШАГАНСЫЗ!"
"СИН БИТ МИНЕМ БАТЫР ӘТИЕМ!"

ГОМЕРЛӘРЕ ҮТӘ САБЫЙЛАРНЫҢ...
АЛАР ГАИЛӘСЕН ЮКСЫНА!
КАЙБЕРӘҮЛӘР ТӨНЛӘ ЮРГАН КАПЛАП,
ЕЛАП АЛА ҮКСЕП,ТЫН ГЫНА!

АНА НАЗЫ.

ҖЫЛЫЙ-ҖЫЛЫЙ БУ ДӨНЬЯГА КИЛДЕК,

АНА НАЗЫ БЕЛӘН ҮСТЕК БИТ!

КҮКРӘК СӨТЕН ИМЕП ӘНКӘЙЛӘРНЕҢ,

ИЗГЕЛЕГЕН ГЕНӘ КҮРДЕК БИТ!

ТУГАНДА ДА АНА НАЗЫ КИРӘК!

АНА НАЗЫ КИРӘК ҮСКӘЧ ТӘ!

АНА НАЗЫ КИРӘК БУЙГА ҮСЕП,

ГОМЕР УРТАСЫНА ҖИТКӘЧ ТӘ!

АНА НАЗЫ КИРӘК ЯТИМНӘРГӘ!

САБЫЙЛАРНЫҢ ҖАНЫ УЯНСЫН!

САБЫЕНЫҢ ЙОШАК УЧЫН ТОЕП,

ҖЫЛЫ ХИСЛӘР КАБАТ КАБЫНСЫН!

БАРЧАБЫЗГА АНА НАЗЫ КИРӘК,

БЕРЕБЕЗ ДӘ НАЗСЫЗ КИЛМИБЕЗ!

ӘНКӘЙЛӘРНЕҢ ИСӘН САКЛАРЫНДА,

КАДЕРЛӘРЕН ГЕНӘ БЕЛМИБЕЗ!

***************************************

ЛӘЗЗӘТЕҢДӘ ҮЛСӘМ ИДЕ...

КҮЗ АЛДЫМДА СИНЕҢ КАРАШЛАРЫҢ...

КҮЗ АЛДЫМДА АЛСУ ЙӨЗЛӘРЕҢ!

ЙӨРӘГЕМӘ КАЙНАР УТЛАР САЛГАН,

"СӨЯМ!"-ДИГӘН НАЛЫ СҮЗЛӘРЕҢ.

КҮКРӘГЕҢӘ БАШЫМ КУЙСАМ ИДЕ,

КАЙНАР КУЕНЫҢДА СҮНСӘМ ИДЕ!

ИРЕННӘРЕҢ ТӘМЕН ТОЙСАМ ИДЕ,

ЛӘЗЗӘТЕҢДӘ СИНЕҢ...ҮЛСӘМ ИДЕ!

======

КӨТӘМ СИНЕ ЯЗЛАР ҖИТКӘН ЧАКТА,

ТОРНАЛАРДАЙ ОЧЫП КАЙТ ИНДЕ!

НАЗЛЫ СУЛЫШЫҢНЫ БИК САГЫНДЫМ,

ЙӨРӘГЕМДӘ ЧӘЧӘК АТ ИНДЕ!

КЫСЫП АЛЫП, КАЙНАР КОЧАГЫМДА,

ЙӨРӘК ТИБЕШЕҢНЕ ТОЙСАМ ИДЕ!

ЗӘҢГӘР КҮЗЛӘРЕҢНЕҢ СЕРЕН ЭЗЛӘП,

ЛӘЗЗӘТЕҢДӘ СИНЕҢ...ҮЛСӘМ ИДЕ!

=======

КЫР КАЗЛАРЫ КҮЛЛӘРЕНӘ КАЙТТЫ,

КӘККҮКЛӘР ДӘ БИРДЕ ТАВЫШЫН.

ТИК ЙӨРӘГЕМ ҺАМАН СИНЕ КӨТӘ,

КҮҢЕЛЛӘРЕМ ТУЛЫ САГЫШЫМ.

ЯЗГЫ ҖИЛЛӘР БУЛЫП ИССӘҢ ИДЕ!

ЧИШМӘЛӘРДӘЙ ЧЫЛТЫРАСАҢ ИДЕ!

ЛӘЗЗӘТЕҢДӘ СИНЕҢ... СҮНӘ-СҮНӘ

БӘХЕТ ДИҢГЕЗЛӘРЕН КИЧСӘК ИДЕ!!!

================================================================

БӘХЕТ ТӨНЕ

ЙОЛДЫЗ БЕЛӘН ЙОЛДЫЗ СЕРЛӘШКӘНДӘ,

ЯННАРЫМА ОЧЫП КИЛДЕҢ СИН!

САФ СӨЮЕҢ СИНЕҢ ТАШЫП ТОРА,

БӘХЕТ ТӨНЕ БҮЛӘК ИТТЕҢ СИН!

ЕЛЛАР УЗДЫ...АГЫМ СУЛАР АКТЫ...

СИЗМӘДЕМ ДӘ УЗГАН ГОМЕРНЕ.

ОНЫТАЛМЫЙМ СИНЕҢ ТӘҮГЕ ТАПКЫР,

БҮЛӘК ИТКӘН БӘХЕТ ТӨНЕҢНЕ!

БӘХЕТ ТӨНЕ-ИҢ БӘХЕТЛЕ МИЗГЕЛ!

БӘХЕТ ТӨНЕ-УЛ БИТ МӘҢГЕЛЕК!

ТИК КҮҢЕЛДӘ КАЛГАН ХАТИРӘЛӘР,

БУЫННАРГА ҖИТӘ СӨЙЛӘРЛЕК!

**********************************

ОНЫТАЛМАССЫҢ....

ОНЫТАЛМАССЫҢ ДУСКАЙ БУ ЯЗЛАРНЫ
ЯЗЛАРЫҢНАН ТАПКАН НАЗЛАРНЫ!
МИНЕМ БЕЛӘН БӘЛКИ КАВЫШМАССЫҢ,
ТИК БАРЫБЕР МИНЕ ОНЫТАЛМАССЫҢ!

ЙӨРӘГЕҢНӘН АЛЫП ТАШЛАСАҢ ДА,
ИКЕНЧЕ ЯРЬ  СӨЯ БАШЛАСАҢ ДА.
САГЫНМАСАҢ ИРКӘМ САГЫНМАССЫҢ,
СИН БЕРКАЙЧАН МИНЕ ОНЫТАЛМАССЫҢ!

ЙӨРӘГЕМДӘ ТАМЫР ҖӘЙДЕҢ ИНДЕ,
ТӨШЛӘРЕМӘ КЕРЕП КӨЛДЕҢ ИНДЕ.
МЕНДӘРЛӘРНЕ КАПЛАП ЕЛАМАССЫҢ,
ТИК СИН,ДУСКАЙ,МИНЕ ОНЫТАЛМАССЫҢ!

ЯЗ КОШЛАРЫ-СЫЕРЧЫКЛАР КАЙТЫР ИНДЕ,
АЛМАГАЧЛАР  АЛ ЧӘЧӘКЛӘР АТЫР ИНДЕ!
НАЗЛАРЫМНАН КАЧЫП КИТАЛМАССЫҢ,
СИН МӘҢГЕГӘ МИНЕ ОНЫТАЛМАССЫҢ!
========================================

ТАМЧЫГӨЛ.

КАЙТКАН САЕН, ТӘРӘЗ ТӨПЛӘРЕНДӘ

КӨЛЕП КАРШЫ АЛА ТАМЧЫГӨЛ!!!
ӘТКӘЙ-ӘНКӘЙ НАЗЫ БЕЛӘН ҮТКӘН,
БАЛАЧАГЫМ ГӨЛЕ - НАЗЛЫ ГӨЛ!

ИНДЕ КАРТАЙСАҢ ДА, САРГАЙСАҢ ДА,
ЯЗЫН БАЛКЫП, ЧӘЧӘК  АТАСЫҢ.
УЙНАП ЧАПКАН КОЛЫНЧАКЛАР СЫМАН,
БАЛАЧАККА КИЛӘ КАЙТАСЫМ!

ҮТӘ ТОРА ЕЛЛАР-АРГАМАКЛАР,
ҖИТЕЗ ГЕНӘ ЧАБЫП УЗАЛАР.
ЧИКӘЛӘРГӘ АК  ЭНҖЕЛӘР СИБЕП,
МАҢГАЙЛАРГА СЫРЛАР СЫЗАЛАР.

ШУЛ АТЛАРГА МЕНЕП, ҖИТЕЗ ГЕНӘ
БАЛАЧАККА  КИЛӘ  КАЙТАСЫМ.
ТӘРӘЗ  ТӨБЕНДӘГЕ  ТАМЧЫГӨЛДӘЙ,
ТОМЫРЫЛЫП ЧӘЧӘК  АТАСЫМ!
====================================

ЮГАЛТАСЫМ КИЛМИ!

КҮҢЕЛЕМДӘ ГӨЛЛӘР ЧӘЧӘК АТА,
ЙӨРӘК ТУЛЫ МОҢ ДА ХИС КЕНӘ.
МИН БИТ СИНЕ ЯЗМЫШЫМНАН ТАПТЫМ,
ЮГАЛТАСЫМ КИЛМИ ҺИЧ КЕНӘ!

...

ҖЫРЛЫЙ-ҖЫРЛЫЙ ГӨРЛӘВЕКЛӘР АГА,
СИН ДӘ ШУЛАЙ ҖЫРЛАП КЕРӘСЕҢ!
НАЗЛЫ КАРАШЫҢНЫ МИҢА ТӨБӘП,
КЫҢГЫРАУДАЙ ЧЫҢЛАП КӨЛӘСЕҢ!

...

ҺИЧКЕНӘ ДӘ ЮГАЛТАСЫМ КИЛМИ,
ҖЫРЛАРЫҢНЫ...АЛЧАК ЙӨЗЕҢНЕ...
ХОДАЕМА КӨН ДӘ ЯЛВАРАМЫН,
БИРЧЕ ДИМЕН, СИҢА ТҮЗЕМЛЕК!

...

АЕРМАСЫН БЕЗНЕ АЧЫ ЯЗМЫШ!
БЕЗ ЯШӘРГӘ КИЛГӘН ДӘВЕРГӘ!
СИНЕҢ БЕЛӘН ГЕНӘ МИН БӘХЕТЛЕ!
ЮГАЛТМАМЫН СИНЕ ГОМЕРГӘ!

## ӨМЕТ

ЯЗМЫШЫМА ЯКТЫ КОЯШ БУЛЫП,
КИЛЕП КЕРДЕҢ ТОРМЫШ КҮГЕМНӘН.
ИҢНӘРЕМӘ КӨЧЛЕ КАНАТ КУЙДЫҢ,
ТАРТЫП АЛДЫҢ ТОРМЫШ КҮЛЕННӘН.

СИН АЛИҺӘ!СИН ӨМЕТЕМ МИНЕМ!
СИН-ИҖАДЫМ,ИЛҺАМ УЧАГЫМ!

ЙӨРӘГЕМДӘ ЯЛКЫН КАБЫЗУЧЫ,
ЙОЛДЫЗЫМ СИН,ЯКТЫ МАЯГЫМ!

КЕШЕ ҖАНЫ ӨЧЕН КҮП КИРӘКМЕ?
ҖИТӘ АНЫҢ НАЗЛЫ КАРАШЫ.
СИН БИТ МИҢА ӨМЕТ БҮЛӘК ИТТЕҢ,
ЗИНҺАР КҮЗЛӘРЕМӘ КАРАЧЫ!

КҮКТӘ ТАГЫН БЕР ЙОЛДЫЗ КАБЫНДЫ!
МИНЕМ ЙОЛДЫЗ-ӨМЕТ ЙОЛДЫЗЫМ!
ДИМӘК МИН БӘХЕТЛЕ-МИН ӨМЕТЛЕ!
ДИМӘК МИН ДӘ КАЛМАМ ЯЛГЫЗЫМ!
*************************************

НИГӘ ШУЛАЙ ИКӘН?

НИГӘ ЯЗМЫШ БЕЗНЕ КЫЗГАНМЫЙЧА,
ЙӨРТӘ ИКӘН ТӨРЛЕ ЮЛЛАРДАН?
ИҢ КЫЕНЫ ЯМАН СҮЗ ИШЕТҮ,
ТУГАННАРДАН,ЯКЫН ДУСЛАРДАН.

КЫЕНЛЫКЛАР,АВЫРЛЫКЛАР БУЛДЫ,
КҮҢЕЛЕМДӘ АЧУ ТОТМАДЫМ.
БАР ГОМЕРЕМ БУЕ ИЛҺАМ АЛДЫМ,
ЙӨРӘГЕМӘ МОҢНАР ТУПЛАДЫМ.

КАЙЧАК МИННӘН КИЛЕП СРАСАЛАР,

КИЧЕР ИНДЕ ДУСКАЙ ДИСӘЛӘР.
ӘЙТЕП САЛАМ:"ДУСКАЙЛАРЫМ МИНЕМ!
КҮҢЕЛЕМДӘ МИНЕМ ЧӘЧКӘЛӘР!

АЧУ УРЫНЫНА ИЛҺАМ ҖЫЯМ,
САГЫШ УРЫНЫНА МОҢ АЛАМ!
ЧИСТА БИТКӘ ЯЗАМ ЧАЛ ТАРИХНЫ,
ТАҢ КОШЛАРЫ СЫМАН МОҢЛАНАМ!

УЙЛАМАГЫЗ МИНЕ ЯМАН ИТЕП,
НАЧАР ИТЕП ИСКӘ АЛМАГЫЗ.
КАЙГЫ-САГЫШЛАРДАН ҖЫР ЯСЫЙМЫН,
ГӨНАХ КҮЛЛӘРЕНӘ САЛМАГЫЗ!

ВАКЫТЫМ ЮК АЧУ ЙӨРЕТЕРГӘ,
УЙЛАРЫМА КЕРЕП, ЮГАЛАМ.
БАР КҮҢЕЛЕМ БЕЛӘН КҮКЛӘРДӘ МИН!
ЙОЛДЫЗЛАРГА АШЫП, МОҢ АЛАМ!".

=======================================

С А Г Ы Н А М.

ӘЙ САГЫНДЫМ, ЯЗНЫҢ ҖЫЛЫ НАЗЫН,
ӘЙ САГЫНДЫМ КОШЛАР САЙРАВЫН.
СЫЗГЫРЫШЫП ҖИЛЛӘР ҖЫРЛАГАНЫН,
ЯЗГЫ ТАШКЫННАРНЫҢ ШАУЛАВЫН.

ӘЙ САГЫНДЫМ ЯЗГЫ ЛӘЙСӘННӘРНЕ,
ТАМЧЫЛАГАН КАЕН СУЛАРЫН.
ТЕЗЕЛЕШЕП КАЙТКАН ТОРНАЛАРНЫ,
КАҢГЫЛДАШЫП ОЧКАН КАЗЛАРЫН.

ӘЙ САГЫНАМ ЯЗНЫҢ МИЗГЕЛЛӘРЕН,
ӘЙ САГЫНАМ ЯЗНЫҢ НАЗЛАРЫН!
ЯҢГЫРАГАН КӘККҮК МОҢЫ БЕЛӘН,
СЫЗЫЛЫП АТКАН ТЫНЫЧ ТАҢНАРЫН!

ӘЙ САГЫНАМ ЯЗНЫҢ ЧӘЧӘКЛӘРЕН,
УМЫРЗАЯ, ЛАЛӘ,ЛАНДЫШЛАР!
ТИЗДӘН ҖИТӘ ЯЗЛАР...КҮҢЕЛЛӘРДӘ
БЕТӘР МИКӘН ИНДЕ САГЫШЛАР?
========================================

БЕР КИЛЕРМЕН ӘЛЕ!

БЕР ОЧРАШЫРБЫЗ ӘЛЕ-ТИК ТИЗ БУЛМАС,
ТӨШЛӘРЕҢӘ КИЛЕП КЕРЕРМЕН.
СИНЕҢ ИРЕННӘРДӘЙ НАЗЛЫ,АЛСУ
АЛ ЧӘЧӘКЛӘР АЛЫП КИЛЕРМЕН.

КОЧАГЫМА АЛЫП ИРКӘЛӘРМЕН,
КҮЗЛӘРЕҢНӘН СИНЕҢ ҮБӘРМЕН.
ЙӨРӘГЕҢӘ ҮТЕП КЕРЕРМЕН ДӘ:
"СИН-МИНЕКЕ МӘҢГЕ!"-ДИЯРМЕН!

БЕР КИЛМӘСӘМ,ИРКӘМ, БЕР КИЛЕРМЕН!
ӨМЕТЕҢНЕ,ЗИНХАР, ЮГАЛТМА!
ТАУ БЕЛӘН ТАУ ГЫНА ОЧРАШМЫЙ-
ОНЫТМА СИН,МИНЕ, ОНЫТМА!

КӨТМӘГӘНДӘ ҖИЛӘС ҖИЛЛӘР БУЛЫП,
ИШЕГЕҢНӘН КИЛЕП КЕРЕРМЕН.
СИНЕҢ ИРЕННӘРДӘЙ НАЗЛЫ, АЛСУ
РОЗАЛАР  БҮЛӘК ИТЕРМЕН!

**************************************************************************************************************************************

ИКЕ ЙӨРӘК.

ЯЗМЫШ БЕЛӘН ЯЗМЫШ ОЧРАША,
КОШЛАР БЕЛӘН КОШЛАР ПАРЛАША.
ТИК ТАУЛАРНЫ БУЛМАЙ ОЧРАШТЫРЫП,
БАР ТЕРЕКЛЕК ЯЗЫН КАВЫША.

КӨН БЕЛӘН ТӨН ТИГЕЗ ВАКЫТЛАРДА,
ЯЗНЫҢ ШУНДЫЙ ГҮЗӘЛ МИЗГЕЛЕ!
ОЧРАШТЫЛАР ИКЕ ЯЛГЫЗ ЙӨРӘК,
ИКЕ ГҮЗӘЛ АККОШ ШИКЕЛЛЕ.

ИКЕ ЙӨРӘК БЕРСЕН-БЕРСЕ ТАПТЫ!
БӘХЕТ ЯҢГЫРЫНДА КОЕНДЫ.
ВӘГЬДӘЛӘРЕН БИРЕП ТАШЛАШМАСКА,
БЕР-БЕРЕНӘ СЕҢДЕ-СЫЕНДЫ.

ИКЕ ЙӨРӘК БЕРГӘ ТИБӘ ХӘЗЕР,
МӘХӘББӘТЛЕ БУЛСЫН ЯЗЛАРЫ!

АК ЧӘЧӘКЛӘР БЕЛӘН ТУЛЫ БУЛСЫН,

АЛАР ГИЗГӘН ТОРМЫШ ЮЛЛАРЫ!

МӘХӘББӘТНЕ САКЛАГЫЗ!!!!!

МӘХӘББӘТ УТРАВЫ

ӘКИЯТТӘ ТҮГЕЛ, ЧЫНБАРЛЫКТА

МӘХӘББӘТНЕҢ БАРМЫ УТРАВЫ?

КЕМНӘР ЯШИ ИКӘН?НИЧЕК ИКӘН?

ТЫНГЫ БИРМИ ШУШЫ СОРАВЫМ!

***************

МИН СОРАДЫМ ҖИЛДӘН:"ҖИЛКӘЙ ӘЙТЧЕ!

СИН ЙӨРИСЕҢ ЕРАК ҖИРЛӘРДӘ!

МӘХӘББӘТНЕҢ УТРАВЫ БАРМЫ?

КАЙДА СОҢ УЛ?КАЙСЫ ИЛЛӘРДӘ?"

***************

СОРАВЫМНЫ ТЫҢЛАП ТОРГАННАН СОҢ,

ӘЙТЕП САЛДЫ МИҢА ҖИЛ-АГА:

"ДӨНЬЯЛЫКТА БАР УЛ АНДЫЙ УРЫН!

ТАҢ КОШЛАРЫ АНДА МОҢ БАГА!

****************

ОҖМАХ ҖИМЕШЛӘРЕ ПЕШЕП ТОРА,
ГАШЫЙКЛАРГА УРЫН ҖИТӘРЛЕК.
БЕРСЕН-БЕРСЕ ТАБЫП КАВЫШАЛАР,
ТОРМЫШЛАРЫ КҮККӘ ТИҢЛӘРЛЕК!

****************

АНДЫЙ ҖИРНЕ БАШКА КҮРГӘНЕМ ЮК,
ТӘГӘРӘШЕП ТУА САБЫЙЛАР!
БЕРСЕН-БЕРСЕ СӨЕП ҺӘМ СӨЕЛЕП,
ЯШИ БИРӘ СИНДӘЙ МАЛАЙЛАР!"

*****************

МИН ТҮЗМӘДЕМ:"ҖИЛКӘЙ!ӘЙТЧЕ ТИЗРӘК,
КАЙДА СОҢ УЛ-СЕРЛЕ УТРАУ?
ШУНДА БАРЫП, МИН ДӘ ЯШӘР ИДЕМ,
КҮҢЕЛЛӘРЕМ ТУЛЫ АПТЫРАУ!"

****************

"ӘЙ-Й УЛКАЕМ!СИНЕҢ ТУГАН ҖИРЕҢ,
ТОРГАН ҖИРЕҢ ТУРДА МИН ӘЙТӘМ!
КАЙДА СОҢ БАР ТУГАН ҖИРДӘН ГАЗИЗ,
ТУГАН ИЛДӘЙ МАТУР ҺӘМ КҮРКӘМ!
ЮК УЛ ,БАЛАМ!ТОРГАН ҖИРЕҢ АЛТЫН!
ИҢ КАДЕРЛЕ СӨЮ БИШЕГЕ!
ХЕЗМӘТ КЫЛЫП,БАЛА СӨЕП  ЯШӘҮ-
ШУЛ ТҮГЕЛМЕ-БӘХЕТ ИШЕГЕ!"

==================================================

КАЕННАР АРАСЫНДА!

-------------------------

ШАУЛАП ҮТТЕ БАЛАЧАГЫМ!

ЯШЬЛЕКТӘГЕ ТИЛЕ ЧАГЫМ!

КАЕННАР АРАСЫНДА!

ЧАКЫРСАҢ ДА КАЙТМАС ИНДЕ!

АТКАН ТАҢНАР АТМАС ИНДЕ!

С АГЫНЫП САРГАЙСАҢ ДА!

&&&&&&

ҖӘЙГЕ ГАРМУНЛЫ КИЧЛӘРЕМ!

БЕРЕНЧЕ СӨЮ ХИСЛӘРЕМ!

КАЕННАР АРАСЫНДА!

ТУЗГА КАЕП ЯЗГАН ИДЕК,

ВӘГЬДӘЛӘР БИРЕШКӘН ИДЕК

ҖӘЙНЕҢ  АЛСУ ТАҢЫНДА

&&&&&&

ОНЫТАЛМАМ ЯЗГЫ КИЧНЕ!

СӨЙГӘН ЯРЕМ КӨТӘ ТӨСЛЕ!

КАЕННАР АРАСЫНДА!

ЙӨРӘК НИЧЕК ТҮЗӘ ИКӘН?

ҮЗӘКЛӘР ӨЗЕЛӘ МИКӘН?

ЮКСЫНЫП САГЫНГАНДА!

&&&&&&

КАЙТАМ ИНДЕ ЯШЬЛЕГЕМӘ,

ТУЫП ҮСКӘН БИШЕГЕМӘ!

ТОРНАЛАРЫМ КАЙТСЫН ДА!

ХИСЛӘРЕБЕЗ ЧӘЧӘК АТЫР!

ЙӨРӘК ЙӨРӘКНЕ ЮАТЫР!

КАЕННАР АРАСЫНДА!

&&&&&&

=============================================================
=

АЛСУ ЧӘЧӘК!

БЕРЧАК МОГҖИЗАЛАР БАКЧАСЫНДА,

ГӨЛДӘЙ ХИС ИТӘРСЕҢ ҮЗЕҢНЕ!

СИНЕҢ ГҮЗӘЛЛЕККӘ СОКЛАНЫРЛАР,

ЯРАТЫРЛАР НАЗЛЫ ИСЕҢНЕ!

***

ЧЫК ТАМЧЫСЫ ЗӨБӘРҖӘТТӘЙ БАЛКЫЙ,

СИНЕ ТАЖДА-ҖӨЙГЕ ТАҢНАРДА!

СИНЕ КҮРГӘЧ,ИС-АКЫЛЫН ҖУЕП,

ТОТЫНАЛАР СИНЕ МАКТАРГА!

***

КҮЗ АЛДЫҢА КИТЕР-СИН АЛСУ ГӨЛ!

БАРЛЫК ЧӘЧӘКЛӘРНЕҢ ПАТШАСЫ!

ШАГЫЙРЬЛӘР ДӘ СИҢА ШИГЫРЬ БАГЛЫЙ,

МӘХӘББӘТНЕҢ СИН БИТ ТОТКАСЫ!

***

БЕРКЕМ СИҢА ЗЫЯН САЛА АЛМАС!

СИҢА БАРЫ КАРАП ҮТӘЛӘР!

ЯВЫЗЛАРДАН САКЛАП,ХОДАЙ СИҢА

БҮЛӘК ИТКӘН ОЧЛЫ ЭНӘЛӘР!

***

====================================

МИН ОЧАМ.....

******

ДУСЛАРЫМ СЕЗ МИНЕ ЮЛӘРЛӘНГӘН,

ИКӘН БУ ДИП УЙЛЫЙ КҮРМӘГЕЗ!

КАРТ КӨНЕНДӘ  БУ АГАЙНЫҢ ӘЛЛӘ

БАШЫ КИТКӘН ДИЕП КӨЛМӘГЕЗ!

***

ЮЛӘРЛӘНДЕМ,ДУСЛАР,БАШЫМ КИТТЕ!

МӘХӘББӘТТӘН...СӨЮ ХИСЕННӘН...

ТАҢДА ТОМЫРЫЛЫП ЧӘЧӘК АТКАН,

БАЛАН ЧӘЧКӘСЕНЕҢ ИСЕННӘН!

***

ЮЛӘРЛӘНДЕМ,ДУСЛАР,БАШЫМ КИТТЕ!

ҖӘЙГЕ ТАҢДА ГАШЫЙК БУЛДЫМ МИН!

САНДУГАЧТАЙ КАНАТЫМНЫ КАГЫП,

ЗИФА ТАЛГА БАРЫП КУНДЫМ МИН!

***

ҮЗЕМ ОЧАМ...ҮЗЕМ ИЛХАМЛАНАМ...

ЯКТЫ ЙОЛДЫЗЛАРДАН МОҢ АЛАМ!

ЙӨРӘГЕМДӘ БЕР ГӨЛ ЧӘЧӘК АТТЫ...

ШАТЛЫГЫМНАН ОЧАМ...МИН ОЧАМ...

***

О МӘХӘББӘТ!!!

==============================

УЙЛАНУ.

КАЙЧАГЫНДА ЙӨРӘК ҮРСӘЛӘНӘ,

КАЙДА БАРГАНЫН ДА ТОЙМЫЙМЫ?

ӘЛЛӘ УЛ ДА САГЫШ-ӘРНҮЛӘРДӘН,

ӨЗГӘЛӘНЕП ШУЛАЙ ҖЫЛЫЙМЫ?

*******

НӘРСӘ ҖИТМИ ИКӘН БУ ЙӨРӘККӘ?
АЛГА ЧАБА,ҺАМАН ТУКТАМЫЙ.
ЯРСУЫННАН ДУЛЫЙ АТЛАР СЫМАН,
ХУҖАСЫН ДА ХӘТТА ТЫҢЛАМЫЙ!

*******

БЕР КАРАСАҢ КӨЛӘЧ ЕЛМАЯ УЛ,
БӘХЕТЕННӘН БАРЫ МОҢ ТАМА!
БЕР КАРАСАҢ КӨЗГЕ МОҢСУ ТӨНДӘЙ,
УЙГА БАТЫП ӘЛЛӘ ТЫН КАЛА!

*******

БЕР КАРАСАҢ ЙӨРӘК ЧӘЧӘК АТА!
СӨЮ-НАЗГА ТУЛА КҮҢЕЛЛӘР!
ШУНДЫЙ ЧӘЧӘК АТКАН ЙӨРӘК БЕЛӘН,
ҮТСЕН ИНДЕ БЕЗНЕҢ ГОМЕРЛӘР!

**********

## КАЕН ҖИЛӘГЕ

***

ИНДЕ ЧИРЕК ГАСЫР ҮТЕП КИТКӘН,
КҮРМӘГӘНГӘ СИНЕҢ ЙӨЗЕҢНЕ!
ТӨШЛӘРЕМДӘ ГЕНӘ КҮРӘМ ХӘЗЕР,
НАЗ БӨРКЕГӘН,УЙЧАН КҮЗЕҢНЕ.

***

ИСКӘ ТӨШӘ КИЧЕН КАЕНЛЫКТА,
ШАУЛАП УЗГАН ЯШЬЛЕК ЕЛЛАРЫ!
КАЕН ҖИЛӘГЕННӘН АЛСУЛАНГАН,
АКЛАННАРЫ...УРМАН БУЙЛАРЫ!

***

СИНЕҢ БЕЛӘН ТӘҮГЕ ҮБЕШҮ ДӘ,
БУЛДЫ БАРЫ ҖӘЙНЕҢ КИЧЕНДӘ!
АЛСУЛАНГАН КАЕН ҖИЛӘГЕНЕҢ ,
ТӘМЕН ТОЙДЫМ СИНЕҢ ИРЕНДӘ!

***

ҺӘР ҖӘЙ САЕН КИЛӘМ УРМАННАРГА,
УЧЛАП АШЫЙМ КАЕН ҖИЛӘГЕН.
КҮЗЛӘРЕМНЕ ЙОМАМ...СИН ҮБӘСЕҢ...
БОЛЫТЛАРГА АША ХИСЛӘРЕМ!

***

САЛКЫН КЫШТА СУЫТКЫЧТАН АЛЫП,
КАБЫП КУЯМ КАЕН ҖИЛӘГЕН!
ТОЯМ ШУШЫ АЛСУ ҖИЛӘКТӘ ДӘ,
СИНЕҢ ИРЕННӘРНЕҢ САФ ТӘМЕН!

***

ОНЫТЫЛМЫЙ ИКӘН КАЙНАР ХИСЛӘР!
ТАҢДА ЧӘЧӘК АТКАН СИРЕНЬНӘР!
ОНЫТЫЛМЫЙ КАЕН ҖИЛӘГЕДӘЙ,
НАЗ БӨРКЕГӘН,КАЙНАР ИРЕННӘР!

***

==========================================

КҮЗЛӘР АЛДАШМЫЙ...

Күл буенда Ялгыз Хатын тора...

Аккошларга карап соклана!

Моңсу күзләрендә тирән сагыш,

Йөрәгендә әрнү саклана!

****************************

Таңнан бирле балык тоталмыйча,

Ялгыз Иркәй урын тапмады!

Сагышлардан өзгәләнде җаны,

Йөрәгендә нәфрәт кайнады!

*****************************

Кинәт Иркәй шулчак күреп калды,

Күл буенда Ялгыз хатынны.

Төнбоектай гүзәл җанны күреп,

Күңелләре шунда тартылды!

*****************************

Тал чыбыгы сыман зифа гәүдә!

Энҗе сыман нурлы йөзләре!

Чакрып тора назлы иреннәре,

Сөю бөрки моңсу күзләре!

*****************************

Инде моңсу күзләр очрашты!

Танышып та бик тиз алдылар.

Бер-берсеннән аерылмый шулай

Сәгатьләр дә бик тиз уздылар.

******************************

Кояш инде күптән баеп бетте,

Ә сөйләшер сүзләр бетмәде.

Әйтерсең лә шулчак икесенә-

Бер көн түгел,мизгел җитмәде!

*****************************

Берсен-берсе назлап, төн дә үтте,

Ике ялгыз йөрәк табышты!

"Мәңгелеккә бергә булырга!"-дип,

Вәгъдәләшкән парлар кавышты!

====================

## ЯЛАННАРДАН ЭЗЛӘП ЙӨРЕДЕМ...

Җәйләремдә сине болыннардан,

Тугайлардан эзләп йөредем!

Җир җиләге пешкән тау битеннән,

Җырлый-җырлый аска йөгердем!

***

Күзләремнән эзләп йөрдем сине!

Буйлап шомырт җыйган аланны.

Алтын көзнең алтын бизәгеннән-

Эзләмәгән җирем калмады!

***

Кышларымда туңдым,сине эзләп!

Бураннардан таба алмадым.

Карлы чыршылардан сорый-сорый,

Шыгыр-шыгыр алга атладым.

***

Эзләп таптым сине язларымнан,

Чәчәк аткан гөлләр иленнән!

Көннәр буе моңлы җыры белән,

Канат каккан кошлар иленнән!

***

Бу ил-минем кайнар йөрәк икән!

Син яшисең икән биредә!

Якты йолдыз булып СИН балкыйсың!

Йөрәгемдә...Тормыш күгемдә...

***

=========================

ТОМАННАРДА КАЛМА!

Каплаганнар куе ак томаннар,

Синең белән минем араны.

Таң җилләре көлеп кузгаталар,

Йөрәктәге беткән яраны.

Язлар килде бары безнең өчен!

Безнең өчен кошлар кайттылар!

Безнең назланганны карап торган,

Шомыртлар да чәчәк аттылар!

СИН һәм дә МИН!Бары икәү булдык,

Күбәләкле гүзәл җәйләрдә!

Безнең өчен дөнья тигез иде,

Чәчкәләрдән кундык гөлләргә!

Еллар узды...Ераклашты ара...

Томан басты еллар арасын.

Язмышыбыз шундый булды инде,

Аермады агын-карасын!

Ак томаннар Сине урладылар,

Инде мине ялгыз иттеләр.

Саф мәхәббәт белән бергә Сине

Әллә кайда алып киттеләр.

Ишет җаным!Сөю бар чагында,

Томаннарда калма адашып!

Кискән икмәк кире ябышмас бит,

Язмышларны булмый алдашып!

====================

МӘХӘББӘТ ЧИШМӘСЕ.

***

КАЙТТЫМ ӘЛЕ ТАГЫН АВЫЛЫМА,

САГЫНДЫРГАН УЗГАН МИЗГЕЛЛӘР.

КҮЗ АЛДЫМДА ТОРА АЛСУ ЙӨЗЕҢ!
ЯЗЛАР БҮЛӘК ИТКӘН СИПКЕЛЛӘР!
САГЫНЫП КАЙТТЫМ МИН,
МӘХӘББӘТ ЧИШМӘСЕН!
ГОМЕР ҮТСӘ ҮТСЕН-
ТИК МӘХӘББӘТ КЕНӘ СҮНМӘСЕН!

-----------------------------

КАЙДА КАЛГАН ГАЗИЗ БАЛАЧАГЫМ?
ЮГАЛГАННАР НАЗЛЫ КАЕННАР.
БЕЗНЕҢ БЕРГӘ САЛГАН СУКМАКЛАРНЫ,
ТОРМЫШ ЕЛГАЛАРЫ ЮГАННАР!
ҖЫРЛЫЙ-ҖЫРЛЫЙ ТӨШӘМ
МӘХӘББӘТ ЧИШМӘСЕНӘ!
СӨЙГӘН ЯРЕМ КАЙТЫР-
И,ГОМЕРКӘЙ,ТИК СИН ҮТМӘ ГЕНӘ!

--------------------------------------

ИНДЕ БЕЗ ДӘ ТИЗДӘН КАРТАЯБЫЗ,
КЫРАУ КУНДЫ ИНДЕ ЧӘЧЛӘРГӘ!
ЯШЬЛЕКТӘГЕ ТАТЛЫ МИНУТЛАРНЫ,
КАЛДЫ БАРЫ САГНЫП СӨЙЛӘРГӘ!
ТӨШӘМ ӘЛЕ ТӨШӘМ,
САЛКЫН СУЛАР ЭЧӘМ!
ТИК СИН ГЕНӘ КАЙДА-
ТӘҮГЕ СӨЙГӘН ЯРЕМ СИН-БЕРГЕНӘМ?

## КАЙТ ӘЛЕ СИН КӨЛЕП ЯШЬЛЕГЕМӘ!

********

БАЛ КОРТЛАРЫ ЭШКӘ ЯБЫШКАНДА,
ТАҢНЫҢ НУРЛАРЫНА КҮМЕЛЕП.
ЧИШМӘЛӘРГӘ СУГА ТӨШӘ ИДЕҢ,
КЫҢГЫРАУДАЙ ЧЫҢЛАП ҺӘМ КӨЛЕП.
УРАМНАРГА  ШАТЛЫК ТУЛА ИДЕ-
ЯҢГЫРАТЫП КӨЛЕП ҖИБӘРСӘҢ!
МИНЕМ ЙӨРӘК ЧӘЧКӘ АТА ИДЕ-
"И-И,МАТУРЫМ!"-ДИЕП ЭНДӘШСӘҢ!
ЯЗМЫШЫМА КӨЛЕП КИЛЕП КЕРДЕҢ!
КӨЛЕП  КАЛДЫҢ МИНЕМ ЙӨРӘКТӘ!
ЯШЬЛЕГЕМНЕ КӨЛЕП БИЗӘДЕД СИН,
НАЗЛЫ КӨЛӘ ИДЕҢ БИГРӘК ТӘ!
СИНЕҢ БЕЛӘН ҮТКӘН АСЫЛ ЕЛЛАР,
КҮЗ АЛДЫМА ХӘЗЕР КИЛӘЛӘР!
ТӨШЛӘРЕМДӘ КЫЗЛАР СИНЕҢ БЕЛӘН,
КӨЛӘ-КӨЛӘ СУЛАР КЕРӘЛӘР!
КАЙТ ӘЛЕ СИН КӨЛЕП ЯШЛЕГЕМӘ,
САНДУГАЧЛАР КАНАТ КАККАНДА!
КҮБӘЛӘКЛӘР ЧӘЧКӘЛӘРГӘ КУНЫП,
КАЕННАРДАН МОҢНАР ТАМГАНДА!
КАЙТ ӘЛЕ СИН КӨЛЕП БӘХЕТЕМӘ!
ЙӨРӘГЕМӘ КӨЛЕП КИЛЕП КЕР!
"И-И,МАТУРЫМ!"-ДИЕП КӨЛӘ-КӨЛӘ,

ҖЫЛЫ НАЗЛАРЫҢНЫ МИҢА БИР!

**********************************

ФӘРЕШТӘЛӘР. АЙЛЫ КҮКТӘ ФӘРЕШТӘЛӘР ОЧА!!!

ЙОЛДЫЗ БЕЛӘН ТУПЛЫ УЙНЫЙЛАР.

ӨСТӘН БЕЗНЕ ИСКӘ АЛЫП ТОРЫП,

ИЗГЕЛЕКЛӘР БЕЗГӘ ЮЛЛЫЙЛАР!!!

АРЫП-ТАЛЫП ЙОКЛАП КИТКӘННӘРГӘ,

ТӘМЛЕ ТӨШЛӘР БҮЛӘК ИТӘЛӘР.

САБЫЙЛАРНЫ ТЫЛСЫМ ДӨНЬЯСЫНА-

ӘКИЯТКӘ АЛЫП “КИТӘЛӘР”!

ЯЛГЫЗЛАРНЫҢ КАЙНАР ЙӨРӘГЕНӘ,

ГЫЙШЫК УГЫН КАДЫЙ АМУРЛАР.

Ә ЯЛГЫЗЛАР ИСӘ ГАШЫЙК БУЛЫП,

СӨЮ УТЛАРЫНДА ЯНАЛАР!!!

ИЗГЕ ТЕЛӘК ТЕЛИ ФӘРЕШТӘЛӘР!

КАНАТЛАНА КҮҢЕЛ КЫЛЛАРЫ!

АЛАР БЕЗНЕ БӘЛАЛӘРДӘН САКЛЫЙ!

ҮТӘ ШУЛАЙ ТОРМЫШ ЕЛЛАРЫ!

ТУПЛАР ИТЕП,ЙОЛДЫЗ АТЫШАЛАР!

ФӘРЕШТӘЛӘР КҮКТӘ УЙНЫЙЛАР!

КАЙНАР ЙОЛДЫЗЛАРДАН ПЕШМӘСКӘ ДИП,

БИК САКЛАНЫП КЫНА УЙНЫЙЛАР!

ӘГӘР ИНДЕ АЛАР ТОТАЛМАСА,

КАЙНАР ЙОЛДЫЗ ҖИРГӘ АТЫЛА!

Ә КЕШЕЛӘР ЙОЛДЫЗ АТЫЛГАНДА-

ТЕЛӘК ТЕЛӘРГӘ ДИП ОМТЫЛА!

ТАҢ АЛДЫННАН ГЫНА ТЫНЫЧЛАНЫП,

ЙОЛДЫЗЛАРНЫ АЛАР СҮНДЕРӘ!

БОЛЫТЛАРГА ТӨРЕНЕП, ЙОКЛЫЙ АЛАР-

БАР ДӨНЬЯНЫ НУРГА КҮМДЕРӘ!

ЙОКЛАСЫННАР,ӘЙДӘ ЯЛ ИТСЕННӘР!

АЛАРГА СЕЗ БӘХЕТ ТЕЛӘГЕЗ!

БӘХЕТ ӨЛӘШҮЧЕ ФӘРЕШТӘГӘ-

БӘХЕТ НИГӘ КИРӘК ДИМӘГЕЗ!

МӘХӘББӘТ.

КАРАҢГЫ ТӨН...ГӨҖЛӘП ЯҢГЫР КОЯ...

ӨЧ КАРТ ЮЛЧЫ КЕРДЕ АВЫЛГА.

ӨСЛӘРЕНДӘ ТУЗЫП БЕТКӘН КИЕМ,

НИ КАЛГАНДЫР МОНДЫЙ ДАВЫЛДА?

*********************************

ЧАЛ ЧӘЧЛЕЛӘР,САКЛ-МЫЕК БАСКАН,

КҮҢЕЛЛӘРЕ   ИЗГЕ  -СӘГӘДӘТ!!!

ИҢ  ӨЛКӘНЕ   БАЙЛЫК АТЛЫ ИКӘН,

БЕРСЕ -БӘХЕТ,БЕРСЕ-МӘХӘББӘТ!!!

ЯЛГЫЗ ХАТЫН ЧЫГЫП КАПКА АЧТЫ,

"ӨЙГӘ КЕРЕГЕЗ!"- ДИП,ЧАКЫРДЫ.

"БАРЧАГЫЗГА УРЫН -АШ  ТАБАРМЫН!"

КҮЗЛӘРЕНДӘ ЯШЬЛӘР ЧАГЫЛДЫ!

**********************************

-И БАЛАКАЙ!ЗУР-ЗУР РӘХМӘТ СИҢА!

БЕРЕБЕЗНЕ ГЕНӘ САЙЛА СИН!

Ә ИКЕБЕЗ ТЫШТА КАЛЫП ТОРЫР,

КАЙСЫБЫЗНЫ КУНА КЕРТӘСЕҢ?

***********************************

ХАТЫН УЙГА КАЛДЫ..."БАЙЛЫК МИҢА,

Я БУЛМАСА БӘХЕТ НИК КИРӘК!

Ә МӘХӘББӘТ КЕРСӘ ТОРМЫШЫМА-

БАЙЛЫК АРТЫР,БӘХЕТ ТАШЫР НӘКЬ!"

************************************

КӨЛЕШТЕЛӘР ӨЙДӘ БАЛА-ЧАГА!

МӘХӘББӘТ БИТ КЕРДЕ ИШЕКТӘН!

КАНАТЛАНЫП,ИРЕ КАЙТЫП ҖИТТЕ,

АКЧА БЕЛӘН - ЕРАК СЕБЕРДӘН!

*********************************

ЯҢГЫР КОЯ!!!ТӨННӘР БИГРӘК МОҢСУ!!!

Ә МӘХӘББӘТ НАЗЫН ӨЛӘШТЕ!

БАЙЛЫК БЕЛӘН БӘХЕТ ТЫНЫЧ КЫНА,

ШУШЫ ТАМАШАНЫ КҮЗӘТТЕ!!!

**********************************

БӘХЕТ ТАШАР-БАЙЛЫГЫГЫЗ АРТЫР!

САФ МӘХӘББӘТ КЕРСЕН ИШЕКТӘН!!!

СӨЮ БАРДА БӘХЕТ,БАЙЛЫК БУЛЫР,

АЛАРНЫ БИТ ХОДАЙ ИШ ИТКӘН!!

********************************

*****ЯЛГЫЗЛЫК*****

САГЫШЛАРНЫҢ ЯРАЛАРЫН АЧЫП,

ЙӨРӘКЛӘРНЕ ӨЗЕП, ЯРСЫТЫП.

КАНУННАРГА БАШЫН ИМИ ҺИЧ ТӘ-

ТОРМЫШЛАРГА КЕРӘ ЯЛГЫЗЛЫК!

КАНЛЫ ЯШЬКӘ БАТА УЙЧАН КҮЗЛӘР,

Ә КҮҢЕЛЛӘР ТАШКА ӘЙЛӘНӘ.

ТИК ЯЛГЫЗЛЫК ҺАМАН ҮЗЕНЧӘ БИТ,

ЯЗМЫШЛАРГА КИЛЕП БӘЙЛӘНӘ!

ЧЕЛПӘРӘМӘ КИЛӘ АК ӨМЕТЛӘР!

ХЫЯЛ КАНАТЛАРЫН СЫНДЫРА!

АРТТАН КИЛЕП ИНДЕ ӨМЕТСЕЗЛЕК,

БАШКАЙЛАРГА ТУКМАК ТОНДЫРА!

ЯЛГЫЗЛЫК БИТ-ТОРМЫШ ГАЗАБЫ УЛ!

ЯЛГЫЗЛЫК БИТ-ГАСЫР АФӘТЕ!

ЯЛГЫЗЛЫККА ИНДЕ БАШНЫ САЛСАК,

ЙӨРӘКЛӘРНЕҢ СҮНӘР КҮӘТЕ!

ПАР АККОШЛАР КҮРЕП СЫКРАНМАГЫЗ!

ТЫРЫШЫГЫЗ ПАРЛЫ БУЛЫРГА!

ҺӘР БЕРЕБЕЗ ӨЧЕН ПАРЛАР БАР БИТ,

ОМТЫЛЫГЫЗ ТИҢДӘШ ТАБЫРГА!

ЯЛГЫЗЛЫКНЫҢ БОГАЗЫННАН АЛЫП,

ТАМЫРЛАРЫН ЧӘЙНӘП ӨЗЕГЕЗ!

АККОШЛАРДАЙ СӨЕП ҺӘМ СӨЕЛЕП,

ТОРМЫШ ЮЛЛАРЫННАН ҮТЕГЕЗ!

===========================================

ОНЫТМА!

Син онытма мине-һич онытма!

Күңелеңнән алып ташлама!

Мин бит синең янәшәңдә генә,

Язмыш кулларына ташлама!

Кышларыңда мине онытма син!

Кар бөртеге булып туңармын!

Күбәләктәй очып йөрермен дә,

Керфегеңә килеп кунармын!

Йөрәгеңнән алып ташлый күрмә!

Күзләреңдә кайтып җитәрмен!

Моңсу яңгыр булып,җылый-җылый

Тәрәзәңә килеп чиртермен!

Син онытма!Мин бит синең белән!

Язлар булып керәм җаныңа!

Беркайчан да мине ОНЫТМА син,

Мин бит монда!Синең яныңда!

------------------------------------------------------

ЕЛАМА!!!....

Газаплардан интеккәндә...

Сагышлардан кимсенгәндә...

Елама,син,җаным-елама!

Йөрәгеңнән кан тамса да...

Күзләреңнән яшь акса да...

Язмыш кануннарын тыңлама!

***

Таңнарыңа чык булып төш...

Җиләк булып кызарып пеш...

Яшьлегеңдә -чәчкә чагында!

Сандугачтай канат кагып...

Тормышыңның ямен табып...

Җырлый-җырлый җәйнең таңында!

***

Яңгыратып көлче әйдә...

Шушы гүзәл назлы җәйдә...

Сагыш пәрдәләре ачылсын!

Вакыт бүләк иткән җәйдә...

Яшәп калыйк әле әйдә...

Тик гомерләр генә сулмасын!

***

СИН - МӘҢГЕЛЕК!

Син-ҖИЛ,БУРАН,ДАВЫЛ-ӨЕРМӘ!

Син бит назлы,язгы ГӨРЛӘВЕК!

Син бит алсу КАЕН ҖИЛӘГЕ!

Син теш үтмәс каты ЧИКЛӘВЕК!

Болыннарда үскән ЧӘЧКӘ син!

Җырлап аккан салкын ЧИШМӘ син!

Йөрәгемдә янган ЯЛКЫН син!

Күңелемнән мәңге китмә син!

Син-ҖӘЙ,син-КЫШ,син-ЯЗ мәңгелек!

Син- моңсу КӨЗ!Тере гүзәллек!

Син-ОКЕАН!ДИҢГЕЗ!Син-ЙОЛДЫЗ!

Бар җиһанны сиңа тиңләрлек!

Керфегемә ТАМЧЫ булып там!

ТУРГАЙ булып сайра иң элек!

Син-бит ул МИН!Мин тик бары СИН!

Син-ТАБЫШМАК!Син бит-МӘҢГЕЛЕК!

********

СИН КИЧЛӘРЕН МИНЕ...

Син кичләрен мине көтәсеңме?

Көзгеләргә карап көләсеңме?

Сине сагынудан йөрәгемнең,

Ярсып януларын сизәсеңме?

***

Син кичләрен мине уйлыйсыңмы?

Минем белән әллә уйныйсыңмы?

Күз алдыңа килсә кайнар хисләр-

Мендәреңне кочып җылыйсыңмы?

***

Син кичләрен мине сагнасыңдыр!

Күңелеңә өмет салгансыңдыр!

Төшләреңдә күреп бергә чакны,

Сарыларга инде саргансыңдыр!

***

Син кичләрен мине көт яме,көт!

Болыннарга чыгып,җырлап үт!

Хуш исләрен иснәп чәчәкләрнең,

Син кичләрен,җаным,мине көт!

***

==========================================

ХЫЯНӘТ.

КАРАҢГЫЛЫК БАСТЫ ТОРМЫШ КҮГЕН,

ЙӨРӘКЛӘРДӘН  ЯРСЫП КАН ТАМДЫ.

КИЧЕРАЛМЫЙ ХАТЫН ХЫЯНӘТЕН,

КИЧЕРАЛМЫЙ ТУПАС ЯЛГАННЫ!

НИГӘ ЯЗМЫШ ШУЛАЙ КЫРЫС ИКӘН?

ҮЗӘК ӨЗГЕЧ САГЫШ ҖИЛЛӘРЕ!

БЕР МИНУТТА ЧЕЛПӘРӘМӘ КИЛДЕ,

ЧӘЧӘК АТКАН СӨЮ ГӨЛЛӘРЕ.

СИН ЕРАКТА ИДЕҢ-ЭШ БУЕНЧА,

БАЛАЛАР ДА УКЫЙ МӘКТӘПТӘ.

ЯШЬ ХАТЫНЫҢ ӨЙДӘ ЯЛГЫЗ КАЛДЫ,

БАРЫСЫ ДА ИДЕ ТӘРТИПТӘ.

АВЫЛДАШЫ КИЛЕП,ЭШНЕ БОЗДЫ,

ЧӨКЕРДӘШЕП, ШӘРАБ ЭЧТЕЛӘР.

ИСКӘ АЛЫП, УЗГАН ЯШЬЛЕКЛӘРЕН,
РЕСТОРАНГА КЕРЕП КИТТЕЛӘР.

ТӨН УРТАСЫ ҖИТКӘЧ КАЙТЫП КЕРДЕ,
БАЛАЛАР АЧ КИЛЕШ ЙОКЛАГАН.
УРЫН ҖӘЕП,БЕРКЕМ ӨСЛӘРЕНӘ
ҖЫЛЫ ЮРГАННАРНЫ ЯПМАГАН.

ИРТӘН ТОРГАЧ ҺУШКА КИЛДЕ ХАТЫН,
ТИК ТЕРСӘГЕ ҖИТМИ ТЕШЛӘРГӘ!
ХЫЯНӘТНЕ АЛЫП ТАШЛАП БУЛМЫЙ,
НИШЛӘРГӘ СОҢ,ХӘЗЕР НИШЛӘРГӘ!
==============================

СИН ЫШАН!!!

САГЫШ БОЛЫТЛАРЫ КАПЛАП АЛСА,
КИНӘТ КЕНӘ ТОРМЫШ КҮГЕҢНЕ.
КОЯШ БУЛЫП, КАБЫНЫРМЫН КҮКТӘ
ЯКТЫРТЫРМЫН СИНЕҢ ЙӨЗЕҢНЕ!

СИН ОНЫТМА МИНЕ!ЫШАН МИҢА!
ЙӨРӘГЕМДӘ БУЛ СИН МӘҢГЕГӘ!
ЯЗМЫШЫБЫЗ БЕРГӘ КУШЫЛСЫН ДИП,
КӨН ДӘ ЯЛЫНАМЫН ТӘҢРЕМҢ!

ЫШАН МИҢА!СИНЕ ЭЗЛИ КҮҢЕЛ!
ИКЕ КҮЗЕМ ЮЛЛАР ЧАТЫНДА!
ЙОЛДЫЗ БУЛЫП,КҮКТӘН АТЫЛСАҢЧЫ
САГЫНЫПЛАР КӨТКӘН ЧАГЫНДА.

САЛКЫН ЧИШМӘ БУЛЫП, АК ӘЛЕ СИН!
САГЫШЛАРДАН СУЛДЫМ-САРГАЙДЫМ!
СИН ЫШАН ТИК-МИҢА ГЫНА ЫШАН!
МИН БИТ СИНСЕЗ ЯРТЫ КАРТАЙДЫМ!

*******************

СИН БИТ МИҢА БӘХЕТ  БҮЛӘК ИТТЕҢ,
КҮҢЕЛЛӘРГӘ САНДУГАЧЛАР КЕРДЕ!
ЯЗ СУЛЫШЫН ТОЙДЫМ СИНЕҢ БЕЛӘН,
ЯЗЛАР БЕЛӘН БЕРГӘ НАЗЛАР БИРДЕҢ!
КАЕННАРДАН МОҢ ТАМГАНДА,
ҖЫРЧЫ КОШЛАР САЙРАГАНДА.

АККОШ КАНАТ КАГЫНГАНДА,
ЯЗЛАР БЕЛӘН БЕРГӘ ТИК СИН КИЛДЕҢ!

СИН БИТ МИҢА ЯЗЛАР БҮЛӘК ИТТЕҢ!
КҮРЕП ТУЙМАС КҮЗЛӘРЕМНӘН ҮПТЕҢ!
АК КАЕННАР КЫЗЫГЫШЫП КАРАП ТОРДЫ,
Ә СИН МИҢА ҖЫЛЫ НАЗЛАРЫҢНЫ СИПТЕҢ!
КАЕННАРДАН МОҢ ТАМГАНДА,
САНДУГАЧЛАР САЙРАГАНДА.
АККОШ КАНАТ КАГЫНГАНДА,
СӨЮЕҢНЕҢ КАЙНАРЛЫГЫН ИСБАТ ИТТЕҢ!

СИН БИТ МИҢА СӨЮ БҮЛӘК ИТТЕҢ!
НАЗЛАП-НАЗЛАП ИРЕНЕМНӘН ҮПТЕҢ!
АК КАЕННАР ОЯЛЫШЫП БАШЫН БОРДЫ,
МИН ҮЗЕМНЕ КҮКЛӘРДӘ ДИП ХИС ИТТЕМ!
КАЕННАРДАН МОҢ ТАМГАНДА,
ТАҢ КОШЛАРЫ САЙРАГАНДА,
КУЕ ТОМАН САРЫЛГАНДА,
САФ МӘХӘББӘТ МИҢА БҮЛӘК ИТТЕҢ!

...ЙӨРӘГЕМНӘН КАН ТАМЫЗМА....!!!

ТАГЫН ИНДЕ КИТӘМ ДИСЕҢ-

ҖАНЫМНЫ ӨЗГӘЛИСЕҢ,
ТӨШЛӘРЕМӘ КИЛЕП КЕРЕП-
ЙӨРӘКНЕ ТЕЛГӘЛИСЕҢ.
САГЫШЫМНАН СУЛАМ ИНДЕ-
УТЛАРЫНДА КӨЯМ ИНДЕ,
КИРЕ КАЙТЫР ЮЛЛАРЫҢНЫ-
НИГӘ СОҢ ЭЗЛӘМИСЕҢ?

ЙӨРӘГЕМНӘН КАН ТАМЫЗМА!
КҮЗЕМНӘН ЯШЬ АГЫЗМА!
ЯЗНЫҢ НАЗЛЫ ТАҢНАРЫНДА,
БУЛСАҢ ИДЕ ЯННАРЫМДА.
СӨЮНЕҢ ДӘ ИҢ ТАТЛЫСЫ,
ЯЗЛАРНЫҢ ДА ИҢ НАЗЛЫСЫ
ТИК СИН ГЕНӘ,ТИК СИН  ГЕНӘ
КАЛСАҢ ИДЕ ҖАННАРЫМДА!

ЙӨРӘГЕМНӘН КАН ТАМЫЗМА-
САГЫШ УТЛАРЫ КАБЫЗМА,
ТАҢ АТКАНДА ҖЫРЛЫЙ-ҖЫРЛЫЙ
КИЛЕРСЕҢМЕ ГҮЗӘЛЕМ?
МӘХӘББӘТЕБЕЗ ЯШӘРСЕН,
СӨЮ УЧАГЫ ДӨРЛӘСЕН,
ЙӨРӘГЕМНӘН КАН ТАМЫЗМА-
ӨЗЕЛӘ БИТ ИНДЕ ҮЗӘГЕМ!

МЕНӘ ТАГЫН ЯЗЛАР КИЛДЕ-
КҮҢЕЛЛӘРГӘ ИЛҺАМ КЕРДЕ!
ТИК СИН  ЮКСЫҢ! ТИК СИН ГЕНӘ
НИКТЕР КИЛМИСЕҢ!
ЙӨРӘГЕМНӘН КАН ТАМЫЗМА-
ГАЗАП УТЛАРЫН КАБЫЗМА,
ЯКТЫ ЙОЛДЫЗЛАРДАЙ БАЛКЫП ,
ЯННАРЫМА КИЛЕП ҖИТӘРСЕҢ!

*****************

ТӨНГЕ  ВАЛЬС.

КИЧ ҖИТКӘНДӘ КИЛЕРМЕН МИН БЕРЧАК,
АЛ ЧӘЧӘКЛӘР БҮЛӘК ИТӘРМЕН.
ТАТЛЫ ШӘРАБТАН СОҢ КҮҢЕЛЕҢДӘ
ЯЗГЫ ҖИЛЛӘР БУЛЫП ИСӘРМЕН.

БАШ ӘЙЛӘНЕР СИХРИ МУЗЫКАГА-
ЧАКЫРЫРМЫН СИНЕ БИЕРГӘ.
СИН ӘЗЕРСЕҢ ИНДЕ БАР ҖАНЫҢНЫ,
ЙӨРӘГЕҢНЕ МИҢА БИРЕРГӘ.

МОҢЛЫ КӨЙ АГЫЛДЫ БҮЛМӘ БУЙЛАП,
ТЫП-ТЫН КАЛДЫ ХӘТТА ГӨЛЛӘРЕҢ.
СИНЕҢ КОЧАГЫҢДА ЭРЕДЕМ МИН,

ЯШӘРГӘНДӘЙ БУЛДЫ ЙӨРӘГЕМ.

ЧАЛ ЧӘЧЛӘРЕМ КАРАЙГАНДАЙ БУЛДЫ,
ЯШЬЛЕК ДӘРТЕ ТАШТЫ КАННАРДА.
ИХ,ГҮЗӘЛЛЕК!!!ИХ,БУ ТӨНГЕ ВАЛЬС,
ЯШЬЛЕК БҮЛӘК ИТТЕ ҖАННАРГА!

ЯШЬ АРАСЫ ШАКТЫЙ БУЛСА ДА БИК,
МИН ЯШЬ ИТЕП ТОЙДЫМ ҮЗЕМНЕ.
ИХ,ГҮЗӘЛЛЕК!!!ИХ СИН,ТӨНГЕ ВАЛЬС
БҮЛӘК ИТТЕҢ  МИҢА СӨЮНЕ!!!

************************************

КИЧЕР МИНЕ!

ЯШЕРСӘНӘ ШОМЫРТ КҮЗЛӘРЕҢНЕ,
КЫЕНСЫНАМ СИНЕҢ КАРАШТАН.
АҢЛЫЙ АЛСАҢ ӘГӘР КИЧЕР МИНЕ,
БАШКАЛАРНЫ СИҢА АЛМАШМАМ!

ӘГӘР БУЛДЫРАЛСАҢ КИЧЕР МИНЕ!
СИН КӨТКӘНДӘ КИЛӘ АЛМАСАМ.
ЛӘЗЗӘТ БЕЛӘН СӨЮ МИНУТЛАРЫН,
СИҢА БҮЛӘК ИТӘ АЛМАСАМ!

КИЧЕР МИНЕ, ӘГӘР ЙӨРӘГЕҢНЕҢ
ЯЛКЫН ИКӘНЛЕГЕН ТОЙМАСАМ!
ТЫН АЛГАНДА КАЛКУ ТҮШЛӘРЕҢӘ
КАЙНАР УЧЛАРЫМНЫ КУЙМАСАМ!

КИЧЕР МИНЕ,СИНЕ КОЧЫП АЛЫП,
ЧЫКЛЫ ҮЛӘННӘРДӘН ҮТМӘСӘМ.
САФ СӨЮДӘН СУЛГАН ИРЕНЕҢНӘН,
НАЗЛАП-НАЗЛАП СИНЕ ҮПМӘСӘМ!

КИЧЕР МИНЕ...

ОЗАТМА!

КИТӘМ ИНДЕ...КИТӘМ ЕРАКЛАРГА

ОЗАТМА СИН,МИНЕ ОЗАТМА!

ТАМАГЫМДА КАТЫ ТӨЕР ТОРА,

ЗИНҺАР КҮЗЛӘРЕМНЕ ЧЫЛАТМА!

ОЗАТСАҢ ДА КАРАШЛАРЫҢ БЕЛӘН,

МӘҢГЕЛЕККӘ МИНЕ ЮГАЛТМА!

ИКЕ ЙӨРӘК БЕРСЕН БЕРСЕ ЭЗЛӘР,

БӨТЕНЛӘЙГӘ МИНЕ ОНЫТМА!

КАРАШЫҢНАН ИРКӘМ ТОЕП ТОРАМ,

СӨЮЕҢНЕҢ КАЙНАР ИКӘНЕН.

КҮКРӘГЕМӘ КЫСАМ-СИЗЕП ТОРАМ,

ЙӨРӘГЕҢНЕҢ ЯЛКЫН ИКӘНЕН.

ЕЛЛАР ҮТКӘЧ КИРЕ КАЙТЫРМЫН МИН,

СИН ЙӨГЕРЕП КАРШЫ ЧЫГАРСЫҢ.

МИН САГЫНСАМ СИНЕ-САРГАЕРМЫН!

Ә СИН,ИРКӘМ,НИЧЕК ЧЫДАРСЫҢ?

КИТӘМ ИНДЕ...ЗИНҺАР АЧУЛАНМА...

ОЗАТМА СИН, МИНЕ ОЗАТМА!

ЯЗЛАР БЕЛӘН ҖЫРЛАП КАЙТЫРМЫН МИН,

ТИК СИН ГЕНӘ МИНЕ ЮГАЛТМА!

АҢЛАМАДЫҢ!

Аңламадың мине аңламадың,

Кирәк чакта ярем булалмадың.

Йөрәгемә очкын салалмадың,

Сиңа әйтер сүзләр табалмадым.

Аңламадың мине аңламадың,

Авыр чакта җаным булалмадың.

Йөрәгемнән ташкан саф сөюгә,

Йөрәгеңнән урын табалмадың.

Аңламадың мине аңламадың,

Күзләремә туры карамадың.

Шау чәчәктә булган күңелемә

Назлы карашыңны салалмадың.

Аңламадың мине аңламадың,

Онытырмын диеп уйладың.

Тик йөрәктән алып ташлап булмай,

Син бит өметемне урладың.

Аңламадың мине аңламадың,

Соңладың шул, инде соңладың!

Гомер генә зая узып бара,

Син бит яшьлегемне урладың!

***************

ФӘРЕШТӘМ БУЛ!

-----------------

АЙЛЫ КИЧТӘ ЙОЛДЫЗ КЫЗЛАРЫНЫҢ,

КАРАП ТОРДЫМ УЙНАП ОЧКАНЫН.

БАШ ОЧЫМДА ГЫНА ҮРТӘДЕЛӘР,

КАБЫЗДЫЛАР ЙӨРӘК ОЧКЫНЫН.

------------

ФӘРЕШТӘЛӘР КҮКТӘ ЯШИ ДИЛӘР,

ӘЛЛӘ АЛАР ШУЛАЙ УЙНЫЙЛАР.

КҮКТӘ ЙӨЗГӘН БОЛЫТЛАРГА БАСЫП,

ЕЛМАЕШЫП КУЛЛАР БОЛГЫЙЛАР

-----------

СИН ДӘ ШУЛАЙ КҮКТӘ ОЧСАҢ ИДЕ!

АКСЫЛ БОЛЫТЛАРДА ЙӨЗСӘҢ ИДЕ!

ФӘРЕШТӘЛӘР БУЛЫП,ОЧЫП  ТӨШЕП,

КҮҢЕЛЕМӘ КИЛЕП КЕРСӘҢ ИДЕ!

-------------

КӨН ДӘ КАРЫЙМ ТӨНЛӘ АЙЛЫ КҮККӘ,

КҮЗЛИМ ШАЯН ЙОЛДЫЗ КЫЗЛАРЫН.

ӘЙДӘ СИН ДӘ ФӘРЕШТӘЛӘР БУЛЫП,

ЯКТЫРТ ӘЛЕ КҮҢЕЛ НУРЛАРЫН!

----------

ФӘРЕШТӘМ БУЛ!ИЗГЕЛЕКЛӘР ЭШЛӘ!

БӘХЕТ ӨЛӘШ ЗӘҢГӘР КҮКЛӘРДӘН.

ИЗГЕЛЕК ҺӘМ НАЗЛЫ СӨЙКЕМЛЕЛЕК
ТАШЫП ТОРА СИНЕҢ КҮЗЛӘРДӘН!

## КЫЗЫЛ РОЗАЛАР.

ИСЕҢДӘМЕ КАРАҢГЫ ТӨН ИДЕ...
ЯКТЫРТМЫЙЛАР ИДЕ ЙОЛДЫЗЛАР.
СӨЮЕМНЕ ИСБАТ ИТӘР ӨЧЕН,
БҮЛӘК ИТТЕМ КЫЗЫЛ РОЗАЛАР.

ТАҢГА КАДӘР ТӨН БЕЗНЕКЕ ИДЕ!
ОНЫТЫЛДЫ САГЫШ-БОРЧУЛАР.
ИРТӘН КИТТЕҢ...ОНЫТЫЛЫП КАЛДЫ,
МИНЕМ БҮЛӘК ИТКӘН РОЗАЛАР!

БЕР БОТАГЫН АЛЫП,СУГА КУЙДЫМ,
ТИЗДӘН АЛАР ТАМЫР ҖИБӘРДЕ.
УТЫРТЫП ТА КУЙДЫМ-ӨЙ ЭЧЛӘРЕМ
МАТУРЛАНДЫ...ХИСЛӘР ҮЗГӘРДЕ...

КҮЗ АЛДЫМА КИЛӘ СИНЕҢ БЕЛӘН,
БЕРГӘ БУЛГАН ТАТЛЫ МИНУТЛАР.
РОЗАЛАР ЧӘЧӘК АТТЫ ИНДЕ,
ТИК СИН ЮКСЫҢ...УЗА ВАКЫТЛАР...

СИН ЕРАКТА ХӘЗЕР...ЙӨРӘГЕҢДӘ
БАШКА ГӨЛЛӘР ЧӘЧӘК АТКАНДЫР.
ТИК СИНЕКЕ СЫМАН АЛСУ ГӨЛЛӘР
ЙӨРӘГЕМДӘ ЧӘЧӘК АТМАСТЫР!

ЫШАНМАДЫҢ...

ЫШАНМАДЫҢ СҮЗЛӘРЕМӘ...
ЫШАНМАДЫҢ ЙӨРӘГЕМӘ...
ЫШАНМАСАҢ ИНДЕ ЫШАНМА!
СИНЕ КҮРМИ АЙЛАР УЗДЫ..
СИНЕ КҮРМИ ЕЛЛАР УЗДЫ...
ЗИНХАР КАРАШЫҢНЫ КЫЗГАНМА!
************
ЫШАНМАДЫҢ КҮЗЛӘРЕМӘ...
ЫШАНМАДЫҢ КАРАШЫМА...
Ә МИН СИНЕ ТАШЛЫЙ АЛМАДЫМ!
СИННӘН БАШКА ЯРЬ-ЯРЬ ТҮГЕЛ...
АҢЛА ИРКӘМ,СИН ШУНЫ БЕЛ...
ЙӨРӘГЕМНЕҢ НИЧЕК ЯНГАНЫН!
*************
ЫШАНМАДЫҢ СӨЮЕМӘ...
ЫШАНМАДЫҢ КӨЮЕМӘ...
ЫШАНМАДЫҢ ҖАНЫМ,ОЧЫНДЫҢ!
СИҢА БАРЫ БӘХЕТ ТЕЛӘП...

СИҢА НАЗЛЫ ЯЗЛАР ТЕЛӘП...

БӘХЕТ КҮГӘРЧЕНЕН ОЧЫРДЫМ!

*****************

БЕЗ БИТ СӨЯР ӨЧЕН ЯРАЛГАН!

Әйдә әле,җаным,бергәләшеп,
Көлә-көлә ашыйк күкләргә!
Болытларны түшәк итеп ятыйк,
Өстән карап торган җирләргә!
Әйдә  әле,җаным,күккә ашыйк!
Йолдызларга сәлам җиткерик!
Фәрештәләр безне саклап йөртер,
Сөю ләззәтләрен  кичерик!
Күрәсеңме,җаным,җиребездә
Гөлләр чәчәк ата башлаган.
Чәчәк атсын сөю хисләребез,
Без бит сөяр өчен яралган!
Йолдызлардан йолдызларга очыйк,
Җир әйләнсен!Гөлләр шиңмәсен!
Без бит кайнар сөю җимешләре,
Сөю ялкыннары сүнмәсен!!!

===

=====================

СИН-МӘҢГЕЛЕК!!!

ИСЕҢДӘМЕ,ТӘҮГЕ ОЧРАШУДА-
СИН БЕР СЕРЕНАДА ҖЫРЛАДЫҢ.
СИНЕҢ ТАВЫШЫҢНАН ИСЕРДЕММЕ,
КҮЗЛӘРЕМНЕ ЙОМЫП ТЫҢЛАДЫМ.

САФ ЧИШМӘДӘЙ ТАВЫШЫҢ ДА НАЗЛЫ,
СИН-ҮЛЕМСЕЗ...СИН БИТ МӘҢГЕЛЕК!
УЙЧАН  КҮЗЛӘРЕҢНЕ КҮКТӘ ЯНГАН,
ЙОЛДЫЗЛАРГА СИНЕҢ ТИҢЛӘРЛЕК.

БАР ТИРӘ-ЯК СИХРИ МОҢГА ЧУМА,
ЯҢГЫРАТЫП КӨЛЕП ҖИБӘРСӘҢ,.
КҮЗЛӘРЕҢНӘН НАЗЛЫ НУР БӨРКЕЛӘ,
МИҢА ҖЫЛЫ КАРАШ СИРПЕСӘҢ.

СИН МӘҢГЕЛЕК-МИНЕМ КҮҢЕЛЕМДӘ!
СИН МӘҢГЕЛЕК МИНЕМ УЙЛАРДА!
СИН МӘҢГЕЛЕК МИНЕМ ЙӨРӘГЕМДӘ!
СИН МӘҢГЕЛЕК МИНЕМ ҖЫРЛАРДА!

БЕР БОТАГЫН АЛЫП,СУГА КУЙДЫМ,
ТИЗДӘН АЛАР ТАМЫР ҖИБӘРДЕ.
УТЫРТЫП ТА КУЙДЫМ-ӨЙ ЭЧЛӘРЕМ
МАТУРЛАНДЫ...ХИСЛӘР ҮЗГӘРДЕ...

КҮЗ АЛДЫМА КИЛӘ СИНЕҢ БЕЛӘН,
БЕРГӘ БУЛГАН ТАТЛЫ МИНУТЛАР.
РОЗАЛАР ЧӘЧӘК АТТЫ ИНДЕ,
ТИК СИН ЮКСЫҢ...УЗА ВАКЫТЛАР...

СИН ЕРАКТА ХӘЗЕР...ЙӨРӘГЕҢДӘ
БАШКА ГӨЛЛӘР ЧӘЧӘК АТКАНДЫР.
ТИК СИНЕКЕ СЫМАН АЛСУ ГӨЛЛӘР
ЙӨРӘГЕМДӘ ЧӘЧӘК АТМАСТЫР!

## ЫШАНМАДЫҢ...

ЫШАНМАДЫҢ СҮЗЛӘРЕМӘ...
ЫШАНМАДЫҢ ЙӨРӘГЕМӘ...
ЫШАНМАСАҢ ИНДЕ ЫШАНМА!
СИНЕ КҮРМИ АЙЛАР УЗДЫ..
СИНЕ КҮРМИ ЕЛЛАР УЗДЫ...
ЗИНХАР КАРАШЫҢНЫ КЫЗГАНМА!
************
ЫШАНМАДЫҢ КҮЗЛӘРЕМӘ...
ЫШАНМАДЫҢ КАРАШЫМА...

Ә МИН СИНЕ ТАШЛЫЙ АЛМАДЫМ!

СИННӘН БАШКА ЯРЬ-ЯРЬ ТҮГЕЛ...

АҢЛА ИРКӘМ,СИН ШУНЫ БЕЛ...

ЙӨРӘГЕМНЕҢ НИЧЕК ЯНГАНЫН!

*************

ЫШАНМАДЫҢ СӨЮЕМӘ...

ЫШАНМАДЫҢ КӨЮЕМӘ...

ЫШАНМАДЫҢ ҖАНЫМ,ОЧЫНДЫҢ!

СИҢА БАРЫ БӘХЕТ ТЕЛӘП...

СИҢА НАЗЛЫ ЯЗЛАР ТЕЛӘП...

БӘХЕТ КҮГӘРЧЕНЕН ОЧЫРДЫМ!

******************

БЕЗ БИТ СӨЯР ӨЧЕН ЯРАЛГАН!

Әйдә әле,җаным,бергәләшеп,

Көлә-көлә ашыйк күкләргә!

Болытларны түшәк итеп ятыйк,

Өстән карап торган җирләргә!

Әйдә  әле,җаным,күккә ашыйк!

Йолдызларга сәлам җиткерик!

Фәрештәләр безне саклап йөртер,

Сөю ләззәтләрен  кичерик!

Күрәсеңме,җаным,җиребездә

Гөлләр чәчәк ата башлаган.

Чәчәк атсын сөю хисләребез,

Без бит сөяр өчен яралган!

Йолдызлардан йолдызларга очыйк,

Җир әйләнсен!Гөлләр шиңмәсен!

Без бит кайнар сөю җимешләре,

Сөю ялкыннары сүнмәсен!!!

===

=======================

СИН-МӘҢГЕЛЕК!!!

ИСЕҢДӘМЕ,ТӘҮГЕ ОЧРАШУДА-

СИН БЕР СЕРЕНАДА ЖЫРЛАДЫҢ.

СИНЕҢ ТАВЫШЫҢНАН ИСЕРДЕММЕ,

КҮЗЛӘРЕМНЕ ЙОМЫП ТЫҢЛАДЫМ.

САФ ЧИШМӘДӘЙ ТАВЫШЫҢ ДА НАЗЛЫ,

СИН-ҮЛЕМСЕЗ...СИН БИТ МӘҢГЕЛЕК!

УЙЧАН  КҮЗЛӘРЕҢНЕ КҮКТӘ ЯНГАН,

ЙОЛДЫЗЛАРГА СИНЕҢ ТИҢЛӘРЛЕК.

БАР ТИРӘ-ЯК СИХРИ МОҢГА ЧУМА,

ЯҢГЫРАТЫП КӨЛЕП ҖИБӘРСӘҢ,.

КҮЗЛӘРЕҢНӘН НАЗЛЫ НУР БӨРКЕЛӘ,

МИҢА ҖЫЛЫ КАРАШ СИРПЕСӘҢ.

СИН МӘҢГЕЛЕК-МИНЕМ КҮҢЕЛЕМДӘ!

СИН МӘҢГЕЛЕК МИНЕМ УЙЛАРДА!

СИН МӘҢГЕЛЕК МИНЕМ ЙӨРӘГЕМДӘ!

СИН МӘҢГЕЛЕК МИНЕМ ҖЫРЛАРДА!

## “СҮНДЕРМӘЛЕ,ӘНКӘМ,УЧАГЫҢНЫ!”

Тышта салкын буран котырса да,

Кар басса да йөргән сукмагыңны.

Җыелышып, кайтып керербез бер,

Сүндермәле,әнкәм,учагыңны!

Самавырың җырлап торсын түрдә,

Пешереп куй тәмле коймагыңны!

Җылытырбыз салкын җаныбызны,

Сүндермәле,әнкәм,учагыңны!

Сагынышып бер кайтырбыз әле,

Юксынышып назлы кочагыңны.

Һәрвакытта янып,гөрләп торсын!

Сүндермәле,әнкәм,учагыңны!

========================================

## С А Н Д У Г А Ч.

Салкын чишмәләрдән сулар эчеп,
Рәхәтләнеп канат кагынгач.
Өздерепләр генә сайрарга дип,
Болыннарга очты сандугач.

Сайра кошкай!Сайра-үзәкне өз!
Тирә-якка моңнар сибелсен!
Бар табигать моңга сусаган бит,
Җаннарыбыз моңга күмелсен.

Мин дә синең сыман моңлы җан бит!
Шигырь язам күңел бай булгач.
Халкыбызга назлы моңнар сибеп,
Әйдә бергә сайрыйк ,сандугач!

Шаулап атсын көн дә тыныч таңнар,
Гөрләп узсын сабан туйлары!
Күңелләрне җилкендереп торсын,
Сандугачның назлы моңнары!!!

**********************************

## КАРГА БУРАНЫ.

***************

ЯЗ ҖИТСӘ ДӘ ӘЛЕ КЫШ КӨЧЕНДӘ!
ШАУЛАП ТОРА НАРАТ УРМАНЫ.
ТИЗДӘН ЯЗ ДА МЕНӘР ТӘХЕТЕНӘ,
БУЛЫП ҮТСӘ КАРГА БУРАНЫ!

********

ТЫШТА ИШЕП-ИШЕП КАРЛАР ЯВА
ҖИЛ СЫЗГЫРА-АЙКЫЙ ДӨНЬЯНЫ!
ЯЗ БЕЛӘН КЫШ ШУЛАЙ АЕРЫЛА-
ШУШЫ ИНДЕ КАРГА БУРАНЫ!

************

ЯЗ БЕЛӘН КЫШ БИЛЛӘР АЛЫШАЛАР,
КАЙСЫ КӨЧЛЕ, КАЙСЫ БИЛ БИРӘ?
ШУНДЫЙ КАРГА БУРАННАРЫ БЕЛӘН,
ТОРМЫШЛАРГА БЕЗНЕҢ ЯЗ КЕРӘ!

************

ИКЕ КӨННӘН ИНДЕ САГЫНЫШЫП,
КАЙТЫП ҖИТӘ КАРА КАРГАЛАР.
КАЙТУ БЕЛӘН ЭШКӘ ТОТЫНАЛАР,
ПЫР-ЗЫР КИЛЕП ОЯ КОРАЛАР.

**************

БУРАННАРЫ, КАРГАЛАРЫ БЕЛӘН
ЯЗ-ГҮЗӘЛКӘЙ МЕНӘ ТӘХЕТКӘ!
ТЫНЫЧ ЯЗЛАР КИЛСЕН ИНДЕ АМИН,
БАР ДА БУЛЫР БЕЗНЕҢ БӘХЕТКӘ!

НИЛӘР ЭШЛИМ!

БУ ДӨНЬЯНЫ ҺИЧ ТӘ АҢЛЫЙ АЛМЫЙМ,
ЯЛКЫН ДА БАР ИСӘ ЙӨРӘКТӘ.
ЗАМАН ҖИЛЛӘРЕНӘ БИРЕШМӘСЛЕК
КӨЧ ТАБАЛМЫЙМ ТАЛГАН БЕЛӘКТӘ.
НИЛӘР ЭШЛИМ!...ӘГӘР БУЛДЫРАЛСАМ
РИЗА БУЛСА ӘГӘР ТӘҢРЕМ.
МИН МӘҢГЕЛЕК ЯСАП КУЯР ИДЕМ,
АСЫЛ КЕШЕЛӘРНЕҢ ГОМЕРЕН.
НИЛӘР ЭШЛИМ!...КАЙНАР ЙӨРӘГЕМНӘН
ТЕЛИМЕН ТИК ИЗГЕ ТЕЛӘКЛӘР.
ИЛҺАМ ЧИШМӘЛӘРЕМ САРКЫП ТОРА!
МОҢГА СУСАМАСЫН ЙӨРӘКЛӘР!
НИЛӘР ЭШЛИМ!...КАРШЫ БАРА АЛМЫЙМ,
ХОДАЙ КУШКАН ЭШКӘ-КАНУНГА.
САБЫР ГЫНА ТОРМЫШ ДӘВАМ ИТӘ,
ЯРАКЛАША БӘНДӘ ЗАМАНГА.
НИЛӘР ЭШЛИМ!!!КИРӘК ТИК ЯШӘРГӘ!
ЯШӘҮЛӘР БИТ БАРЫ БЕР ГЕНӘ!
ҮЗ КАДЕРЕҢ - ҮЗЕҢ БЕЛЕП ЯШӘ,
ТОРМЫШ ЯМЕН ТАТЫЙ БЕЛ ГЕНӘ!

НИЛӘР ЭШЛИМ!!!ЯЛКЫНЛАНЫП ЯШИМ!
ДӨНЬЯ БЕЛӘН ТУЛГАН ДУСЛАРЫМ!
МИНЕМ ӨЧЕН ӨЗЕЛЕШЕП ТОРГАН-
ЗАМАНДАШЛАР!!!ИПТӘШ КЫЗЛАРЫМ!
МИНЕМ ӨЧЕН ҖАН БИРЕРГӘ ӘЗЕР-
ГАЗИЗЛӘРДӘН-ГАЗИЗ ДУСЛАРЫМ!!!
ТУГАННАРЫМ ӨЗГӘЛӘНЕП ТОРА,
ЧӘЧӘК АТА КҮҢЕЛ МОҢНАРЫМ!!!
***************************************

САГЫНАМ!!

ХАТИРӘЛӘР БЕЛӘН КҮҢЕЛ ТУЛСА,
ИСКӘ АЛСАМ БАЛА ЧАГЫМНЫ.
ҮЗӘКЛӘРНЕ ӨЗӘ МИЗГЕЛЛӘРЕ-
БИК САГЫНСАМ ТУГАН ЯГЫМНЫ.

САГЫНАМ МИН САЛКЫН ЧИШМӘЛӘРНЕ,
БОЛЫННАРЫН ТУГАН ЯГЫМНЫҢ.
ЧАЛГЫ МОҢЫН ТЫҢЛАП, АГАЙЛАРГА
ӘЙРӘН ТАШЫП ЙӨРГӘН ЧАГЫМНЫ.

САГЫНАМ ШУЛ ДУСЛАР,БИК САГЫНАМ.
КУРА ҖИЛӘК ПЕШКӘН АКЛАННАР.
ӘЙДӘП МИНЕ ЧАКЫРАЛАР ТӨСЛЕ,

КӨРМӘКЛӘШЕП ҮСКӘН БОЛЫННАР.

ТУГАН ЯКНЫҢ ГҮЗӘЛ МИЗГЕЛЛӘРЕ
САГЫНДЫРСЫН,ӨЗСЕН ҮЗӘКНЕ!
ЙӨРӘКЛӘРДӘН АЛЫП ТАШЛАП БУЛМЫЙ
КАНЫМ ТАМГАН ИЗГЕ ТӨБӘКНЕ.

БУРАННАРДА КАЛЫП АДАШТЫМ

МИНЕМ БАШТАН ҮТТЕ ТӨРЛЕ ЧАКЛАР,
ХАТАЛАНДЫМ...ЙӨЗ КАТ ЯЛГЫШТЫМ.
ТОРМЫШ ДИҢГЕЗЕНДӘ ЙӨЗАЛМЫЙЧА,
ТОМАННАРДА КАЛЫП АДАШТЫМ.
------------------------------------------------------------
КУРЫКМАДЫМ ХӘТТА ХОДАЙДАН ДА,
ГӨНАҺ ЭШЛӘР ЭШЛӘП АЛДАШТЫМ.
КАРА КАРГЫШЛАР ДА ТӨШТЕ БАШКА-
УРМАННАРГА КЕРЕП АДАШТЫМ.
------------------------------------------------------------
ТИЗ БИРЕШТЕМ ЯЗМЫШ ҖИЛЛӘРЕНӘ,
ЯМАН ЧИРДӘН СЫКРАП САТАШТЫМ.
ТАМЫРЛАРЫМ ШАРТЛАП,КАННАР САУДЫ
БУРАННАРДА КАЛЫП АДАШТЫМ.

---------------------------------------------------------------

ТИК МОҢ АЛДЫМ КӨЧЛЕ ДУЛКЫННАРДАН
ТОМАННАРДАН...КАРЛЫ БУРАННАН...
АГАЧЛАРЫ ГОРУР ШАУЛАП ТОРГАН,
КАРАҢГЫ ҺӘМ КАЛЫН УРМАННАН.

--------------------------------------------------------------

КҮҢЕЛЛӘРЕМ ИЛҺАМЛАНЫП КАЛА,
УРМАННАРГА КЕРЕП ҖЫРЛАСАМ.
ТЕШНЕ КЫСЫП, АЛГА ТАБА БАРДЫМ
БУРАННАРДА КАЛЫП АДАШСАМ.

--------------------------------------------------------------

ТОРМЫШ-ДИҢГЕЗ,ЯЗМЫШ-ДУЛКЫННАРЫ
ЙӨЗӘ БЕЛМИ КЕРЕП ЯЛГЫШТЫМ.
КУҢЕЛ-УРМАН,Ә ХИСЛӘРЕМ-БУРАН!!!
БУРАННАРДА КАЛЫП АДАШТЫМ!!!

ХУШ КИЛӘСЕҢ ЯҢА ЕЛ!!!

ЙӨГЕРӘ-АТЛЫЙ КУЯН ЕЛЫ КИЛӘ!!!
КҮҢЕЛЛӘРГӘ НИНДИ КУАНЫЧ!!!
ЯҢА БӘХЕТ, ЯҢА ШАТЛЫК КИЛӘ-
ӨМЕТЛӘРГӘ БИРЕП ЫШАНЫЧ!!!

ХУШ КИЛӘСЕҢ ЙОМШАК ИЗГЕ КУЯН!!!

АК ЮЛ СИҢА  АКЛЫ ҖӘЙМӘДӘН!
БЕЗ КӨТӘБЕЗ ИНДЕ СИНЕ КҮПТӘН-
НАЗЛЫ ЯЗДАН, ГӨЛЛЕ ҖӘЙЛӘРДӘН.

АК  КАРЛАРЫҢ...СЫРМА БУРАННАРЫҢ
АЛЫП КИЛСЕН ЯҢА БӘХЕТЛӘР!!!
САБЫЙЛАРГА ШАТЛЫК БҮЛӘК ИТЕП,
КЕРФЕКЛӘРГӘ КУНСЫН БӨРТЕКЛӘР!

САГЫНДЫРЫП КУЯН ЕЛЫ КИЛӘ...
ҖИҢЕЛ БУЛСЫН ТӨКЛЕ АЯГЫҢ!
ӨМЕТ УТЫН КАБЫЗ ҖАНЫБЫЗНЫҢ,
ЯНДЫР БЕЗНЕҢ ТОРМЫШ МАЯГЫН!!!

АВАЗ БИРЕП ТУСЫН НАРАСЫЙЛАР!!!
ТӘГӘРӘШЕП  ҮСЕП  ТОРСЫННАР!!!
ГӨРЛӘП ТОРГАН ДАНЛЫ ХАЛКЫБЫЗНЫҢ-
БӨРКЕТ-ЛАЧЫННАРЫ  БУЛСЫННАР!

ЙӨГЕР ӘЙДӘ, ҖИТЕЗ КУЯНЫБЫЗ!!!
РӘХИМ ИТ СИН ЗАМАН  ТҮРЕНӘ!!!
БАРЛЫК УЙ-ХЫЯЛЛАР ЧЫНГА АШСЫН!
ЫШАНЫЧ БИР БЕЗНЕҢ КҮҢЕЛГӘ!
*****************************************

К Ү Л Ә Г Ә.

КАЙДА БАРМА МИННӘН КАЛМЫЙ,
НАДОЕЛ  БУ  КҮЛӘГӘ!
ӨЙГӘ КЕРСӘМ-АРТТАН КЕРӘ,
КЕРӘ ХӘТТА БҮЛМӘГӘ!

КИЧ ҖИТКӘЧ КЕНӘ ЮГАЛА,
АРТТАН КАЛМЫЙ КӨН БУЕ!
БАЛЫК ТОТСАМ-УЛ ДА ТОТА,
НИДӘ ИКӘН БАР УЕ?

МИНЕ БОЛАЙ ЭЗӘРЛЕКЛӘП,
ЙӨРЕМӘ СИН, КҮЛӘГӘ!
ЯЗМЫШЫМНАН КӨЛГӘН КЕБЕК,
СИН ЙӨРИСЕҢ ЭРГӘМДӘ!

АШАРГА ДА СОРАМЫЙСЫҢ,
ТӘМӘКЕ ДӘ ТАРТМЫЙСЫҢ!
БАРЫ БЕР МИРАЖ КЕБЕКСЕҢ,
НИК АРТЫМНАН КАЛМЫЙСЫҢ?
=============================

"БАШЛАР ИСӘН БУЛСЫН"

КҮПТӘН ТЫНДЫ СУГЫШ ЯЛАННАРЫ,
БОМБАЛАР ДА ИНДЕ ШАРТЛАМЫЙ.
ЯКЫННАРСЫЗ КАЛГАН АНАЛАР ДА,
СУ БУЕНА ТӨШЕП ЕЛАМЫЙ!!!!

БАШЛАР ИСӘН БУЛСЫН! КИРӘК ТҮГЕЛ
ЯВЫЗ СУГЫШ БЕЗГӘ! КАНКОЕШ!
АЗМЫ ГОМЕРЛӘРНЕ ӨЗЕП ТАШЛАП,
КАН ЧЫГАРДЫ КҮЗДӘН БУ СУГЫШ!

ИРЕНЕНДӘ ӘЛЕ АНА СӨТЕ,
КИБЕП ӨЛГЕРМӘГӘН ЕГЕТЛӘР.
СӨЮ УЧАГЫНЫҢ НИ ИКӘНЕН,
ТАТЫП ӨЛГЕРМӘГӘН ГОМЕРЛӘР.

"КАЙТТЫ" АЛАР ЦИНК ТАБУТЛАРДА,
КАЙТТЫ АЛАР КУЛСЫЗ-АЯКСЫЗ.
КАЙТКАНЫ ДА ЧИРЛЕ,КОНТУЗИЯ
ЯСАП КУЙГАН ЭШКӘ ФАЙДАСЫЗ.

БАШЛАР ИСӘН БУЛСЫН! БУ ТОРМЫШТА
ЯШӘР ӨЧЕН ИКЕ БАШ КИРӘК.
ТОРМЫШ УПКЫНЫНА ТӨШМИ КАЛГАН,
ЯШӘҮЧЕЛӘР ХӘЗЕР БИК СИРӘК.

ҮЗ-ҮЗЕҢНЕҢ КАДЕРЕҢНЕ БЕЛЕП,

ТАТЫП ТОРМЫШ АЧЫ-ТӨЧЕСЕН.

ЯШИК ӘЛЕ-БАШЛАР ИСӘН БУЛСЫН,

КАЛГАНЫНА ШАЙТАН ТӨКЕРСЕН!

========================================

САРЫ ЯФРАКЛАР.

мәрхүм сабакташым Мансурның якты истәлегенә

АЛТЫН КӨЗНЕҢ САРЫ БИЛГЕЛӘРЕ

УРАМ ТУЛЫ САРЫ ЯФЫРАК.

ДУСЛАР ТАБЫЛСАЛАР ШАТЛЫК АРТА!

ТИК ЮГАЛТУ ГЫНА АВЫРРАК.

ХУШЛАШМЫЙЧА ГЫНА КИТЕП БАРДЫҢ

ДУСТЫМ МАНСУР БЕЗНЕҢ АРАДАН.

ЯМАН ЧИРЛӘР БОГАЗЫҢНАН АЛДЫ

КОТКАРМАДЫ СОҢГЫ ЧАРАДАН.

СИН БУЛМАГАЧ, МОҢСУЛАНЫП КАЛДЫ

БЕЗНЕҢ АУНАП ҮСКӘН КАЕНЛЫК.

ТИК ЙӨРӘКТӘ МӘҢГЕЛЕККӘ КАЛДЫҢ

БУЛСА ИДЕ  ЮЛЛАР КАЙТЫРЛЫК.

ЯТКАН ҖИРЕҢ МАМЫК ТҮШӘК БУЛСЫН!

ТЫНЫЧ ЙОКЛА ДУСКАЙ МӘҢГЕГӘ.

АВЫР ТУФРАГЫҢ ҖИҢЕЛ БУЛСЫН.

СИН МӘҢГЕЛЕК БЕЗНЕҢ ХӘТЕРДӘ!

КАЕННАР ДА КАРТАЙДЫЛАР ИНДЕ,

БЕРӘМ-БЕРӘМ  АВА  БАРАЛАР.

ҮТӘ ТОРА ГОМЕР...ҮТКӘН ЕЛЛАР

ТИК ХӘТЕРДӘ ГЕНӘ КАЛАЛАР.

-----------------

2011 елның 28 гыйнварында кичке сәг.18.00 газиз әнием бик каты авырудан соң якты дөнья белән хушлашты-мәңгелеккә күзләрен йомды!

ИСЕМНӘРЕҢ ЙӨРӘК ТҮРЕМДӘ!!!

"ӘНИ!"-ДИЕП ДӘШЕР КЕШЕМ ДӘ ЮК!

ТОРМЫШ КҮГЕН САГЫШ КАПЛАДЫ.

ТАГЫН БЕР ГОМЕРНЕ АЧЫ ЯЗМЫШ,

САБАГЫННАН ӨЗЕП ТАШЛАДЫ.

ТУГАН ЙОРТКА КАЙТСАК, КАРШЫЛАРГА

ӘНИ ДӘ ЮК ХӘЗЕР АВЫЛДА!

"БАЛАКАЕМ ИСӘН-САУ БУЛ!"-ДИЕП,

ФАТИХАЛАР БИРЕП КАЛЫРГА.

"ӘННӘ!"-ДИЕП ОРАН САЛА-САЛА,

ЯКТЫ ДӨНЬЯЛАРГА ТУАБЫЗ.
АНА СӨТЕ, АНА НАЗЫ БЕЛӘН
БУЙГА ҖИТЕП, ТОРМЫШ КУАБЫЗ.

ЧИКӘЛӘРГӘ КАРЛАР КУНЫП БЕТӘ,
ОНЫКЛАРДА КӨТЕП АЛАБЫЗ.
ТИК ҺАМАН ДА ГАЗИЗ ӘНИ ӨЧЕН,
БЕЗ БАЛАКАЙ БУЛЫП КАЛАБЫЗ!

РӘНҖЕМӘССЕҢ ӘНИ -ГОМЕР БУЕ,
ЯЛГЫШЛЫКЛАР БИК КҮП ЭШЛӘДЕМ.
БАШЛАРЫҢА, СИНЕҢ МАҢГАЙЛАРГА
ХАТАЛАНЫП, СЫРЛАР ӨСТӘДЕМ.

СИНЕ СОҢГЫ ЮЛГА ОЗАТЫРГА,
КАЙТАЛМАДЫМ-КИЧЕР!РӘНҖЕМӘ!
ЯЗЛАР ҖИТКӘЧ КАЙТЫП КИЛЕРМЕН МИН,
КУЛЛАРЫМНЫ КУЕП КАБЕРЕҢӘ!

ТЫНЫЧ ЙОКЛА ӘНИ!!!КАРА ТУФРАК
МАМЫК ЮРГАН БЫЛЫП ЯБЫЛСЫН.
СИНЕҢ САЛГАН СОҢГЫ СУКМАКЛАРЫҢ,
АК ЭНҖЕДӘЙ КАРЛАР САРЫЛСЫН!

АВЫР ТУФРАГЫҢ ҖИҢЕЛ БУЛСЫН!

УРЫННАРЫҢ БУЛСЫН ҖӘННӘТТӘ!

ҮЗЕҢ КИТСӘҢ ДӘ СИН- ҖАНЫҢ КАЛДЫ,

БЕЗ САКЛАРБЫЗ КАЙНАР ЙӨРӘКТӘ!

========================

НИК  КЕРМИСЕҢ , ӘНКӘЙ , ТӨШЛӘРЕМӘ?

КЫРЫГЫҢ ДА УЗЫП КИТТЕ ИНДЕ

ЕШ  ТӨШӘСЕҢ  ХӘЗЕР  ИСЛӘРЕМӘ.

ИЗГЕЛӘРГӘ АТАП  ХӘЕР  БИРӘМ,

НИК КЕРМИСЕҢ , ӘНКӘЙ , ТӨШЛӘРЕМӘ?

НИК БЕЛМИБЕЗ ИКӘН КАДЕРЛӘРЕН,

ӘНКӘЙЛӘРНЕҢ - ИСӘН ЧАГЫНДА.

НИК КЕРМИСЕҢ , ӘНКӘЙ , ТӨШЛӘРЕМӘ

ШУШЫ ЯЗНЫҢ ГҮЗӘЛ ТАҢЫНДА?

ОЗАКЛАМЫЙ ТОРНАЛАР ДА КАЙТЫР,

САГЫНЫШЫП , ТУГАН КҮЛЛӘРЕНӘ.

ХАТАЛАРЫМ ГАФУ ИТӘЛДЫҢМЫ,

НИК КЕРМИСЕҢ , ӘНКӘЙ , ТӨШЛӘРЕМӘ?

ӘЛЛӘ ҖИЛӘДЕҢМЕ БУ ТОРМЫШТАН?
ОҖМАҺЛАРДА ҖАНЫҢ ТЫНГАНДЫР.
КИЧЕР ӘНКӘЙ ДИЕП СОРАУЛАРЫМ,
БӘЛКИ ЮККА ГЫНА БУЛГАНДЫР!

**********

ХАТЫН БӘЙРӘМЕ!

АШЫГАБЫЗ...АШКЫНАБЫЗ...
ТИЗДӘН ХАТЫН БӘЙРӘМЕ!!!
СРОЧНО ТАБАРГА КИРӘК-
КҮРКӘМ ЧӘЧӘК БӘЙЛӘМЕ!

БУКЕТЛАР ДА КЫЙММӘТ ХӘЗЕР,
УН МЕҢ ДӘ, ЕГЕРМЕЕ МЕҢ!
ГАРЬЛЕГЕҢНӘН КОЕГА ТӨШ,
ИЛИ ЮПИТЕРГА МЕН!

БУЛМЫЙ БОЛАЙ-АКЧА БИТ ЮК!
КИТТЕМ МАЙЛЫ ЭШ ЭЗЛӘП.
ИНҖЕНЕР БУЛЫП УРНАШТЫМ,
АКЧА ТАБАМ МИН ЭШЛӘП.

АЙ БУЕНА ТИР-КӨЧ ТҮКТЕМ!

НАКОНЕЦ ХЕЗМӘТ ХАКЫ.
АЛАР БИРГӘН АКЧАГА ДА
КИЛӘ УН ЧӘЧКӘ БАРЫ!
КӘЕФ ТӨШТЕ...КАЙТАМ ӨЙГӘ...
ТӨШТЕ БОРЫН САЛЫНЫП.
БУКЕТЫМНЫ БҮЛӘК ИТТЕМ,
БЕР КЫЗАРЫП...БЕР ЯНЫП...

ХАТЫН МИНЕ ҮБЕП АЛДЫ!
КЕСӘЛӘРНЕ КАРАДЫ...
"КАЙДА ХЕЗМӘТ ХАКЫҢ?"-ДИЕП,
ЯҢАККА ЧАБАКЛАДЫ...

"БЕР АЙ БУЕ ТРАЙ ТИБЕП,
КАЙДА ЙӨРДЕҢ СИН, МӨРТӘТ!
ИШЕКТӘН ЧЫКМЫЙСЫҢ ХӘЗЕР!
ЯТ КЕР ЮЫП-ҮТҮКЛӘП!"

ХАТЫН СҮЗЕ БЕЗГӘ ЗАКОН!
КӨН ДӘ ИРТӘН КЕР ЮАМ!
КАЙНАТАМ ДА, ҮТҮКЛИМ ДӘ
БАЛКОНГА ЭЛЕП КУЯМ.

АРЫЙ-АРЫЙ ИДӘН ЮДЫМ!
БҮГЕН ХАТЫН БӘЙРӘМЕ!

УФТАНМЫЙМ ДА, СУКРАНМЫЙМ ДА

БҮГЕН АЛАР  БӘЙРӘМЕ!!

----------------------------------------------------

БАЛАЛАР ӨЧЕН ШИГЫРЬЛӘР.

ЧЫРШЫ БӘЙРӘМЕНДӘ БАЛАЛАРГА ЯТЛАР ӨЧЕН  КЕЧКЕНӘ ШИГЫРЬЛӘР

ИРТӘН ИРТҮК КАРЛАР ЯУГАН!

БҮГЕН ЧЫРШЫ БӘЙРӘМЕ.

ЯШЕЛ ЧЫРШЫНЫҢ ЯНЫНДА

БЕЗ ҖЫРЛЫЙБЫЗ ӘЙЛӘНЕП.

*****

КЫШ БАБАЙ ДА БЕЗНЕҢ БЕЛӘН,

ҖЫРЛАП ТА, БИЕП ТӘ АЛА.

ТӘМЛЕ КҮЧТӘНӘЧ ӨЛӘШЕП,

АРКАДАН СӨЕП КАЛА.

********

КЫШЫН АК ТУННЫ КИЯМ,

АК КАРДАЙ-МИН АК КУЯН!

ЧАБЫП КИЛДЕМ БӘЙРӘМГӘ

БҮЛӘКЛӘР ТЕЗЕП КУЯМ.

КАР ЯУСА ДА ИШЕТӘМ:

ИСЕМЕМ-ОЗЫНКОЛАК!

ЯТМЫЙМ АЮ БАБАЙДАЙ

МИН КЫШ БУЕНА ЙОКЛАП!

*********

КАРСЫЛУ КЫЗЫН ИЯРТЕП,
КЫШ БАБАЙ КИЛЕП ҖИТТЕ.
БАРЧАБЫЗГА КҮЧТӘНӘЧЛӘР,
ТӘМЛЕ КӘНФИТЛӘР БИРДЕ.

***********

ӘНӘ "АЮ"ДА КИЛГӘН БИТ,
ЙОКЫСЫННАН УЯНЫП.
БАРЫБЫЗНЫ ДА КӨЛДЕРӘ
ӘЛЛӘ НИЛӘР КЫЛАНЫП.

*************

ТИЕННӘР ДӘ КИЛЕП ҖИТКӘН,
КЫШ БАБАЙНЫ САГЫНЫП.
МАТУР ЧИТЕКЛӘРЕН КИЕП,
ҖЫЛЫ ТУННАР ЯБЫНЫП.

*************

САГЫНЫШТЫК ИНДЕ КӨТЕП,
ТИЗРӘК КИЛЧЕ ЯҢА ЕЛ!
ЯҢА ҖЫРЛАР ДА ӨЙРӘНДЕК,
ХУШ КИЛӘСЕҢ ЯҢА ЕЛ!

**********

КУРКАК БАТЫР

БОРЫН-БОРЫН ЗАМАНДА-
БИК КАРАҢГЫ УРМАНДА.
ЯШӘГӘН ДИ БЕР КУЯН,
ҮЗЕ БИК КУРКАК БУЛГАН!

КУРЫККАН УЛ СУЫКТАН,
ҖИЛ СЕЛКЕТКӘН КУАКТАН
ШУЛАЙ КУРКЫП КӨННӘР БУЕ
ТӨНЕН ЙОКЛАРГА ЯТКАН.

УРМАНГА АЮ КИЛГӘН!!!
"АЙ-ҺАЙ-МИН БАТЫР!"-ДИГӘН.
ЮЛДА ЯТКАН БҮРӘНӘНЕ
АЛГАН ДА КҮККӘ ЧӨЙГӘН!

КУЛЫН КУЕП БИЛЕНӘ
КИЛӘ КУЯН ӨЕНӘ.
ИШЕККӘ ШАК-ШОК БӘРГӘН-
"КЕМ ТОРА МОНДА?"-ДИГӘН.

КУЯН АГАРЫП КАТКАН!
ҖАЙЛАП ТӘРЗӘНЕ АЧКАН.
АННАН СИКЕРЕП ТӨШКӘН ДӘ
УРМАНГА КЕРЕП ЧАПКАН.

КУЯННЫҢ ЧАПКАНЫН КҮРЕП,
АЮ КУРКУГА ТӨШКӘН.
"НИНДИ ХАЙВАН ИКӘН?"-ДИЕП,
УЙЛАП БЕР АРТКА ЧИККӘН.

БАРЫП БАСКАН ТЫРМАГА!!!
БАШЫН БӘРГӘН ЧОРМАГА!!!
АВЫРТУДАН ЕЛЫЙ-ЕЛЫЙ
КЕРЕП КАЧКАН УРМАНГА.
========================

ШАЯН КӨЧЕК

Безнең Лада алып кайтты
Урманнан нәни көчек.
Үзе шаян...Үзе җитез...
Күзләре йолдыз кебек!

Мин уйнарга чыгам дисәм,
Ул иң алдан йөгерә.
Туп артыннан да чаба ул,
Баскычтан да сикерә!

Чалбар балагыннан тарта-
"Тешли" аяк-кулларны.

"Ырр!Ырр!" килеп тырнап йөри

Мәче йөргән юлларны.

Кичтән йокларга ятканда,

Куенга кереп ята.

Иртән-иртүк аягымнан

Тарта-тарта уята.

Песиләр белән талаша,

Ай-һай усал бу көчек.

Үсеп җиткәч сакчы булыр,

Рекс һәм Мухтар кебек!!!

========================

"БАЛЫКЧЫ"ЛАР

..................................................

КӨН ДӘ БАЛЫК ТОТАБЫЗ ДИП,

ЧАБАБЫЗ КҮЛ БУЕНА.

ЯР БАШЫНДА КАРМАК САЛЫП,

ЯТАБЫЗ КӨН БУЕНА.

ТАМАК ТА АЧ!!!КИЕМ ЮЕШ!!!

ЧЕБЕШ АЯК-КУЛЛАРДА.

ЯЛАНТӘПИ ЙӨГЕРӘБЕЗ

ТУЗАН ОЧКАН ЮЛЛАРДА.

БАЛЫК УЙНЫЙ-КҮЗЛӘР УЙНЫЙ!

ТОТТЫРМЫЙ  ШУЛ ХӘЙЛӘКӘР!

КАЙДА БУЛГАН КЫЗЫЛКАНАТ?

ЙОКЛАГАННАР ЧҮКӘЛӘР...

СУАЛЧАНГА КЫЗЫКМЫЙЛАР,

ЧИРТМИЛӘР ИПИГӘ ДӘ.

ӨЧ МАЛАЙГА ИКЕ ПИСКАР-

ТОТЫП КАЙТАБЫЗ ӨЙГӘ.

*****************************

*****АТАКАЗ****

ҺИЧ БЕРКЕМНӘН КУРЫКМЫЙДА

БИК БАТЫР МАЛАЙ-АЛМАЗ.

ҖИЛДӘЙ ҖИТЕЗ...ДУСЛАРЫ КҮП!

ТИК БЕР ДОШМАН-АТАКАЗ!

ӘГӘР КАЗЛАР ЫСЫЛДАСА

ЙӨРӘГЕ ДӨП-ДӨП ТИБӘ.

АТАКАЗНЫ КҮРСӘ БИК ТИЗ

АГАЧ БАШЫНА МЕНӘ!

-ҮСКӘЧ КЕМ БУЛАСЫҢ?-ДИСӘК,

-МИН БУЛАМЫН ОЧУЧЫ!

БУЛСА ӘГӘР АТАКАЗНЫҢ

ТОМШЫКЛАРЫН ТОТУЧЫ!

===============================

МИЛӘҮШӘ

БИК ТӘ МӘЗӘК МИЛӘҮШӘ

КУРЧАК БЕЛӘН СӨЙЛӘШӘ,

АРКАСЫННАН СӨЯ-СӨЯ

"БӘБКӘЕМ"-ДИП ЭНДӘШӘ.

КУРЧАГЫ ДА БИК ЧИБӘР!

КОЕП КУЙГАН МИЛӘҮШӘ.

БИШЕГЕНӘ САЛЫП КУЙСАҢ:

"ӘННӘМ,ӘННӘМ!» ДИП  ДӘШӘ.

*************************

ХИКӘЯЛӘР,ПРОЗА ӘСӘРЛӘРЕ.

================

БАЛАН ЧӘЧКӘСЕ.

Быел яз бик салкын булды...Кояшка чыгып кызынырдай көннәр бармак белән генә санарлык-шаккатмалы хәл!Шуңа карамастан вакытыннан соңлабрак булса да шомырт чәчкә атты!Аннан инде...алмагачлар,чияләр...Ә миләш белән балан ашыкмады...Алар,гүя серләшкәндәй, язның җылы көннәрен көттеләр...

...Нәфисә унынчы сыйныфны бетереп,мәктәптә үткән соңгы звонок - 25 май көн иде.Алар бар класс белән кичтән Ташлы елгасы буена җыелдылар.Егетләр тиз генә утын җыештырдылар,казан асып ут ягып җибәрделәр-кызлар аш пешерергә кереште.Нәфисә өйләреннән бәрәңге белән суган алып килгән иде,шуларны чистартырга кереште.Карашы белән сабакташы Зиннурны күзәтте...Киң бәдәнле,озын буйлы,кара бөдрә чәчле бу асыл егетне мәктәптә күзләре төшмәгән кызлар калмагандыр инде!Аны мәктәптә балачактан яшьтәшләре "Цыган" дигән кушамат белән атап йөртәләр иде!Исеменә күрә җиселе-чегән егетләренә хас җитезлек,кызу

характер,уңганлык Зиннурны һәрвакытта өстә йөртте!Ул әйттеме-закон,аңа каршы әйтүче дә,каршы чыгучы да юк иде!Тик Нәфисә генә аның адресына шелтә сүзләрен әйтә ала иде.Алар инде җиденче класстан башлап гел бергә-бер партада,кичке уеннарда да,турслетта да бер-берсеннән аерылмадылар!Кайчагында Зиннур сөйгән кызын кочаклап,иреннәреннән үбәсе,аны иркәләсе килә иде!Тик Нәфисә эшне зурга җибәрми иде: "Соңрак,матурым,соңрак!"-дип яңагыннан гына үбеп ала иде.Сылу гәүдәле,калку күкрәкле,озын толымнары белән дан тоткан куе кара кашлы,коңгырт күзле Нәфисәне читтән генә ике егет-параллель класстан Азат белән Ришат күзәтеп утырды.Алар инде уйлары белән Нәфисәне кочаклыйлар,үбәләр,иркәлиләр иде...Тик Зиннур монда шуул!...Беркемнең дә башында мәкерле уй юк кебек иде-барысы да көлешә-көлешә үз эше белән мәшгүль булды...

Тиздән яланга хуш исләрен чәчеп,тәмле аш пешеп чыкты!Чәйгә дигән казан да күптән кайнап чыккан-мәтрүшкә белән чәй саласы гына!Кызлар күмәкләшеп табын әзерли башлады,егетләр ярдәм итте.Инде кояш та баеп килә-көнбатыш ягыннан алсу шәфакъ нурлары кабынды.Егетләр кайсы гармун,кайсы магнитофон,гитара алып килгәннәр-моңлы,дәртле көйләр яңгырады.Тәмле ашны ачыгулары да җиткәндер инде,тиз ашап куйдылар.Яшереп кенә алып килгән винолар,сыралар чыга башлады.Егетләрнең кайберләре аракыдан да баш тартмыйлар-тик Зиннур аракы эчми иде!Ришат аны чакырып алды:

-Цыган,әйдә соңгы звонок өчен берне эч инде!-дип аңа ярты стакан аракы сузды.

-Юк,егетләр,рәхмәт,мин сыра гына эчәм!

-Әйдә егетлегеңне күрсәт!Без бит сине барыбыз да хөрмәт итәбез,өстен күрәбез-күрсәт әйдә  лидер икәнеңне!Шул гәүдәң белән ярты стакан аракыдан куркасыңмы...

Әллә Ришатның әйткән сүзләре,әллә шайтан котыртты-Зиннур бертын белән эчте дә куйды.

Кызлар да җайлап кына вино эчтеләр-каннарын йөгерттеләр!Нәфисә ахирәте Лиза белән үз йомышлары белән әрәмәлеккә таба китте,ә Зиннур Ришатның фәлсәфәсен тыңлап утыра бирде.

Аракы аның канын кайнарлатты,зиһенен чуалтты,инде күзләре томаланды һәм чирәм өстенә авып,каты йокыга талды...

-Син җитәрлек салдыңмы? -Ришат Азатка сораулы карашын төбәде.

-Курыкма-иртәгә төшкә чаклы йоклаячак!5 таблетка финазепам!-дип пышылдады тегесе.

Музыка көчәйде-инде биергә төштеләр.Нәфисә карашы белән Зиннурны эзләде-тик караңгы төшкән иде инде!Ул пошына башлады-егетләрдән сорашты,тик берсе дә Зиннурның кайда икәнен белми иде! Ниһаять Нәфисә Азатны танып алды:

-Азат,син Зиннурны күрмәдеңме?

-Әнә палаткада ул!Исерек!- дип мыскыллы елмайды ул.Нәфисә Азатка ачулы карашын ташлап,читтә торган палаткага табан китте.Шулчак аны арттан килеп ике ягыннан тотып,авызын каплап, ике егет палаткага алып кереп китте.Ичмасам tанырлык та түгел караңгы,болытлы төн иде...Аның авызына көчләп ярты стакан аракы койдылар,кулларын каерып бәйләделәр...

Төне буе пыскып кына яңгыр яуды-инде таң алдыннан җил чыкты.Яшьләр кайсысы кайсы палаткага урнашып,алмаш-тилмәш учакта җылынып,җырлашып утырдылар.Тик берсенең дә башына мондый кабәхәтлек,мондый ерткычлык булганлыгы килмәде.Җил көчәйгәч,алар әйберләрен җыештырып,кайтырга чыкты.Инде нәрсә эшләргә белмәгән Лиза да аларга иярде.

Яланда бары бер палатка торып калды...

Көн үзәге җитәрәк кенә ушына килде Нәфисә...Киемнәре ертылып беткән,аяк-куллары,түшләре күгәреп чыккан-кендек астында бик каты авырту тойды ул!Кичәге кичне исенә төшерергә тырышты..Шуышып барып,палатканың авызыннан башын тыгып карады.Кояш чыккан,ялан сихри хуш ис белән тулган,әрәмәлектәге баланнар чәчкә аткан!Әле кичә генә яшеллеккә күмелеп утырган әрәмәлек ап-ак булган!Ярсып елый-елый кире урынына барып егылды Нәфисә!Инде авыртуы да көчәйде-башы чатнап авыртты.Киемнәрен капшап карады-бер киеме дә юк-ул анадан тума шәрә иде...Ярсып бетте инде елый-елый,янәшәгә мотоцикл килеп туктаганын да сизмәде.Палатканы киң итеп ачып ташладылар-тышта аның әнисе белән әтисе басып тора

иде...Канга батып беткән бердәнбер кызларын шушы рәвештә күреп,әнисе йөрәген тотып тынсыз калды! Палатканың бер почмагында шәп-шәрә Зиннур ята!

Билендәге чалбар каешын ычкындырып,ачуын кая куярга белмәгән әти кеше эчкә узып кызының өстенә ертык күлмәк кисәкләрен ыргытты да,берни белми йоклап яткан Зиннурны каеш белән кыйный башлады.Көчле авыртудан Зиннур бик тиз ушына килеп,чак ычкынды Закир абыйсының кулыннан.Чалбарын кия-кия алдына-артына карамыйча әрәмәлеккә таба йөгерде.Ярсыган Закир инде кызын тукмый башлады:" ...ах син сөйрәлчек,кара син аны әле кулына документ алмаган килеш чегән азгыны белән көпә-көндез анадан тума шәрә калып яталар!..."-дип әйтә-әйтә кызын каеш белән ярды.Әнисе ирен туктатырга маташты,кычкырып та карады-тик тавышы чыкмады,калак сөяге астыннан әйтерсең лә кемдер очлы тимер тыккандай,4 тапкыр кысып алды...Ул акрын гына сыгылып төште дә,бөтенләй тынсыз калды...

Инде ярсып,чыгыры чыккан ир,күзләрен акайтып Зиннурны эзләп әрәмәгә таба кереп китте.

Нәфисә барлык көчен җыеп,әнисенә дәште:"...Әни!Әнииеем!". Инде әнисенең суына башлаган гәүдәсенә таба килеп,аның кулларын үбә башлады,бит очларын,муеннарын үпте.Кинәт кенә аңына килеп йөрәген,пульсны тыңлады.......Тик әнисенең йөрәге типми иде инде!Нәфисәнең күз аллары караңгыланып калды-һәм еракта яктылыкка таба очты кыз...

Авылда шомлы хәбәр тиз таралды-халык гөж килде!Укытучылар,барлык укучылар җыелыша башлады....."...Закир кызын көчләгәннәр!..","Зиннур белән Нәфисә бергә кунганнар!","Закир Зиннурны эзли-таба алмый!".Тик Ришат белән Азат кына бер ни булмагандай,бик җитди кыяфәттә читтә тордылар!Аларның планы тормышка ашты бит!Ришат ике ел Нәфисәне кыз килеш үзенеке итәргә тырышып йөрде һәм кичә максатына иреште...Азат белән Маратка да татлы җимештән "авыз итәргә" рөхсәт булды!Зиннур "крайний"булып калды! Ришат Азатка карап күз кысты да,баш бармагын өскә күтәреп куйды-"во!" янәсе!

Укытучы Камил Сабирович 7-8 егет белән иң беренче килеп җитте яланга! Иң башлап палаткага күз салган Дамир кычкырып

җибәрде...Эчтә яткан һушсыз Нәфисәне укытучылары тиз генә ясалма сулыш алдырып,аммиак иснәтеп җан кертте.Тик әнисенең гәүдәсе суынган иде!Бик тиз генә милициягә,"Ашыгыч ярдәм" хезмәтенә шылтыраттылар һәм Зиннурны эзләргә керештеләр.Зиннур электән үк Камырлавык тавына сәяхәт итәргә ярата иде.Хәтта ул шалаш та ясап куйган имеш дип сөйлиләр иде.Монда камырлавык күп үсә иде-бигрәк тә тау битендә,шуңа инде исеме дә Камырлавык!Элек бу якларда аю да булган дип сөйлиләр-дөресме,юкмы...

Зиннур чак тын ала-ала килеп керде шалашына.Монда аның сәкесе бар-түмәр урындык һәм өстәл ролен үтәгән иске умарта корпусы.Яшергән урыннан ачкычын алып,умартаның капкачын ачты-аннан агачка үрмәли торган аркан,бер кап шырпы һәм чит ил тәмәкесе алды.Эче пошканда шунда килеп,тәмәке көйрәтеп китә иде ул!Нишләп болай килеп чыкты соң әле!!!Аракы эчкәнен белә ул-калганын менә баскан урынынан ходай суксын -хәтерләми...Инде үз күзләре белән Нәфисәнең мыскыл ителгән гәүдәсен күргәч-ул үзен гаепле итеп тойды!Ничек итеп авылдашлары алдына,әти-әниләре каршына чыгып басар?Әнисе күзенә ничек карар?Нәфисәнең туганнары нәрсә дияр?Бу сораулар аның җанына тынгылык бирмәде. Тәмәкенең йогынтысы бик тиз башына менде-җиңеләеп калды.Блокнот белән каләмен алды да умартан ябып,яза башлады:

"Кадерле әти-әнием,туганнарым,авылдашларым!!!Бик зур хата эшләгәнмен-гонаһым өчен Ходай каршында гаебемне үз гомерем белән,үземнең сулышым белән түлим!Ачуланмагыз,хушыгыз!!!"

Ашыгып кына язуын кесәсенә салды һәм арканын алып агач башына үрмәләде..

Милиция һәм "Ашыгыч ярдәм" хезмәткәрләре бик тиз килеп җиттеләр.Авылдашлары инде Зиннурның да гәүдәсен тапкан иде-башта барып,аның мәетен алып килделәр.Класстагы егет-кызлардан сораулар алып,инде тәмам кеше төсе калмаган Нәфисәне култыклап машинага утырттылар,хатынының үле гәүдәсе кырында тынсыз калган Закирны бер читкә борып,Нәфисәнең әнисен дә машинага салдылар...Ярты авылдан күп халык җыелган иде инде-бу фаҗига барсының да күзләренә кайнар яшьләр тамызды!Хәтта бүген генә таңда чәчәк аткан баланнар да елый иде бу минутларда!!!

Ике көннән бөтен авыл белән аларны зурлап күмделәр.Тик Нәфисә генә кайта алмады-аны Уфага озатканнар.Акылдан шашкан диделәр...

Бу кадәр кансызлыкны,бу кадәр вәхшилекне уйлап чыгарып,тормышка ашыручы үсмерләр берни булмагандай яши бирделәр.Ришат авыл хуҗалыгы техникумына укырга керде,аны тәмамлап хәрби хезмәткә алынды.6 ай Воронеҗ шәһәрендә учебкадан соң Афганстанга эләкте.Аннан бары "Хәбәрсез югалды!"-дигән язуы гына килде.Азат мәктәпне бетергәч,училищеда шофер һөнәрен үзләштерде.Себердә аварияга очрап,1 группа инвалид ул хәзер.Нәфисәнең әтисе Закир ачы кайгыдан эчкечегә әйләнде-инде йорт-кура җимерелеп беткән,утсыз-газсыз йортта яши.

Беркөнне авылга акрын гына якынлашып килүче чит ил машинасы күренде.Алар Закир яшәгән йортка туктады-ул капка төбендә ничек итеп баш төзәтү уе белән утыра иде!Инде 5 ел пенсия алса да-бурычтан чыкмый башы.Капка төбенә шундый затлы машина килеп туктагач,берчә шикләнде,берчә сөенеп куйды.Машинадан озын ак костюм кигән кап-кара чәчле ир-ат һәм озын толымлы чәчләрен купшы итеп үреп куйган,матур гәүдәле ханым төштеләр.

Зәңгәрсу күлмәк,алтын алкалар,алтын йөзекләр аның бик тә килешле йөзенә тагын да матурлык өсти иде!Карашы белән Закирга карап торды да,акрын гына татарчага якын тел белән:"Саумысыз атии!" -дип,Закирга таба атлады. "Кызыымм!Нәфисәәм!"-ул тамагына утырган тоенне йотарга тырышып,кызын кочаклап алды.Күзләренә бәреп чыккан кайнар яшен тыярга теләп,кызын сөйде.Аннан читтә торган кунак ир белән бик җылы күрешеп алдылар."Надзим!"-дип таныштырды ул үзен.1984 елны Нәфисә Уфада дәваланып яткан хастәханәдә практика үткән булган ул-үзе Төркиянеке икән.Бер караудан Нәфисәне охшаткан,һәм аның ай-ваена куймыйча үзе белән Төркиягә алып кайткан.2 ел дәвамында тәҗрибәле белгечләр кызны аякка бастыра,какшаган нерв системасын дәвалыйлар,тик Нәфисә беркайчан да балага узалмас булып кала.Балалар йортыннан ике сабый алып тәрбияләп үстерәләр,хәзер инде дәү әни булган Нәфисә!Тиз генә өйләрне җыештырып,идәннәрне юып чыгардылар!Юкә мунчала белән идәнне ышкып-ышкып юуу Надзимга хәтта ошап та китте!Ошамаслык мени-ничәмә еллар су күрмәгән карагай идән сап-сары гәрәбәдәй ялтырап калды.Нәфисәнең кайтканы инде бөтен авылга таралды-менә өйгә элекке дуслары,классташлары

килә башлады.Ярый әле Нәфисә барысын да күз уңында тотып,барчасына да җитәрлек итеп бүләкләр алган иде.Кичтән бик озак сөйләшеп,хатирәләрне искә төшереп сөйләшеп утырдылар,елашып та алдылар.Надзим Закирны утыртып,балыкка төшеп киттеләр.

Икенче көнне иртән торып,өчесе дә зияратка юл алдылар.Әнисенең каберен тәртипкә китереп,чәчкәләр салып куйды Нәфисә."И-и әнием,тыныч йокла инде яткан ерен тушак булсын!Җанын оҗмахта болсын!!!"-дип укынып та алды.Аннан Зиннурның каберен эзләп таптылар.Ул бер читтә иде..Кемдер балан утырткан мы-үзе шулай үсеп чыкканмы -шау чәчәктә балан куагы утыра иде.Әйтерсең лә теге әрәмәлек-шаккатмалы хәл!Бөтен дөньяга хуш исен чәчеп,балан шомлы гына нидер сөйли,нидер көйли кебек иде...Тик аны беркем дә аңламады..

Нәфисә кабер өстенә 2 чәчкә куйды да капка ягына табан атлады.Надзим бик матур итеп әрвахлар рухына багышлап,Корьән укыды.Авылга балан чәчәгенең хуш исе белән беррәттән моңлы аваз яңгырады:

Бисмиллаһ ир-рахман ир-рахим,

Әссәламү галейкем, йа бәхет-дәүләт!

Әйү вә хуш кил, йа бәхет-дәүләт!

Көйләр белән кил, йа бәхет-дәүләт!

Көн вә кояш кебек туа килгел, йа бәхет-дәүләт!

Йагмур кебек ява килгел, йа бәхет-дәүләт!

Кар кебек ява килгел, йа бәхет-дәүләт!

Кыш кебек кышлайу килгел, йа бәхет-дәүләт!

Сәгадәт кабалын ала кил, йа бәхет-дәүләт!

Сөенечлек берлә кил, йа бәхет-дәүләт!

Нигъмәт капугын ача кил, йа бәхет-дәүләт!

Рәхмәт нурын чәчә кил, йа бәхет-дәүләт!

Май 2011 ел.










Сынган канатлар.

(Чын хәлләрдән алынды,геройларның исемнәре үзгәртелмәде)

Бүген иртә йокыдан уянды Рөстәм. Үзалдына әкрен генә укынып, аяк-кулларын җайлап-җайлап кына кузгатып алды. Инде хәрәкәтсез калуына 7 ай да үтеп киткән. Көндез коляскада, төнлә урын өстендә үтә аның гомере. Телефонын кабызып сәгатькә күз салды. «Әле сәгагать иртәнге биш кенә...», дип авырсынып куйды. Тагын ике сәгать чамасы ятарга кирәк әле. Телефонның яктысы аша ак стенага, түшәмнәргә күз төшерде ул. Шуннан кинәт кенә Уфада йортсыз кешеләргә ярдәм итү үзәгенә урнашкан вакытлары исенә төште аның. Ул вакытта тәмуг газапларыннан котылып, оҗмаһка килеп эләккән җан иясед әй тойды ул үзен. Анда килеп урнашканнан соң Рөстәмне республика хастаханәсенә салдылар. Тәҗрибәле табиблар аның бар организмын тикшерде. Рассеянный склероз дигән яман чир белән авырганын ул бары шунда гына белде. Бу инде балачагында кан

чиреннән калган авыру. Аңа II группа инвалидлыкны бирделәр. Хастаханәдә ятканда Рөстәм янына дусты Руслан килеп йөри иде. Руслан... Аның белән Рөстәм өч ай элек кенә танышкан иде. Әле ярый аны очратты, әгәәр язмышы аны шушы кеше белән туры китермәгән булса, ничек буласын ул үзе дә күз алдына китерә дә алмый иде инде.

....Көзге салкын көн иде. Үзен-үзе кайда куярга белмичә, көч-хәл белән генә атлап, күңелендә әллә нинди шомлы уйлар уйлап, урамда бик озак йөрде Рөстәм. Инде аяк-куллары тыңламас хәлгә җиткән иде. Бер калтырый башласалар — җаныңны да кайда куярга белмисең инде. Кесәдәге актык акчасына кибеттән бер буханка икмәк белән бер төргәк пилмән сатып алды да, әкрен генә Николай яшәгән йортка юнәлде. Николай аның электән бергә эшләгән танышы. Улы Артем белән генә яши ул. Ике ел элек хатыны инфарктан соң, якты дөнья белән хушлашты. Рөстәм кайвакыт аның янына килеп, кунгалап китә иде. Алар пилмән пешереп ашарга утыргач, ишек шакыдылар. Николай барып ишекне ачты. Таныш түгел кеше үзен Руслан дип таныштырды. Ул дини китаплар, журналлар таратып йөри икән. Русланның акрын гына, тыныч кына тавышы Рөстәмнең җанына ничектер якын булды. Аның карашыннан, акыллы күзләреннән ниндидер җылы нур бөркелә иде сыман. Рөстәм дә бик аралашучан, шуңа да ул Руслан белән бик тиз уртак тел тапты. Алар бар дөньясын онытып, ике сәгатьтән артык сөйләшеп утырды. Өч көннән соң, тагын кереп чыгармын әле дип, Руслан хушлашып чыгып китте. Ул төнне Рөстәм бик озак йоклый алмый азапланды. Таң алдыннан гына изелеп, йоклап китте. Менә шунда ул беренче тапкыр мәрхүмә газиз әнисен төштә күрде.

... Рөстәм, имеш, ниндидер караңгы урман эчендә сазлыкта яфалана. Бөтен өсте пычрак ләмгә  баткан, аякларын сазлыктан тартып алалмый. Бер аягын алам гына дисә, икенчесе бата башлый. Сазлык аны һаман аска суыра. Шул чагында яр башында күкрәгенә сабый бала күтәргән әнисе пәйда булды. “Улым!!!... Рөстәәәм!..” Кулындагы сабыйны сиңа таба суза: «Улым, балаңны ташлама!!!..» Ул шыбыр тиргә батып, куркып уянып китте. Өнемме, төшемме дигән сыман, бик озак уйланып ятты. Улы Эдгарны искә төшерде: «Бүген тагын барып хәлен белеп киләм!», - дигән бер фикергә килде. Көн үзәгендә, аның бәхетенә булгандыр инде, Николайның баҗасы хәл белергә керде. Ул машина белән икән. Рөстәм аның белән балалар

приютына кадәр утырып барды. Монда аны танып торалар инде. Вахтада утырган таза гәүдәле Нина исемле хатын: «Вот, молодец, Эдгарның папашасы килде!», - дип ачык йөз белән каршы алды. Рөстәмнең коридорга узуы булды, каршысына улы үзе йөгереп килеп чыкты.

5-6 яшьләр тирәсендәге теремек кенә сабый иде ул. Зәңгәр күзләре, якты саргылт чәчләре хас әнисенеке инде. «Ура! Папа пришел! Мой дорогой и самый лучший папа!», - дип әтисенең кочагына ук сикереп менде ул. Улын алдына утыртып, коридорда диванда ике сәгатьләп сәйләште алар. Рөстәм аны сөеп туялмады. Эдгар да сабый чактан ук сөйләшергә әвәс иде, гел генә татылдап торды. Үзенең куенына сыенып, аның сөйләгән сүзләрен дә ишетү аңа шулкадәр рәхәт иде. Эдгар уйчан карашын әтисенең чыланган күзләренә төби, кечкенә учы белән әтисенең кулларын, бармакларын иркәли. Менә шундый татлы мизгелләр белән ике сәгать вакытныңң үткәне дє сизелмәде. Аерылышу минутлары гына газаплы булды. Улы, әтисеннең кочагыннан чыгасы килми бик озак торды, моңардан Рөстәмнең күңеле тулды. Чак үзен тыеп торган ир, газиз баласы белән хушлашырга ашыкќты.

Руслан әйткән сүзендә торды. Өч көннән соң алар Николай белән чәй эчеп утырганда килеп җитте ул. Уң кулы белән пальтосын салып чөйгә элде. Русланның сул кулы култык төбеннән үк киселгән — шарфын, чәшке бүреген дә салды Руслан. Кыйммәтле кара костюмы, ачык зәңгәр төсле күлмәге, галстугы аның ыспай гәүдәсенә килешеп тора иде. Ир-егетләр исәнләште, бергәләп чәй дә эчеп алды алар. Руслан бик күп күчтәнәчләр белән килгән. Сумкасыннан икмәк, йомшак кабартмалар, конфет-печеньелар, бер блок «Максим» тәмәкесе ђәм Рөстємгә өр-яңа спорт костюмы да алып килгән. Мондый мул бүләк-күчтәнәчләрдән Рөстәм хәтта уңайсызланып та куйды, күңеле тулып, күзләре дә яшьләнде. Рәхмәт сүзләрен чак әйтәлде ул. Вакыт соң иде инде, Николай бүлмәсендә ятып йоклады. Руслан белән Рөстәм икесе таң атканчы сөйләшеп утырды. Руслан Рөстәмне зур игътибар белән тыңлады, шулай ук үз тормышын да бәян итте, акыллы киңәшләре белән дә уртаклашты.

«Кеше үз язмышына үзе хуҗа. Әгәр бар ихтыярыңны туплап, тормыш төпкеленнән чыгарга теләсәң, шушы теләгең көчле булса, бар авырлыкны да җиңеп чыгарсың. Бик авыр вакытларда ялгызың булганда, бар өметеңне баглап Аллаһыга ялвар, Ходайдан эшләгән хаталарың, гөнаһларың өчен гафу үтен, кичерүен сора. Үзең турында гына уйлама. Үзеңнән көчсезләргә ярдәм ит,  хәлсезләргә — куәтеңне бир. Өлкәннәр әйткән сүзләрне тыңла. Кешеләр биргән киңәшләрне беркайчан да кире какма. Әгәр вакытында тәнкыйтьне кабул итсәң, эшләгән хаталарыңны танысаң — Ходай сине ярдәменнән ташламас!..»Русланның әлеге сүзләрен Рөстәм һаман да хәтерли. Гомумән, Руслан аның өчен изге кеше булып калды. Берничә көннән соң Руслан Рөстәмне яшәү урыны булмаганнар өчен вакытлыча торакка урнаштырды. Күп тә үтмәде Эдгарны да балалар йортына тапшырдылар.Бу хакта Рөстәм белми дә калды. Монда да әлеге дә баягы Руслан ярдәмгә килде. Ул Рөстәмне Октябрьскийда яшәгән Владимир белән таныштырды. Аның элемтәләре дә юк түгел. Шулай итеп Володя ярдәмендә Эдгарның балалар йортын эзләп тапты алар. Ләкин суд Рөстәмне ата булу хокукыннан мәхрүм итте шул. Шул чакта әтисе Фасих абыйның аңа васыять итеп әйтеп калдырган сүзләре исенә төште: «Улым! Өйләнеп, балалар үстереп яшәргә тырыш. Безнең нәсел агачын дәвам ит!».

Әйе... Рөстәм әтисенең васыятен үтәде. Улы аның исемендә, димәк Хәбризаловларның нәсел җебе өзелмәде. Тик газиз баласы гына аның янында түгел шул.

Рөстәмне Октябрьский картлар һәм инвалидлар йортына урнаштырдылар. Тик менә улы Эдгар да балалар йортында бик озак тормады. Улының тәрбиячесе һәрчак элемтәдә булгач, аңардан Эдгарны Кырмыскалы районында гомер итүче бер гаилә  үзенә патронаж тәрбиягә алуын белде. Хәзер инде Эдгарның әти-әнисе Мөдәрис белән Гөлсара. Үзләренең ике улы һәм бер кызы бар. Йорт хуҗасы — фермер, Гөлсара ханым — хуҗабикә. Менә шундый хезмәт сөйгән , матур гаиләдә яши хәзер Эдгар. Яңа әти-әнисе аны Рөстәмнән аермады. Алар көн дә диярлек телефоннан аралашты, елына берничә тапкыр алар Октябрьскийга да килеп йөрде. Улының эшкә  өйрәнеп, укуында сынатмавын белеп торган Рөстәмнең күңеле тыныч иде. Улы турында уйланып утырганда, Рөстәм күңелендә үзенең балачак хатирәләрен дә яңартты.

....Рөстәм Уфада гади эшче гаиләсендә дөньяга килде. Әтисе Фасих абый гомере буе Уфа моторлар төзү берләшмәсендә эшләде. Менә шушы эше аның сәламәтлеген дә какшатты да инде. Астма авыруыннан җәфа чиккәннән соң, инвалидлык төркеме биреп, эшеннән бушаттылар. Күп тә үтмәде, шушы чир аны 49 яшендә якты дөньядан да алып китте. Бик авыр кичерде Рөстәм бу югалтуны. Нигә тормыш шундыйга әйләнде соң әле?Әллә язмыш мәрхәмәтсезме аңа? Әллә гаеп үзендәме?

Авырлыклар аны балачактан ук озатып килде. Ул чирләшкә бала булып үсте. 8 яше тулгач, аның хәле тәмам кискенләште, елга якын дәваханәдә үлем белән көрәшеп ятты ул. Ярый бәхеткә, кан чире артка чигенде, тик баланың организмында үзенең тирән яралы эзләрен салып калдырды.

Икенче классны ул өйдә генә укыды. Шул рәвешле әти-әнисе аны авырлыклардан сакларга тырышты. Тик менә кирәк чагында Фасих абый белән Зилә апаның игътибары җитмәде Рөстәмгә. Малай начар юлга баскан яшьтәшләре белән дуслаша, урам йогынтысына бирелә. Тәмәке тарта башлый, соңрак токсикологик матдәләр дә, наркотиклар да куллана башлый.

Мәктәптә укыганда ук Рөстәмнең күңелендә беренче мәхәббәт очкыннары кабына. Ул үзенең классташы Татьянага күз атып йөри башлый. Алар бергәләп төнге клубларга, киногa йөри. Татьяна да әдәпле кыз булмый, шундый ук бозык тормыш алып бара. Рөстәмгә 17 яшь тулганда, кыз авырга кала, яшьләр өйләнешә. Туйдан соң егет йортында яши башлыйлар. Булачак бала хакына Рөстәм белән Татьяна авыр булса да, начар гадәтләрдән арынырга көч таба. Бу очракта Рөстәмнең әти-әнисенең ярдәме дә зур булды. Тик дөрес юлга бассалар да, соң була. Озак вакыт наркотиклар куллануның нәтиҗәсе фаҗигале булды: балалары үле туды. Нишлисең, язмыштан узмыш юк диләр, үлгән артыннан үлеп булмый. Арытаба яшәргә кирәк, тормыш бит дәвам итә. Рөстәм заводка слесарь булып эшкә урнаша, Татьяна өйдә генә утыра. Тормышлары бер җайга салынгандай була. Бер-бер артлы кызлары Алена һәм уллары Артем дөньяга килә. Көтмәгәндә гаиләгә тагы кайгы килә. Рөстәмнең әнисе Зилә апаның гомере фаҗигале өзелә. Ул кер юганда электр тогына сугыла. Аңардан соң күп тә үтми әтисе Фасих абый да бакыйлыкка күчә. Тора -бара дөнья йөген тарту тулысынча Рөстәм җилкәсенә торып кала. Чөнки

Татьяна эштән тыш вакытын гаиләсе белән түгел, ә ахирәтләре белән үткәрергә гадәтләнде. Рөстәм боларның барысына да күзен йомды, ничек тә гаиләсен саклап калырга тырышты. Хатынының атналар буена өйгә кайтып кермәвен, яңадан бозык юлга басып хәмер куллана, тәмәке тарта башлавын да гафу итте. Тик бу тырышулар барысы да юкка гына булды. Ана сөте белән кермәгән, тана сөте белән керми, дип юкка гына әйтмәгәннәр бит.

... Чираттагы Яңа ел бәйрәмен алар Татьянаның әти-әнисендә үткәрергә булды. Бәйрәмнәре бәйрәм төсле булмады. Барысы да шактый гына хәмер белән сыйланып, тиргәшеп, кайсы кайда урын табып йоклап китте. Таң белән Рөстәмне аракыга кибеткә чыгарып җибәрде өйдәгеләр. Подъездга чыккач, Рөстәм Татьянаның күршесе Александра белән очрашты. Килешле итеп киенгән, саргылт чәчләрен иңнәренә таратып салган бу кызга игътибар итми мөмкин түгел. Өстәвенә, алар бер класста да укыган иде. Мәктәптән соң ул күптәнге хыялы белән медицина университетына имтиханнар бирде, тик конкурс аша үтә алмады. Әлеге вакытта ул сукырлар җәмгыятендә эшли. Кыз Рөстәм белән күреште. Алар бер-берсен бәйрәм белән котлап, матур теләкләрен җиткерде. Александра хәтта аның бит очыннан гына үбеп тә алды. Шуннан соң алар бергәләп кибеткә китте. Юл буена алар мәктәп елларын хәтердә яңартып, көлешә-көлешә барды. Кибеткә кергәч Рөстәмнең башына кинәт кенә бер уй килеп керде.

— Саша! Әйдә безнең өйгә киттек, анда беркем дә юк. Бераз бәйрәм итеп, күңел ачып утырырбыз. Кыз ялындырып тормыйча ризалашкач, Рөстәм аракы-шәраб, җимеш һәм башка тәм-томнар алды да, алар өйләренә таба атлады. Өйгә кайту белән чәй куеп, өстәл әзерләделәр. Шәрабтан авыз иткәч, Рөстәм магнитофонын кабызды, бүлмә буйлап вальс көе агылды. Алар биергә төште. Рөстәм яшь кызның зифа гәүдәсен, аның кайнар сулышын тойды. Шулай итеп, бер-берсенә сыенып, шәраб һәм сөю хисенә исереп озак кына вальс әйләнде алар! Икесе дә күңелләрендәге хис-тойгыларын тезгенләп тотарлык хәлдә түгел иде, бар дөньяларын онытып алар ләззәт диңгезенә чумды.

Яңа көн туды. Александра иртүк торып, өенә кайтып китте. Шушы көннән башлап Рөстәмнең йөрәгенә сары чәчле зәңгәр күзле бу туташ

ныклап кереп утырды. Озак уйланганнан соң ул Александрага үзенең күелендге уйларын һәм өйләнешергә тәкъдим ясады.

— Мин сине яхшы аңлыйм, Рөстәм! Тик син бит гаиләле кеше. Балаларыгыз да бар. Мин бит сезнең арага керә алмыйм.

— Их, Саша, Саша! Белсәң иде син гаиләбезне сакларга минем күпме тырышлык салганымны. Әти-әни исән чакта Таня әйбєт булып кына йөрде шул. Хәзер бөтенләй азды: мине санга да сукмый. Инде тәмам түземлегем бетте хәзер. Аерлышырга кирәк дигән карарга килдем. Балаларга исерек әни белән яшәүгә караганда детодомда җиңелрәк булыр.

— Кит инде, Рөстәм! Нишләп шул сабыйларны детдомга бирәбез ди? Мин аларны үз балаларым кебек карап үстерермен.

Менә шушы сөйләшүдән соң алар бергә яшәргә булды. Александраның әти-әнисе бу адымны башлап бик хуплап та бетермәде. Әнисе килеп, дөньяда булган яман яман сүзлєр белән кызын тиргәде. «Бала-чага булгансың, теләсәң ни эшлә. Тик башыңны иеп миңа килєәсе булма», — дип ишекне шап итеп ябып чыгып та китте. Бер атна чамасы вакыт үткәч Татьяна балаларын иренә алып килде. «Мин синең белән яшәмим, балаларыңны үзең кара! Эш хакың безгә түгел, үзеңә дә җитми бит», — дип Рөстәмне мыскыл итеп чыгып китте.Балалар елый-елый үксеп беткән, үзлєре ач, йөзлєреннән төс качкан. Кигән киемнәренә сидек, тәмәке, хәмер ислєре сеңеп беткән. Александра җитез генә аларны чишендереп ваннада юындырды, Өсләренә чиста киемнәр кидерде. Тамак та ялгап алганнан соң балалар татлы йокыга талды.Шуннан алар балаларның киемнәре салынган сумканы бушатырга тотынды. Пычрак киемнәр арасыннан кульяулыкка төйнәлгєн төенчек килеп чыкты. Рөстәм аны чишеп караса, анда төрле чүпрәк кисәкләре, чәч-йон, тырнак калдыклары һәм язу кисәкләре килеп чыкты. Яшьләр аңа әлләни игътибар бирмичә, чүп савытына ыргытты,Кичке аш әзерләгәндә Татьяна бер әзмәвердәй ир ияртеп тагын килеп керде. Ул Рөстәмгә бер ай эчендә фатирны бушатырга куша. Чарасызлыктан, ир фатирын тиз генә сатып, акчаның бер өлешен элеккеге хатынына илтеп бирә. Йортсыз калган яшьләр ике ай чамасы Аркадий исемле танышларында яшәп тора. Ләкин чит кешедә күпме яшәп була инде, Һєркемнең үз тормышы бит. Ярый, бәхеткә Александраның әнисе ярдәмгә килә. Ачуы килгән

чакта авыр сүзләр әйтеп кызын тиргәсә дә, аларның аралары озакка бозылмады. Бер-берсенә кунакка барышып, хәл белешеп тордылар. Шуңа да Александраның әнисе аларны бәхетсезлектә ташламый. Үз фатирын сатып, балаларына да бер бүлмәле фатир алып бирде. Беркөнне Рөстәм эштән кайтып керсә — Татьяна килгән. Ул үзенең сөяркәсе — грузин егете Волан һәм иптәш кызы Ольга белән килеп, тавыш чыгарып, Александраны кыйнап китә. Чыгып китәбез дип торганда гына Рөстәм кайтып керә. Җитмәсә әле, балалары елап, каршы килеп торсалар да, аларны да киендереп алып китәләр. Рөстәм бер ялгызы аларга каршылык күрсәтә алмый. Менә шул көннән башлап шул 2 баланың язмышы аның өчен билгесез. Гыйнвар азагында Рөстәм судка гариза язгач, күп тә үтми аларны законлы рәвештә аералар. Балалар Татьяна белән кала. Менә алар Александрасы белән икәү генә яши башлый. Ир заводтан эштән китеп яшелчәләр сату белән шөгыльләнә башлый. Күмәртәләп сатучылардан сатып ала да, балалар бакчасына, мәктәпләргә, башка төрле кибетләргә илтеп тапшыра. Александра сукырлар җәмгыятендә эшләвен дәвам итә. Шул рәвешле гаиләнең эшләгән акчалары азыкка да, аз-маз кием салымга да җитеп бара. Хәтта бераз гына акчаны туплап барырга тырышалар. Тик бәхет ялгызы гына йөрми шул. Аның янәшәсендә һәрвакытта караңгы күләгә булып кайгы, бәхетсезлек тә йөри. Аерым кешеләрне генә түгел, меңнәрчә гомерләрне, бар дөньяны аямый торган, бернәрсәдән дә курыкмаган, берничек тә җиңә алмаслык кайгы һәм бәхетсезлек йөри. Март аенда бер эшкуар белән сөйләшеп, үзара килешү нигезендә, Рөстәм арендага гараж ала һәм төсле металл җыярга керешә. Килешү буенча, җыелган чималны гараж хуҗасына — эшкуарга аерым суммага тапшыра. Тупланган акчаларына ул беренче мәлдә 500кглап төсле металла җыя һәм аны хуҗага тапшыргач, яхшы гына керемне кесәсенә салып куя. Күңелдә ышаныч очкыны кабына. Хатынына да, үзенә дә яңа өс киемнәре сатып ала. Шул көннәрдә Александра да базарда көнбагыш сатучысы булып эшкә урнаша. Хуҗасы аңардан «астан гына» самопал аракы да саттыра. Салкын көннәрдә көне буе базарда өшемичә тору өчен, базар сатучылары аны хәмер капкалап «җылынырга» өйрәтәләр. Шулай итеп хатын өенә кайтып кергәндә шактый гына «җылынып» кайта башлый. Беренче мәлләрдә Александраның бу кыланышы ирен артык борчымый. Мәхәббәтләре көчле булгандыр күрәсең. Тәмле, кайнар ашлар белән көтеп торган, иркә-назын кызганмаган хатынына Рөстәмнең бер генә дә авыр сүз әйткәне, канәгатьсезлеген

белдергәне булмады. Кайнар сөю хисләренә исереп, йоклап-уянулар үзе генә ни тора бит. Җырларда җырланган бәхет төне шушы буладыр инде ул.

«Эх, яшь чагым, яшь чагым!

Яшь чагым, гүзәл чагым!

Тиле яшьлегемне эзләп,

Сагынып кайттым тагын!», — дип җырлыйсы гына кала шул.

Рөстәм икенчегә төсле металлны бар булган акчасына җыярга уйлый. Бер тонна ярымлап, металл җыя да, кыйбатрак хакка, күрше Чиләбе өлкәсенә, Аркадийның ике туган абыйсы Романга тапшыра. Чиләбедән Рөстәм канатланып, яңа планнарга, яңа уйларга бирелеп кайта. Икенче көнне үк, металл җыя башлый — чөнки Чиләбедә чимал кыйбат: транспорт чыгымнарыннан соң да акча шактый артып кала. Бер тонна чамасы металл җыелганда Рөстәм янына гараж хуҗасы килеп керде. Аның Чиләбегә барганын да, нинди хакка тапшырганын белгән инде ул. Хуҗаның кәефе юк иде: ишектән кергәндә үк исәнләшмичә керде дә, җыелган металларны карап чыкты. «Аз җыелган, аз...», — дип мыгырданып өстәлдә торган аренда килешүен алды да ертып ташлады.

— Син нәрсә, егет, безне «кинуть» решил да? Давай миңа ике ел алдан аренда өчен түләп куй, срочно! ачкычларны бир — әнә гаражны арестовать итәләр, — дип ярсып, ишекне ачты да кемнедер чакырып китерде. — Мин әнә власть вәкилләре белән килдем.

Ишектә милиционер күренде. Рөстәмгә таныклыгын сузып үзе белән таныштырганнан соң, аның документларын сорады. Нишлисең, кесәдәге паспортын чыгарып салды. Өлкән лейтенант паспортны алып, сумкасына салып та куйды.

— Давай, сиңа өч көн срок, шушы сумманы менә шушында китереп тапшырасың!, — дип кисәтеп куйды.

— Мин бит әле бу гаражда өч ай гына эшлим. Нинди ике ел турында сөйлисез?! Күрсәт безнең килешүне! — дип Рөстәм дә ачына башлады.

Хуҗа кеше мыек астыннан гына елмаеп, аңа ап-ак кәгазьгә язылган килешү тоттырды.

Рөстәм бу кәгазь кисәген кулына алып ис-акылы китте. Монда аның исем-фамилиясы язылган, компьютерда җыелган, нотариус мөһере дә, печать тә куелган. Култамга да куелган, нәкъ Рөстәмнеке инде. Ләкин ул бит андый договорга беркайчан да кул куйганы булмады.

— Мондый килешүгә минем кул куйганым булмады. Безнеке бит кулдан гына язылган иде, — дип кирегә сузды Рөстәм.

— Кайда синдәге экземпляр? Договор 3 экземплярда төзелгән бит. Син нәрсә милицияне алдамакчы буласыңмы? — дип җикерде аңа өлкән лейтенант.

Рөстәм сораулы карашын хуҗа кешегә төбәде дә:

— Менә яңа өстәлдә иде, алды да ертты бит менә, — дип чүп савытына үрелгән иде. Шул мизгелдә хуҗа ул савыт янына килеп, кәгазьләргә ут төртеп җибәрде.

— Короче, егет, 3 көннән шушында киләсең дә шушы сумманы түлисең һәм дүрт ягың кыйбла! — дип әңгәмәне тәмамлады милиционер.

Рөстәмгә үз әйберләрен тоттырып, ачкычларын алдылар. Менә шул вакытта ул үзен алдауларына тәәмам төшенде. Договорда язылган суммага карау белән чәчләр үрә торырлык. Барлык булган акчаларны җыйсаң да — бары өчтән бер өлеше генә була.  Ул сөмсере коелып өенә юллана. Александрага барысын да сөйләп бирә.

Иртәгәсен хатыны аңа шундый тәкъдим ясый:

— Рөстәм, кадерлем, беләсеңме? Без әле яшьләр — кайда да яшәрбез. Тулай торак бирә торган эшен дә табарбыз, әйдә фатирны тиз арада арзан хакка булса да сатыйк. Тизрәк бу афәттән котылыйк!Нишләсен инде Рөстәм —  ризалашты. Александра тиз генә игъланнар элеп чыкты, шуннан базардагы хуҗасыннан процент белән бурычка акча алды. Сөйләшенгән вакытка акчаны алар өчәү: Рөстәм, Александра һәм абыйсы Илдар илтә китә. Акчаны биргәч, хуҗадан «расписка» да яздырып алалар. Тиздән Александра фатирны сатты, хуҗасына бурычны түли. Рөстәм тулай торакка өметләнеп бер оешмага бетонщик булып эшкә урнаша. Тик аларның бу адымын

Александраның әти-әнисе генә хуплап бармый. Әнисе кызын бик нык тиргәп, куып дигәндәй чыгарып җибәрә. «Син минем бөтен өметләремне җимердең. Укырга керерсең дип көттем — юк. Инде гаилә корганда да каршы килмәдем, исән-сау яшәгез, бәхетле булыгыз дип фатихабызны бирдек, фатирга кадәр сатып алдык бит. Булмагач булмый икән. Ышанычымны тәмәке белән аракыга алыштырдың инде!», — дип үрсәләнә-үрсәләнә тиргәде әнисе. Шуннан соң алар, бөтенләй күрешмәс булды.Алар чарасызлыктан, вакытлыча яшәр өчен бер бүлмәгә керәє. Рөстәм эшләвен дәвам итте. Ә менә Александра эшкә йөрми башлады, чөнки хәзер базар ерак. Ә шулай да тик ятмады ул — арзанрак хакка вак-төяк әйберлєр алып, шуларны сатып йөри башлады. Тик Рөстәмгә тулай торак барыбер бирмәделәр. Аптырагач, ул эшеннән китте һәм алар Иглин районына әнисенең өлкән апасына яшәргә күченде. Алар кайткач йортларына нур керде. Александра бар җирне пөхтә итеп җыештырды, Рөстәм ихата-кураны караштырды. Шулай бервакыт кичке аш ашаганнан соң, әбисе Рөстәмне үз янына чакырды да кулларына күз салды, аннан кәрт тә салды.

— Улым! Бик начар бозымга юлыккансыз бит. Үлгән кош канаты, чәч-тырнаклар белән сихерләгәннәр сине. Бик көчле бозым бу. Ә шулай да аны җиңәргә була. Тик шушы әйберләрне эзләп табып, дога язып кирегә кайтарырга кирәк.

Рөстәмнең шулчак «кылт» итеп Татьяна китереп ташлаган бала әйберләре арасыннан килеп чыккан төенчек исенә төште. Шушы хакта ул әбисенә дә сөйләп бирде.

— Их, балам, балам! Чыгарып ташлап, дөрес эшләмәгәнсез шул. Мин тырышып карармын, тик бер дә ышандыра алмыйм. Ходай ярдәм бирсен инде сезгә! — дип укына-укына ниндидер үлән яндырып, төтенен иргә таба өрде.

Монда 6 айлап яшәгәннән соң алар тагын Уфага әйләнеп кайта. Рөстәм Уфа моторлар төзү берлєшмәсенә эшкә керә. Тагын вакытлыча гына дип бер бүлмәгә яшәргә керәләр. Һәм ниһаять тормышларында күптән көтелгән шатлыклы вакыйга була — Александра бәбигә уза. Тик менє яшәү шартлары гына кыенлаша. Рөстәм эшләгән заводта 5-6 айлап акча түләмиләр. Шунлыктан ул өстәмә эшкә — дәваханәгә каравылчы булып урнаша. Тик менә канга

сеңеп калган металл чире генә аның күңеленә барыбер тынгы бирми. Заводтан кесәләренә, җиңнәренә тутырып запас частьләр, төсле металл кисәкләре алып чыга. Яисә яшереп куя да — төнлә килеп ала. Алар, гадәттәгечә, эш вакытында металл кисәкләрен җыеп, биек таш койма астына җирне казып яшереп куялар. Төнлә 3-4 тирәсендә, барып ала һәм үзенең каравылчы бүлмәсенә җыеп бара иде. Атна саен аны металл тапшыру пунктына илтеп шактый гына керемгә ия була иде.

Беркөнне Рөстәм каравылда торган вакытта аның янына күршесе йөгереп килә. Александраны тулгак тота башлаган икән. Рөстәм тиз генә сменщигына шалтыратып хәлне аңлатты да еенә йөгерде. Ул кайтып җиткәндә «Ашыгыч ярдәм» машинасы Александраны алып киткән иде инде. Икенчә көнгә — 13 майда көтеп алынган сабый, аларныә уллары дөньяга аваз сала. Рөстәмнең шатлыгының иге-чиге булмый. Ул хәзер иң бнхетле кеше итеп тоя үзен. Сөенечесен туганнарына, әнисе урынына калган Роза апасына шалтырата. Барысы да җыелышып бәби күрергү килә, кулларыннан килгәнчә ярдәм итәргә тырыша. Улларына Эдгар дип исем кушалар. Кечкенә сабый бу кадәр дә әтисенә охшар икән, коеп куйган диярсең. Шундый ук зәңгәр күзле, кечкенә борынлы. Тиешле вакыт җиткәч Рөстәм күршеләре белән бергәләп, чәчәк гөлләмәләре тотып, бәби тудыру йортынннан якыннарын алырга дип килә.

Александрага баланы имезергә рөхсәт итмиләр, Эдгар ясалма туклану белән үсә. Рөстәмнең туганнары Роза апа һәм Шәрифулла абый яшь гаиләгә игътибарларын арттыра, һәрчак ярдәм итәргә тырыша. Шул рәвешле әйбәт кенә яшәп китә алар. Рөстәм шул ике урында эшләвен дәвам итә. Улларына 2 яшь тулгач, аны балалар бакчасына биреп, хатыны да чәчкә кибетенә эшкә урнаша.

Көннәрдән беркөнне, ирнең күзе көтмәгәндә ялкынсына, эренләп чыга. Алар бергәләп дәваханәгә бара, шуннан кайтышлый Рөстәм Александрга үзенең яшереп куйган 50 метр кабель барлыгын әйтә. Бергә чакта аны алып кайтып куярга уйлыйлар. Койма буенда бер кеше дә күренмәде — яшеренгән урыннан кабельне тартып чыгарып, китәргә җыенганда аларны заводның сак хезмәте эләктереп ала. Рөстәмне заводка алып кереп аңлатма яздыралар да өенә җибәрәләр.Әлбәттә инде бу болай гына тәмамланмый. Рөстәмне эшеннән чыгардылар, суд аны ике елга шартлы рәвешле ирегеннән

мәхрүм итү турында хөкем чыгарды. Рөстәм өчен авыр көннәр башланды. Ул төшенкелеккә бирелде, аның өмет канатлары сынды. Йокысызлыктан, һәрчак кәефсез йөрүдән ябыкты, тиз кызучанга әверелде. Танышлары аша базарга балта остасы булып урнашып караган иде, озак эшли алмады. Ул аз гына физик эштән дә тиз арыды, хәлсезләнде. Аяк-куллары хәтта тыңлашмый башлады. Чарасызлыктан ул бу эшеннән дә китте. Ләкин бөтенләй эшсез дә ятып булмый бит инде. Ул үз җаена гына башкалар өчен вак-төяк ремонт эшләрен башкарды. Шул арада Александра да күзгә күренеп үзгәрде. Ире белән аралары суынды, чөнки сәламәтлеге какшавы аркасында ул ир-ат буларак «үлде». Хатын эшеннән гел кызмача булып кайта башлады, соңлаган чаклары да күп булды. Тора-бара куна да кайтмый башлады. Төрле сәбәпләрен дә табып торды: я әнисе чирләп киткән, я иптәш кызына кунакка бара. Бала тулысынча әтисенә генә калды. Ул Эдгарны балалар бакчасына үзе илтте, үзе алып кайтты. Түләргә акчалары да булмагач, аларны бүлмәләреннән дә чыгардылар. Балаларын алып алар Рөстәмнең танышлары Юра һәм Наташаның йортына китә. Баргач табын корып утыралар, хәмернең дә чамасын оныталар. Юра Александрага бәйләнә башлый, алар тәмам оятларына югалтып, ярымшәрә калып биергә тотына. Наташа бу күренешкә түзеп тормый, ачы тавыш куптара һәм әниләренә кайтып китә. Рөстәм улын йоклатырга дип икенче бүлмәгә кереп китә. Әнисенең чит ир белңн төрле авазлар чыгарып кәеф ачканына Эдгар да озак кына йоклый алмый азаплана. Ә Рөстәмнең хатынының бу кыланышына йөрәге ничек әрнегәне, күңеле ярсыганын сүз белән генә аңлатып бетереп булмый. Улы йокыга талгач ул Саша белән танышкан чакларын, бергә мәхәббәт-назга төренеп яшәгән вакытларын исенә төшереп уйланып ята.

Икенче көнне иртән үк Александра Эдгарны алып чыгып китә. Рөстәм Иглин районына апасы янына кайтып китә. Бер атнадан соң Уфага килеп Эдгарны эзли. Тик балалар бакчасында булмый ул. Баксаң Саша Эдгарны ике көн элек Ольга исемле ахирәтендә калдырып киткән икән. Рөстәм улын алып авылга кайтып китә. Монда тыныч кына яшәсәләр дә, тик бу озак дәвам итмәячәге көн кебек ачык иде. Чөнки апасының бер пенсия акчасына өч җанны асрау мөмкин түгел. Рөстәм улы белән янә Уфага кайта. Монда бер танышы — Николайга килә. Бәхеткә ул аларны кире какмый, киресенчә җылы каршылый. Өстәвенә алар бергәләп кешеләргә фатир төзекләндерү эшләрен

башкарып, аз-маз акча да эшлиләр. Бер кичне болар яшәгән фатирга Александра килеп керә. Кем әйткән, кайдан эзләп тапкан диген... Тавыш-фәлән чыгармыйлар, тыныч кына күрешәләр. Александра кибеттән пилмән, башка тәм-том алып керергә дип Рөстәмгә акча суза. Тик ир кибеттән әйләнеп кергәндә, Николайның йоклавы белән файдаланып хатын баланы алып чыгып киткән була. Рөстәм тәмам төшенкелеккә бирелә, башында мең төрле уй кайный аның. Эдгарны хәзер кайдан табарга? Башны кайда куярга? Арытаба ничек яшәргә? Ул канатлары сынып, җирдә тыпырчынып яткан кош хәлендә калды. Шул мизгелдә ирнең башына бер уй килә. Ул үз-үзенә кул сала. Кулына лезвие алып, кан тамырларын кисә. Николай уянмаган булса, ирнең гомере өзелгән булыр иде. Николай тиз генә күршедә яшәгән шәфкать туташы Ларисаны алып керә. Ул Рөстәмнең яраларын эшкәртеп, тегеп куя. Ярый, күп кан югалтып өлгермәгән була Рөстәм. Югыйсә, фаҗига булырга да озак калмас иде. Бу күңелсез вакыйгадан соң ул бераз тынычлангандай була. Әмма бер уй аңа барыбер тынгылык бирми — ничек тә Эдгарны табарга кирәк. Александраның танышлары аша сораштыра торгач ниһаять таба ул аны. Әнисе аны яшь сабыйлар приютына тапшырып, үзе каядыр юкка чыккан икән. Рөстәм көн саен улы янына барып йөреп, күңеленә юаныч таба...

... Таң атканда сәгать уклары 6га якынлашкач, картлар һәм инвалидлар йорты җанлана. Үзләре йөри алганнар коридорга чыга, тәмәке тарту бүлмәсендә кеше күбәя. Урында ятучы авырулар янында санитаркалар кайнаша башлый. Күңелләрне болгаткан сидек исе, сасы тәмәке төтене, тегендә-монда яңгыраган пычрак сүгенү сүзлєре — барысы да вакытлыча күренеш икәнен аңлыйсың. Хәрәкәтсез ятучыларның асларын алыштырып, бүлмәләрдә идәннәрне юып чыгаргач, иртәнге аш керткәч интернат шифаханәне хәтерләтә башлый хәтта. Рөстәм телевизорны кабызды. Яңалыклар, боевик кинолар һәм мультфильмнар карарга ярата ул. Шул вакытта аяк-кулларына гимнастика ясап ала. Шуышып дигәндәй өстәле янына барып утыра, трубка аша гына чәй эчә. Чөнки кулларына бернәрсә дә тота алмый аның. Аяклары да үзенеке кебек түгел — хәрәктәләнми, тыңлашмыйлар. Ул инвалид коляскада гына йөри.

Бүлмәнең ишеге ачылды, ут кабынды.

— Хәерле иртә, егетләр! Әйдәгез, подьем! Юынабыз, бүлмәне җиллэтәбез.

Ишектә үзенең яшеннән күпкә яшьрәк күренгән, зифа гәүдәле, тормыш дәрте ташып торган гүзәл зат — Зәмирә исемле санитарга күренде. Ул Рөстәмгә коляскасына утырырга ярдәмләште, кул-битләрен юындырды да кулына сөлге тоттырып башка бүлмәгә чыгып китте.

Без Рөстәм белән бер бүлмәдә яшибез. Өстәл кырына утыртып, бәбине ашаткан кебек башлап аны ашатам, аннан чәй белән шулпаны ул үзе трубка ярдәмендә эчә.

Көндезге сменада эшләүче санитарка Аймара да килеп җитте. Аның челтерәп чыккан тавышы, яңгыравыклы көлүе өчен, без аны яратып «Колокольчик» дип йөртәбез. Безнең караңгы тормышыбыга нур чәчүче, сынган канатларыбызны ялгаучы Изгелек фәрештәсе сыман күңел юатучы җаннар бит алар. Көннәр буена шушы атмосферада эшләп, кичтән өйгә — тормыш иптәше һәм балалары янына ашыга. Көне буена аларның кулыннан күпме эш үтә: һәрберебезне юындырып, чиста киемнәр һәм урын-җир әйберләрен алыштырып, ашатып-эчереп һәм шул ук вакытта бүлмәләрне, коридорны чисталыкта тотарга кирәк. Барына да өстәп, әледән-әле тикшерүләр, төрле комиссиялєр... Иртәнге ашны, ашагач, азрак ял итеп алабыз. Тәмәке көйрәтергә барабыз, йөри алганнар һавага чыга. Ярый Рөстәм бу җәфадан котылды. Ике ай элек Рөстәм хастаханәдә ятып чыкты, шул вакытта тәмәке тартуын ташлады ул. Медицина социаль экспертизасы комиссиясе аңа беренче группа инвалидлык бирделєр.


Көн дә табиб Радик Искәндәрович кереп хәлебезне белә, кан басымын үлчи, йөрәк-үпкәбезне тыңлый. Кирәк чакта укол кадарга, дару бирергә ачык йөзле шәфкать туташларыбыз бар. Кыскасы, бүлмәдә яткан килештә коридорда кем йөргәнен аяк басып йөргән тавышыннан да аңлыйбыз.

Көн дә сәгать сигез белєн тугыз арасында смена алышына. Бүген дежурга минем якташым Рузилә килә. Сабыр холыклы, киң күңелле якташымны һәрвакыт сагынып, көтеп алам. Безнең этажда 60 кеше, 60 язмыш яши. Аларның һәрберсенең үз холкы. Беребезнең дә хәтерен калдырмыйча, барыбызны да чисталыкта, пөхтәлектә тотучы изге җаннарга минем дә, Рөстәмнең дә рәхмәте чиксез. Кирәк әйберне вакытында сатып алып, китереп бирәләр, шатлык-кайгыларны да, күңелдәге сагышны да уртаклашучы бит алар. Менә шулай сөенешеп-

көенешеп үтә безнең гомер көзләре. Тиздән Рөстәмнең улы Эдгарны әтисе янына кунакка алып килергә тиешләр. Алар көн саен телефоннан сөйләшеп тора. Очрашуны көннәр, сәгатьләр санап көтә инде әти кеше. Туганнары, дуслары белән дә һәрчак элемтәдә ул. Яшәргә урыны бар, ялгызы түгел ул. Барысы да әйбәт кебек, тик күңеле генә барыбер боек Рөстәмнең. Әле бит аңа 38 яшь кенә. Сөеп-сөелер чагы, җимертеп дөнья көтәр, балалар үстерер вакыты. Ә ул шушы йортта яшәргә мәҗбүр.

Әйе... Язмыш аны аямады. Гөлдән-гөлгә кунды, яшьлегендә сөеп-сөелеп алды, тик бәхетле генә булмады. Сынган канатлар ялганса да, аларның эзе мәңгелеккә тирән яра булып күңелдә калды.

Май-август 2009 ел




СӨЮ КӨЧЕ!

Нишләп һаман шылтыратмый икән инде? Бүген бит инде дүртенче көн...Нурия курка төште.Күңеле нәрсәгәдер үрсәләнеп,ашкынып тора!Ул үзалдына гына сөйләнеп,җыена башлады:"Тиктомалга түгел бу хәл-телефонын алмый,үзе шылтыратмый-димәк нидер булган!..."

Азат белән Нурия икесе дә мөселман зиярэтында очраштылар.Нурия,ике ел элек авариягә очрап мәрхүм булган ире Камилнең каберен тәртипкә китереп,бераз уйланып торды да,үзалдына укынып тере чәчәкләр салып,капкага таба юнәлде.Азатның да сөекле хатыны өченче бәбиен тудыра алмаган,ике җан бергә күз ачып йомганчы якты дөнья белән хушлашкан.Менә шунда очраштылар инде алар!Азатның дүрт һәм сигез яшьлек ике

кызы әнисез, ә Нуриянең ике малай-7 һәм 9 яшьлек Айнур белән Алмаз әтисез торып калдылар.

Көн артыннан көн узды.Азат беркөнне Нурияга тәкьдим ясады.Күңеле белән эчтән куанса да, Нурия сиздермәскә тырышып:"Ашыкмыйк әле,Азат,бик мөһим эш!Балалар да бар-бер-беребезне ныграк белик,араларны якынайтыйк!Мин дә каршы түгел-балалар бәхете хакына!!!".

Ашыга-ашыга Азат яшәгән квартирага килеп җиткәнен дә сизмәде Нурия!Звонокка басып-басып карады-җавап юк!Ярый әле-бер күршесе чыгып:"Өченчекөн "Ашыгыч ярдәм" машинасы белән хастаханәгә алып киттеләр аны!"-дип аныклык кертте.

Чак эзләп тапты ул аны.4 нче шәһәр хастаханәсенең онкология бүлегендә ята икән.Монда Нуриянең авылдашы врач булып эшли-аны кабинеттан чакырып алды да:"Гөлфинәкәем,зинһар Азат Сайфуллин нинди чир белән ята-шуны белергә кирәк!"-дип,өметле күзләре белән авылдашына карады.

10 минутлап вакыт үткәндер,Гөлфинә кәгазләр тотып,килеп чыкты.Азат ның хәле мөшкел икән-баш миендә йомырка сарысы кадәр яман шеш тапканнар!Бу хәбәр Нурияны тәмам аяктан екты,ул көч-хәл белән Азат яткан палатага килеп керде....

-Азат җаным,нишләп болай булды?Нәрсә эшлибез хәзер-мин бит инде сиңа өйрәнеп беттем!Өнемдә дә син,төшемдә дә син!Синнән башка ничек яшәрмен мин!-дип үрсәләнде.Аны врачлар тынычландырырга тырыштылар.Тик Нурия Азатның күзләренә карап дәвам итте: -Балалар хакына,минем хакка зинһар безне ташлап китмәәәәә!Инде яңадан бәхетле булдым дигәндә нишләп болай булды...Иии Аллакаем!Зинһар ярдәм бир!Йөрәгемдә чәчкә аткан сөюем хакына,ятим итмә сабый балаларны,иии Аллакаем!".

Аны икенче бүлмәгә алып чыгып,тынычлата торган укол эшләделәр.Өлкән хирург:"Хәле бик начар!Аңа тынычлык кирәк-бәлки кире суырылыр кем белә!Әле үсеш стадиясында генә бәлки кире процесс башланыр!"-дип,аның күңеленә өмет уты салды.Бер көнне 4 бала белән мәш килде,бер көнне Азат янында!

Бар икән Алла!Чигенде явыз чир!15 көн дигәндә инде Азат та торып йөри башлады.Спортзалга,ашханәгә акрынлап үзе барды,телевизор

карарга коридорга чыгып йөри де инде.Озак ятмады-28 көннән соң өенә кайтты..Өйгә килеп керсә....могҗиза!!!!Матур-матур шторалар,ишек чаршаулары эленгән,чиста һәм пөхтә итеп җыештырылган!Нурия  шат елмаеп,тәрәзә төбендәге яңа чәчәк аткан гөлгә су сибә иде!

Июнь 2011 ел.

